
Гүзәл Галләмова
Ямьлисе
иде
тормышны...

Гүзәл Галләмова

# *Ямьлисе иде тормышны...*

Публицистик язмалар

Галләмова Г.И.

Ямьлисе иде тормышны... : публицистик язмалар / Гүзәл Галләмова. 2013. 82 бит.

Китапка авторның соңгы елда матбугатта басылган мәкаләләре тупланды. Аларда намуслы хезмәт юлы үткән шәхесләрне олылау, мәңгелек әхлакый төшенчәләр, язмышлар чагылышы, бар булмышы белән тормышны сөюе чагыла.

# *Автордан*

Бу тәүге китабым. Газеталарда (кыскартылып) басылган бу язмаларымны укыганыгыз да бардыр. “Үзең үк язгансың... Нигә китап итеп чыгарттың?” – диючеләр дә булыр. Нинди генә булмасын, китап ул – китап! Электән, китапка карата хөрмәт тәрбияләнгән. Ә газеталар укылгач, кайда гына ятмыйлар, нинди генә максатларга кулланмыйбыз?!.

Һәр кеше – шәхес! Республикабыз матбугатында басылган мәкаләләремдә үзем аралашкан, бәяләрлек шәхесләрне хөрмәт хисе белән зурларга тырыштым. Әлбәттә, хөрмәткә лаек кешеләр күп һәм барысын да зурлау мөмкин эш түгел...

Яңа танышлар: “Журналистикага ничек кереп киттең?” – диләр. Районыбыз (Лаеш) газетасы “Кама ягында” хезмәттәшем, якын күршемнең якты истәлегенә багышланган саллы гына беренче мәкаләм басылганга да 20 ел була икән. Шул еллардан район газетасында хәбәрче булып киткәнемне, кереш сүз язганда гына барладым. Язмалар язуым – халыкка хезмәт итүдә фәлсәфи-тәрбияви яктан бер өлешем булсын иде дим. (Элгәре, мәдәни-тәрбияви агарту юнәлешендә зур көч куеп эшләгән идем.) Күңел түремдә урын алган, халык бәяләрлек шәхесләргә хөрмәт белән каравым – аларны үрнәк итеп күрсәтәсем, намуслы хезмәтләрен бәялисем, данлыйсым килүе; шулай ук тормыштагы пычрак гамәлләрдән арындырасы килү теләге белән тәрбияви көрәшүем дә – барысы да тормышны ямьлисе килү теләгемнән.

Торыр җирләребез яманлыклардан азат булып, кешеләр үзара хөрмәт белән бер-берсенең уңышларына сөенсеннәр иде. Һәр туар көнгә шатланып, булганга шөкер итеп, изге максатларга омтылып яшәргә насыйп булса икән! Ямьле тормыш шуннан башлана, минемчә...

# Гамьсезме ул балачак?

Гамьсез балачак дияргә яратабыз. Соңгы вакытта бигрәк тә килешмим бу сүзләр белән. Балаларның ата-ана кайгыртуы астында булуына әйтеләдер инде ул үзе. Алай дисәм, олы кешеләр арасында да, бала-чага кебек, берни уйламыйча, “көн үтте”гә яшәүчеләр бихисап...

Балалар белән аралашам. Гамьсез түгел алар! Кечкенә булсалар да тормышка үз карашлары, үзләренә күрә максатлары да бар. Әлбәттә барысыда бер төрле түгел. Мәктәптә укып кайтып, спорт белән шөгыльләнгән, район иҗат һәм сәнгать мәктәпләренә йөреп, музыкаль белем алган, авыл мәдәният йортындагы түгәрәкләргә йөргән һәм һәр чараларда диярлек катнашкан балалар ничек инде гамьсез булсыннар?! Үзләре бала гына, ә никадәр ихтыяр көче, тырышлык, үҗәтлек бар аларда. Ә бит шул мәктәп-укучы темасына кире әйләнеп кайтып яза башласаң, мәктәп дәресләрдән соң үткәрелгән чаралар белән гөрләп тора. Анда да шул ук балалар мәшь килеп йөриләр. Укытучылар, балалар күңеленә юл салып, аларны шәхес итеп тәрбияли торгач, теләсәләр дә теләмәсәләр дә бала кебек куана, вакыты белән аларның эчкерсез дустына әйләнәләрдер дип уйлыйм мин. Гомер буе укытучы булганнар, күпме балага күңел җылысы бирәләр икән?! Балачакны гамьле итү өчен тырышкан һөнәр ияләре шул алар. Юкка гына, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вәссәлләм "... барча остазларыбызның, ... рухларын шат кылсаң иде”, - дип дога кылырга өйрәтмәгән. Димәк, Аллаһ тарафыннан, укытучы хезмәте саваплы буларак, югары бәяләнә торган хезмәт.

Балаларның төрлесе бар дип сүз салган идем. Һәр бала үзенчәлекле, һәр нәрсәгә үз карашы. Укытучы һәр кайсының мөмкинлекләрен вакытында күреп, киләчәктәге уңышларына юл яра дип фикер йөртәм мин. Әлбәттә, баланың күңелендә гаме булса гына. Ярый ла, уңышка ирешкәннәргә һәр кеше дә укытучы кебек шатлана, горурлана белсә. Юк шул, бармакка бармак сугып, эш күрсәтә белмәгән, теленә салынган кешеләр тырнак астыннан кер, пычрак эзлиләр. Үзе булдыра алмаган кеше, ирешелгәннәр нинди авыр, катлаулы юллар аша, никадәр көч, сәламәтлек исраф ителеп килгәнен аңламый. Ә уңышка юллар, мисаллар нигезендә тәфсирлаганымча, балачактан салына...

Алсу - Асылъярыбызның балачагын исемә еш төшерәм. "Ай-яй! Булса да булыр икән үзен аямый торган кеше”, - дип гәҗәпләнә идем. Үзем, 16 яшькә олы булсам да, фәлсәфи фикер йөртә белүенә, үҗәтлегенә, тырышлыгына исләрем китә иде. Беркайчанда көчен кызганмады. Талантын югары бәяләп, ялындырулар, мескенләнүләр аңа ят нәрсә иде. Күңелдән үткәреп карагыз әле, 13

яшьлек кыз бала чиста тавышка (берсе дә алдан яздырылмаган) 17 җыр җырлап, соло концертын куйды ("Яңа гасырны сәламләп” дип аталган бу концерт 2000 нче елның 13 гыйварында булды). Укуда да алдыңгы булып, бер генә район, авыл мәдәният чараларында (республика күләмендәге җыр фестивальләрендә дә) катнашмыйча калмады. Кечкенәдән югары тәрбияле бу баланың, эти-әнисе чит авылга йөреп көн озын эштә булуын, энесе белән сеңлесенә апа булуын да исәпкә алсаң, кая инде ул гамьсез балачак тәтесен?! Шулай балачактан ук "тәртә арасына” кертсәк, әллә соң бала уңышларга ирешүчән, булдыклы булып үсә микән?! Безнең авылда үтә дә уңган-булган гаиләләр байтак. Тырыш кеше күп бала табудан да курыкмый. Кай арада тәрбия бирергә өлгерәләрдер? Җәмгыятьтә җаваплы хезмәтләрен җиренә җиткереп башкарган ата-аналарның балалары да - эти-әниләренең авылдашларга хәер-хаклы карашларын, аралашуларын күреп, эшләгән гамәлләре аша -.тормыш мисалларында күреп үсәләрдер дип уйлыйм. Бер шулай спектакль куярга булдык. Алинә салкын тидергән - каты авырый. Шул 10 яшьлек бала җаваплылык хисен югалтмыйча (җаваплылык хисе балада булмаса да гаеп түгел бит!) кышкы салкында әнисенең өс киеме (озынрак, җылырак булсын дип) белән репетицияләргә килүе, үзенең сүзләре булмаганда урындыкка ятып торулары исемә төшә. Бу бит ата-анадан килгән - коллектив хакын, җитәкче хакын хаклау кебек матур сыйфат. Ә бит авырмаган көе дә, йөз сылтау табып күләгәдә кала алабыз. Балачактан ук шундый булганнарга зур өметләр белән карыйм мин. Күңелемнең тирән төпкеленнән изге теләкләремне телим. Булдыра алганча, мөмкинлекләр бирергә тырышам.

Әгәр уңышка омтылып, үзен кызганмыйча алга бара икән - гәеп эзләмәгез диясем килә минем, кайберәүләргә. Сәләтен, булдыклыгын күреп, кемдер ”үсәргә” булышкан икән, рәхмәттән башка сүз булырга тиеш түгел. Иң беренче чиратта, арттан этүчене түгел, ә үзен кызганмаган, тырыш, көчле алдан баручыны күзалларга кирәк ләбаса. Әгәр уңышларыннан түзә алмыйча, көнләшәсез икән инде, үзегез тырышып эшләп карагыз. Бәлки, пычрак атып, гайбәт сөйләп әрәм үткән вакытыгыз файдалы үтәр, күңелегез дә чистарыр. Теге дөньяларда да: ”Кая минем эшләгән изгелегем?! - диеп җаныгыз бәргәләнеп елап йөрмәс шәт.

*"Безнең гәҗит” (№15) газетасында (18. 04.2012) басылды.*

# Изгелек онытылмый

Яхшылык онытылмый икән. Хәтта 20 ел, 50 ел үтсәдә... Балалыгым, яшьлегем белән аңлап бетермәгән ул чакларны хәтердә яңартам да, һәр изгелек онытылмас хатирә булып күңел түрендә урын ала икән дигән ныклы фикергә киләм.

...Дүрт туганымнан соң, күп вакыт аралыгы белән туганга, үсмер елларыма әти белән әнинең шәһәрдә 8 оныгы үсеп килә иде инде. Аларның каникуллары төп нигездә, авылның саф һавасын сулап, яңа сауган сөт, каймак, олы мичтә пешкән таба ашлары белән сыйланып үтте. Мин җәйләрен өйдә "пионервожатый" булдым. Шәһәр балаларына җитәкчелек итү җиңелдән түгел иде. Хәйран гына маҗаралы хикмәтләр шаһиты булуымны язып тормыйм. Хезмәт саллы булуын гына әйтә алам: юган өс-башлары гына бишәр чиләк булып, электән килгән традициягә буйсынып, көянтә-чиләк белән Камага барып керләр чайкый идем...

Берчак шулай, идән юганда өйдәге бала-чага тыз-быз йөриләр, әллә ничә керделәр, әллә ничә тапкыр чыктылар. Ачуланып, кипкәч керерсез дип, пыраклатып чыгарып җибәрдем. Башка борчымаганнарына, чисталыкка канәгать булып, баскыч төбенә җиткәндә, ярым ачык капкадан (көндез капканың ябык булганын бөтенләй хәтерләмим) таныш булмаган өлкән яшьтәге бабай килеп керде. Исәнләшкәч, кем кирәк сезгә, дип сорадым. "Кызым, берни сорама, кергәч әйтермен", дип хуҗаларча түр якка кадәр кереп китте. Ачык авызымны ябарга онытып, шул гына җитмәгән иде дип, артыннан иярдем. Аңлавымча, бабай начар күрә иде: стеналарга тотынып, гел кергән йортына кергән күк, чамалап атлады. Түргә утырып, кулларын кушырып озаклап дога кылды. Теләмәсәм дә көтеп тордым инде. Догасын багышлап бетергәч әйтә бу: "Мин бу йортта 18 яшемдә бер ай чамасы яшәдем. Үзем Әлкидән мин. Бабаң белән әбиең буладыр инде сиңа алар... Җәбергә түзә алмыйча, ФЗУдан качып кайтып барганда, мине үз балалары күк ашатып, эчертеп тәрбия кылдылар. Гомерем буе истә тоттым, рәхмәтле булдып яшәдем. Картлык көнемә кадәр күңелемдә йөрткән әманәтемне, Аллага шөкер, бүген үтәдем - йортка кереп дога кыла алдым. Бу нигез игелекле нигез, син дә игелекле бул!", - диде дә, мин аңкы-миңке басып торганда чыгып та китте. Әйткән сүзләренең мәгънәсен берничә дистә ел үткәч кенә аңладым. Чыннан да, әтиебез дә, аның вафатыннан соң әниебез дә бу нигезне игелекле әби-бабайларның юлын дәвам итүче шәфкать ияләре булган ләбаса.

Авыл җирендә авылдашлар, туганнар, күршеләр белән ярдәмләшеп яшисең. “Кул - кулны юа, ике кул - битне юа”, диләр. Ансы да хак. Бүген синең ярдәмең, иртәгә башкаларныкы сиңа кирәк булырга мөмкин. Ә чит кешене, күбебез чит итә. Нигә кирәге бар моның дияргә дә уйлап тормыйбыз.

...Колхозда партоешма көчле чак. Правлениега чакырту дигән нәрсә бар иде ул вакытта. Беркөнне әни шунда китте. Авылга яшь белгечләр – агрономнар килгән, фатирга кертү мәсәләсе карала икән. Әни сөйли иде боларны: “Чакыртылган бер генә кеше дә риза булмады. Мин дә, кунак-төшемнән бушаганым юк дип, ризалык бирмәдем. Чыгып барганда, юк дип әйтмәячәгемнән файдаланып, парторг: “Менә бу апагызга ияреп кайтыгыз”, диде. Ризалык бирмәгән көе шулай дигәненә ачуым килсә дә, каршымда басып торган ике яшь егетне күреп, болар да кемнеңдер газиз балалары бит дип, аны-моны сиздермичә: “Әйдәгез!”, дип ияртеп кайтып киттем...”

Шуларның берсе колхоз председателе булып озак кына эшләп ир уртасы яшенә җиткәч тә, гаиләсе белән дә әни янына кереп хәл-әхвәл белешә иде. Кешелекле кешене җитәкче булу да, дәрәҗә дә бозмый диясем килә. Республикабызның финанс министры да авылыбызда яшь белгеч буларак, хезмәт юлын башлаганда, әти-әни фатирга кертте. Исемдә әле, ишегалдында сугым терлекне суя торган мәшәкатьле чак иде. Ияртеп килүчене дә, ияреп килүчене дә борырга базмадылар...

Ә әни үзе, кешегә ярыйм дип ясалма булучылардан да, кешенең бер алдына, бер артына төшеп куштанлана да торган кеше түгел иде. Ләкин кешене: яшьме, олымы - хөрмәт итәргә тырыша иде. Үзе генә түгел, фатирда торучылар да игелекле, югары тәрбияле кешеләр туры килгән. Югары дәрәҗәләргә ирешкәч тә, кечкенә генә яхшылыкны да - фатир хуҗасы буларак гади генә хезмәт күрсәткәнне дә оныта торган булмадылар. Гайзатуллин Радик та гаҗәеп дәрәҗәдә кешелеклеген, ихлас күңеллеген раслап, һәрдаим әнинең изгелеген бәяләп, рәхмәтен белдерә килде.

Инде әнинең оныклары үзләре балалар үстерәләр. Авылга кайткач, бергә җыелган чакларында әбиләре белән үткән җәйләрнең күңелле мизгелләрен ярты төнгә чаклы искә алып утыралар. Сагыну катыш күз яшьләре белән әбиләре әйткән сүзләрне дә, эш-гамәлләрен дә хәтерләрендә барлап чыгалар. Шуклыклары өчен дә уңайсызланалар. Рәхәт балачаклары артта калса да, алар әле яшьләр! Ә минем күңелдә башка уйлар: истәлекләр - дога булып ирешсен иде, дия-дия, сыйлап йөрим үзләрен. Аркаларыннан чәбәкләп, уйларым белән нәни чакларына әйләнеп кайтам да: “Никадәр авырлыклар үтте болар белән

мәшь килеп. Бәлки, барыбызның борчулары  шулай күпкә җыелып, иртәрәк киткәнсең син, әни?!” - дим. Аннан, аларның яратып сөйләгәннәренә эледән эле колак салам да, күңел түремдәге үзе ачы, үзе җылы бер төер эреп, канәгать хис барлыкка килә: “Ун оныk, вафатына дистә елга якынлашканда да, әбиләрен онытмыйча олылап, яратып, сагынып сөйләшеп утырулары - әни-әбиебезнең үлемсезлеге бит бу!”, - дим. Мондый үлем зур бәхет ул, дип бәялим. Үзеңнән соң калган буынга, сагынып сөйләрлек гамәлләрең булмаса, озын гомерле булудан ни мәгънә?! Бер яхшылык та онытылмый икән дип, үземә “бер өлеш” алып куям. Бар вакыйгаларны бизмәнгә салып үлчәсәң, әллә никадәр гыйбрәт җыясың. Әллә кайда түгел ул, аралашкан кешеләр арасыннан гына да күпме туплыйсың аны...

Әти белән әни, без биш баланы үстергәндә - башта әнинең абыйсын, аннан әтинең энесен берничә еллар гаиләләреннән аерылган чакларында үзләренә сыендырганнар. Үз тормышың проблемалары да җитә, югыйсә. Күңелләре киң булган икән. Нигез кунак–төшемнән бушамаган. Һәркемгә ачык чырай күрсәткәннәр. Кунакчыллык татар канына сеңгән булса да, кунак тәрбияләү – үз көеңә генә яшәү түгел, билгеле. Кунакчыллык игелекле гамәл, әлбәттә. Игелекле гамәл дигәннән, мәчет янәшәсендә торгач, җәйләрен мәчеткә тукталган мөселман кардәшләр безгә суга, бәдрәфкә керүчеләр саны көне белән дистәгә тула иде. Көн дәвамында һәрберсен каршыла, озат... Без - яшьләр ухылдый башласак, әни сабыр булырга өнди иде. Таләпчән тавыш белән: ”Мин исән чакта капкамнан беркемдә риза булмыйча китмәсен! Мин үлгәч, үзегез чамаларсыз”, ди иде.

Хәзердә шул нигез, шул мәчет. Артык күпкә киткән көннәрдә чамам бар, хәйләләп борып җибәрергә. Әмма капкага килә җитә, мәрхүмә әнинең: ”Капкадан ризасызлык белән китмәсеннәр!” дигән әмердәй сүзе ишетелгән күк була да, уем үзгәрә. Әлбәттә, бер-беребезгә ярдәмләшеп, күңел ризалыкларын алып яшәргә насыйп булса иде.

*“Игелекле нигез” исеме белән*

*“Татарстан яшьләрендә” (№6, 19.01.2013) басылды.*

# Матурлыкны тудыра белмәсәк, күрә белик.

Кеше фантазиясе искиткеч бай. Соңгы елларда ташландык вак-төяктән дә кирәкле нәрсәләр ясап куябыз. Күп сандагы гади кәгазь кисәкләрен (оригами) аккошка "әйләндереп" була. Бисер бөртекләре дә оста кулыннан үткәч, матурлык булып икенче кат туа. Язу өстәлемдә торган, Гөлсирин апа бүләк иткән сакура агачының һәр бисеры җемелдәп миңа "күз кыса": "Бушка үткәрмә вакытыңны, эшли белмәсәң - яз!", ди сыман... Кулдан ясалган һәр матурлыкка сокланам. Адәм баласы хыялын эшкә җигеп, юк кына нәрсәләргә икенче сулыш өрә дә, кабатланмас әйберләр барлыкка килә. Интернетта кулдан ясарганиләр генә өйрәтелми?! Аларны күргәч тә, ясап карау теләге туа. Кул эшенә осталык геннар буенча салынамы, әллә тормыш итү дәверендә хирыслык барлыкка киләме? Минем уйлавымча, балада яшьтән үк кызыксыну уятмасаң, эшләп карарга никадәр кызыктыргыч булса да, күңелне кул эшләре белән мавыгу хисе биләми. "Куллары белән матурлык тудырмаган хатын-кыз - идеаль хатын була алмый", диләр. Өеңдә тегү машинасы булып та (яки тегү машинасы алырга мөмкинлеген булып та) һәвәскәр тегүчегә чалбар балагы, күлмәк итәге бөктерергә йөргән хатыннарны мин аңламыйм. Балага ана бәйләгән оекбаш белән кибеттән сатып алган оекбаш аермасы да күп. Бәйләгәндә балаларыңа никадәр җылы хис салып, изге теләкләр теләп бәйлисең аны. Өй стенаңа үз кулың белән ясап куйган картина, шкафыңда торган сувенир да - караган саен нур сибеп, җылылык тарата шикелле; үзең бәйләгән башмак кию белән җан рәхәте өсти... Күзләрне иркәләрлек, күңелләргә шатлык тутырырлык матурлыкларны тудырырга яшьтән өйрәтергә кирәктер. Аулак өйләрдә осталык туплап, кул эше белгән әбиләребез бакыйлыкка күчеп бара. Әти-әниләр көн озын эштә, йә булмаса замана кешеләре - компьютер тирәсендә чуалучы, кул эше өнәмәүчеләр. Балаларыбыз компьютерга бәйлелек синдромы белән авырыйлар димәгән кеше сирәк. Авырыйлар дию дөрес тә түгел. Сәламәт акыл белән уйласаң, кем инде шундый мавыктыргыч "тартма" булганда бәйләп яки чигеп утыра. Димәк, замана шундый! Компьютерга исе китмичә, чигеп утырган кыз баланы күрсәм, сәер дип карар идем үзем дә. Бу җәһәттән мин үзем мәктәптәге укыту системасына зур рәхмәтлемен. Бу елларда мәктәптә тегәргә өйрәнү өчен кызларга тегү машинасына кадәр булды. Мәсәлән, минем әнидән калган зингер машинасы өйдә булмаса, кызларым бит аны хезмәт дәресендә генә күрү-тегү бәхетен татыйсылар иде. Ә кемгәдер шулай булды да ул!

Мин укыган елларда хезмәт дәресләре малайлар белән бергә алып барыла иде. Муеннан асылмалы сатин алъяпкычлар белән станок артында тимер шомарттык, фанерадан фигуралар кистек һ.б. Укытучыбыз Рамил абый эшне

сөяргә өйрәтте. Ләкин әйтерсең, сугыштан соңгы еллар һәм кара эшкә эшче куллар кирәк. Нигә ул елларда мәгариф өлкәсендәге галим-мөгаллимнәр, малайларны аерым программа нигезендә, кызларны аерым өйрәтергә фәрманга нигезләмә юлламадылар икән?! Сингапур алымы, тагы әллә ни диләр – педагог булмагач, мин аңлый торган түгел, ләкин ана буларак, мәгариф системасындагы мәгърифәтле акыл ияләре ни уйлаган икән дим, шул чакларны искә алганда. Без үскән елларда акыл ияләре нотык сөйләгәндә: “Кешене хезмәт тәрбияли”, дигән сүзләрне еш кулланалар иде. “Семья – җәмгыятьнең бер ячейкасы” дигән гыйбарәләр дә фәнни хезмәтләрдәге формаль сүзләр генә булган. Кул эше ихтыяри гамәл саналу сәбәпле, мәктәпләрдә кызларга өйрәтү кирәк табылмаганмы? Хезмәт дәресе – яшьтән үк тормышка әзерлеккә өйрәтү түгелме соң ул?! Сүз дә юк, ир балага да яшьтән тормышка әзерлек кирәк. Отверка тотып, шөреп тә бормаган малайлар әллә юкмы? Ярый ла әтиең булса яки үзе эш рәтен белсә?! Аз мени, капкасыннан ничә кереп чыкса да купкан рәшәткә, авышкан багананы “күрмәгән” ирләр? Алардан матурлыкка куела торган, машина покрышкасыннан “аккош” ясарын өмет итеп булмый, билгеле... Ә шулай да матурлыкны күрә белүчеләр күп. Кирәксенү, сорау булгач, гади профнастил дип аталган буялган тимер калайлардан киселеп ясалган тәрәзә йөзлекләре дә бизнеска әйләнеп бара. Менә бит, эш белсәң, файда да китерә. Тәрәзә йөзлекләре булмаган йорт тәрәзәләре керфек-кашсыз күз кебек тоела. Тәрәзәләргә йөзлекләр куйдыңмы, әйтерсең лә күзләр керфекләрен сирпеп карыйлар. Ләкин бер нәрсә бар, бу матурлыкларны күрергә күңел күзебез сукыр булмаска тиеш. Ансын инде, әлбәттә, Ходай үзеңә бирмәсә, ата-ана да, хезмәт укытучысы да бирә алмый. Әгәр, матурлык тудырга сәләт, теләк булмаса, һич югы, матурлык тудыручыларны, аларның хезмәтләрен хөрмәт итеп булса да, күңел белән матурлыкка омтылып булганын беләм мин. Ансына артык көч, тырышлык таләп ителми бит.

*“Т.Я” №13 (04.02.2014) басылды.*

# Онытырлык кешеләр түгел сез!

Ямьле җәйнең инде яртысы үткән икән. Сизмичә дә калдык. Үткән җәй корылык белән күңелгә хуш килмәсә, быелгысы, Аллага шөкер – шифалы яңгырлары явып үтә, кояшы да чамасын белеп кенә кыздыра. Ә мондый җәйләрдә бала-чага, яше-карты Кама ярында су коена, комында кызына иде. Тик, ни өчендер быел алай булмады ул.

Җәй башыннан ук, 2010 нчы елгы корылык сәбәпле, су ярлардан чигенгәнгә, ярларын яшел суүсемнәр басты, болганчык сулы дулкыннар какты. Су коенырга төшүчеләр пычрак суга керергә теләмичә, борылып кайта торды, аннары бер белгәч, Камага төшмәс булдылар. Яр буйларында бушлык – кызынучылар да күренми…

Бу гадәти булмаган күренеш – ил белән бергә, безнең авылга киләсе зур кайгыга кадәр шулай иде. Ә инде хәзер, дөнья бәһасе торырлык ике авылдашыбызны су йоткач, Кама ярларына аяк та басасы килми – андагы ярга каккан дулкыннар йөрәккә шом сала. Атна булды инде шулай…

Һәлакәткә юлыккан теплоходта апалы-сеңелле ике авылдашыбыз – Роза Хәсәнова һәм Фәния апа Миндубаева, алар янында тугандай булган киленнәре – Зөлфия апа Хәсәнова да бар иде. Ходайның рәхмәте белән, алар арасыннан бары Фәния апага гына исән калу насыйп булган.

Дөньяда булган бар бәла-каза, төрле һәлакәтләрне яңалык тапшыруларыннан күреп-ишетеп торабыз. Шул көннәрдә, алар өчен кайгырабыз, фаҗигага тарганнарны кызганабыз һәм… онытабыз. Ә монысы онытырлык түгел. Чөнки, үзебезнекеләр! Ә үзеңнеке – үзәктә һәрвакыт. "И-и, Ходаем, - дим, – иң якыннары – тормыш иптәше, балалар, бертуганнар, ата-аналар ничек түзә?!" Халык ничә тәүлек инде, соңгы өмет – гәүдәләре табылуны тели. Ниһаять, дүрт тәүлектән соң, изге күңелле авылдашыбыз – Зөлфия апаның, биш тәүлектән соң, чибәрлеккә тиңнәр булмаган, роза чәчәгедәй матур Роза апаның табылуы, йөзләгән кеше соңгы юлга озата килүе, аз гына булса да хәлне җиңеләйтте сыман.

Бу тормышта бар нәрсәгә ирешергә тырышабыз. Яшәешебез авылдашлар күз алдында, ә язмышларны үзең дә белмисең. (Ярый әле, белмибез!) Нигә шундый язмышлар языла? Болай булырга тиеш түгел иде бит! Яшәешләре белән сокландырган, үлемнәре белән тетрәндергән язмышлар… Күңелләр һич тә риза түгел! Изге күңелле, яхшы кешеләр иде бит алар. Нигә яздың икән шундый язмышлар, Ходаем?! - дип күңел сыкранды.

Роза апа яшь белгеч буларак, терлекчелектә хезмәт юлын башлап, яшьлегендә Казан каласына киткән. Лаеклы ялга чыккач, авылда өй салып яши башладылар. Шундый яшь күренгән, матур Роза апаны ипле-җайлы гына сөйләшүләре белән күз алдына китерәм…

Зөлфия апа, Хәсәновлар гаиләсенең төпчек уллары Исхак абыйга кияүгә чыккан. Яшь буын аны күрше авылдан килен булып төшкәнен белми инде – 35 елга якын Имәнкискәдә ул. Шушы еллар эчендә ул күпләр өчен үрнәк була алды. Шәфкатьле, сабыр, акыллы, мөлаем – бу сыйфатлар буенча аңа тиңнәр аз иде. Таркалган «Маяк» колхозында, авыл көнкүрешендә, гомумән җәмгыятьтә тырышлык күрсәткән актив хезмәткәрләрнең берсе иде ул. Колхоз тулы көчендә булганда, өлкән хисапчы иде. Сәгате-минуты исәптәге хезмәттә, шуның өстенә, район киңәшмә-җыелышлары, отчетларыннан кайтып кермичә эшләгән елларында да соклана идем аңа. Бит ул елларда шәхси хуҗалыкларда икешәр сыер, казы-үрдәге, дигәндәй. Шул кадәр хуҗалыктан тыш, олы яшьтәге авыру каенана, каенатаны кадер-хөрмәт итүе, ир хатыны, ике бала анасы булуы; кунакчыл йортның уңган хуҗабикәсе, зур коллектив белән идарә итүе дә – барысына да аныңча кешелекле, олы йөрәкле булып калу – һәр кеше булдырырдай эш түгел. Кайната-кайнана да озын гомерле булдылар. Аларны да кадерләп мәңгелеккә озатты ул.

Колхозлар таралгач, Зөлфия апаның көчле булуы, җаваплылыктан курыкмавы зур эшләрне җиңеп чыгарга этәрде – хуҗалык товарлары кибете ачты. Һәлак булуына санаулы көннәр калганда, «Иркә» дип оныгы исемен элмә тактага – кибетенә куйдырды. Күпме авылдашына авыл хуҗалыгы кредитларын юлларга булышты. Уйлап куям: бигрәк өлгер кеше булган икән. Ә үзе һич ашыкмас кеше кебек – каудырланмас, җай белән эшләр иде. Бар нәрсәне акыл белән хәл иткән икән. Имәнкискә сайлау участогы комиссиясен дә ул җитәкли иде. Сайлау – бик җаваплы, авыр хезмәт! Ул булганда, курыкмыйбыз! Чөнки Зөлфия апада белем, сабырлык, яхшы оештыручанлык хәттин ашкан. Без аның канаты астында үзебезне яхшы хис иттек. Хәер, аның янында һәрчак рәхәт иде. Кибетенә кергәч тә, нурлы йөзе тагын балкыр. Өендә кабул иткәндәй, «Әйдә, әйдә, уз!» – дияр. Шундый кибетчедән ничек товар алмыйсың?! Җылы карашын тоеп, аның да күңелен күрәсе, бүген үк кирәк булмаса да, берәр нәрсә алып чыгасы итәсең. Сагынып сөйләргә калганын кем уйлаган?! Кайда гына булмасын, авылдашлары белән аралашуы да туганнарча аралашу кебек, бик самими, искиткеч матур иде. Ә бит тормыш катлаулы! Төрле хәлләр була. Ә ул һичкайчан берни белгертмәс – гел елмаер, итәгатьле сөйләшер иде. Сөйкемле

булуы өстенә, эчке матурлыгы да күңеленә сыя алмыйча, ташып чыга иде микән?!

Матурлык дигәннән, 2003нче елда авыл мәдәният йортында «Матурлык турында матур кичә» дип исемләнгән зур кичә үткәрдем. Анда эчке матурлык белән үзләренә җәлеп иткән, хөрмәткә лаек авылдашларымны кунак итеп чакырган идем. Үтә дә тыйнак икәнен шул вакытта белдем. Чакырсам да, килмәде. Соңыннан сөйләшкәч, шул тыйнаклыгы комачаулаганын аңладым. Ул тыйнаклыгы аны шулкадәр бизи иде.

Ә үткән ел, авылыбызның җәмгыять тормышында күп көч салган, көчле ихтыярлы хатын-кызлар белән «Без көчлебез» дип исемләнгән кичә үткәргәндә, ничек итсәм иттем – тыйнаклыгын да тәнкыйтьләдем (ачулана, үпкәли белми иде). Күп тапкырлар чакыргач: «Кеше сүзен аяк астына салмыйм», диптер инде - килде. Сөенеп бетә алмыйм хәзер: сәхнә түренә утыртып олыладым, кичә барышында башка кунаклар кебек, аны да бәяләдем, сораулар биреп, тамашачы каршында бар яхшы сыйфатларын ачып салдым. Ә тыйнаклыгы шул кадәр күзгә бәрелә – «көчсез зат» диярсең, әгәр тормыш рәвеше белән таныш булмасаң. Ә тамашачы риза иде, чөнки – чынбарлык! Күңеле булды: зур рәхмәтләрен белдерде. Кеше үзе исән чакта бәяли белсәк иде шул. Вафатыннан соң да яхшылыкларын сөйләп бетерә алмадык. Сокландыргыч кеше иде. Роза апа турында да бары матур хатирәләр калды.

Күңелләрдә мәңге сакланырсыз сез, Матур апалар! Менә бүген дә, Зөлфия апа урамнан үтеп китәр дә, мин исәнләшергә өлгергәнче үк: "Исәнме Гүзәл!", дип кояш күк елмаер, көн тагын да ямьләнер төсле. Күңел әле һаман шуны көтә.

*"Безнең гәҗит" №28 (20.07.2011) басылды.*

# Китек язмышлар

Кама ярына төшкән саен, дулкын юып каккан төрле төстәге ташларга карап уйга калам. Күп еллар, юллар үткән бу эреле-ваклы ташлар нигәдер бар игътибарымны ала. Учларыма алып сокланып карыйм аларга: һәрберсе үзенчәлекле: ялтыравык һәм матурлар... Хәер, арада тоныклары да бар икән.

Нишләптер, шушы ташлар белән кешеләр арасында уртаклыклар бар күк тоела. Мизгел эчендә хәтердә авылдашлар, аларның язмышлары яңара...

“Йөргән таш шомара”, диләр. Тормыш дигән диңгезне кичә-кичә “шомармый” булмас, билгеле! Авырлыклар алдында бөгелмәскә нык ихтыяр көчләре кирәк! Кирәген – кирәк тә, ә каян аласы аны?! Ишелеп төшкән кайгы-хәсрәтләргә, яман гадәтләргә бирешкәндә тормыш төпкеленә батасың, әгәр акылың белән ихтыяр көчләре юлдаш булмаса. Бер баткач чыгулар, ай-һай... Әле өстәп, язмыш дигәне дә рәхимсез әвәли, кайчак. Мине әнә шул язмыш сынауларында сынмаска тырышканнар сокландыра. Чебен кадәр проблеманы телдә, фил кадәр күпертеп, шул ялганга кеше ышандырып йөргән пүчтәк кешеләр белән очрашканда кәеф төшә. Уйларым үзеннән-үзе, яп-яшь көе дөньялыктан киткән Алия Сәляхова-Габитова барып тоташты. Сабырлык - гомер итү дәверендә туплана, диләр. Алиядә сабырлык, ихтыяр көчләре бар иде үзе.

...Тулы матур гаилә иде. Әти-әниләре эштә булганда, энесе белән икесенә “күз-колак” булырга әбиләре дә бар иде. Әбиләре дә, этиләре дә бер-бер артлы үлеп киттеләр. Әниләре Минзифа апа авылда көчле хатыннардан саналды. Эшләп тә хезмәт хакы түләнмәгәндә, авырлыклар белән терлек асрап, 2 баланы үстерде: кызы Алияне укытты, улы Раилне армиягә озатты. Кайгы-хәсрәтләрне никадәр акыл-сабырлыклар белән үткәрсәң дә, адәм баласы кичерешләре эзсез үтми икән. Раил армиягә киткәч, санаулы айлар эчендә яман чирдән кызы кулында үлеп китте ул. Алиянең кичерешләрен үзе кичергәннәр генә нечкәлекләре белән тоядыр. Ә кичермәгәннәр өчен дәвамы болаерак була. Туган йортында бер үзе яшәп, энесен армиядән кайтуын көтеп алды. Ул кайткач, 1-2 ел эчендә туганнар булышлыгы белән абзар-гараж салдылар. Мөлаем, якты йөзеннән нур чәчеп, кибеттә дә, мәктәптә дә эшләп алды, Алия. Ничек итеп “йота”алды икән хәсрәтен, дим. Чытык йөз, яшьле күзләр күрсәтмәде – гел елмаерга тырышты. Балык Бистәсеннән Марат исемле егет, Алияне күрү белән тиз тотты – берничә айдан өйләнешеп тә куйдылар. Ятим булгач, кызгангангамы: пар, бәхетле гомерләр теләп, Шумково авылына озаттык. Тик бәхете озакка булмаган – язмыш тагын зур сынау әзерләгән. Йөрәк астында йөрткән нарасые туганчы ук, газраилгә җанын тапшырган шул. Катлы-катлы хәсрәт кичерүләр – ташка бер кайнар, бер салкын су сибеп чатнатуга тиң, ахры. Әйе, таш булып таш чатный! Кеше күңелен ташка тиңләү мөмкин түгел. Бик нечкә хисле шул без. Алиябез бер ай эчендә хәсрәттән сызып, улы артыннан мәңгелеккә китеп барды. Ямьле май иде ул. Алия дә май кояшы күк ягымлы иде...

...Учымдагы ташлар да шома өсле, ялтыравык булулары белән генә матур икән шул. Китек булсалар бер дә алай матур күренмәсләр иде. Кеше язмышлары даербөтен, шома, матур булса иде икән.

*"Безнең гәҗит" газетасында (17.07.2013) басылды.*

# Рәхмәт сиңа, әни!

Туганнарны төп нигез, авылда төпләнеп калган гаилә берләштерә. Бергә җыелулары бик рәхәт. Шатлык-кайгыларны уртаклашу, ир һәм хатынның ике якны да яратып, тигез күреп туганлык хисләре белән яшәве – ананың баласына биргән олы тәрбиясе ул! Мин дә әнигә бик рәхмәтле! Үзе вафат булганнан соң да, без – туганнарны берләштерердәй хис-тойгы, кайгыртучанлык хисләре биреп калдырган. Әнинең якты хатирәләре, сокландыргыч эшләре, үрнәк гамәлләре, авырлыкларга бирешмәс көчле ихтыяры безгә маяк булып, юл күрсәтеп тора.

Әни дигәч, күп вакыт йомшак табигатьле, иркәләүче ананы күзаллыйбыз. Безнең әниебез, киресенчә артык иркәләп тормады һәм бик таләпчән иде. Тик, үзе исән чакта аңлап бетермәгәнбез: барлык кисәтүләре, әрләүләре урынлы булган. "Әни, гел әрләмә инде! Мәзәктәге Хуҗа Насретдин күк чүлмәк ватканчы ук "кыйныйсың"!" – дигән чаклар булгалады. Ә ул: "Чүлмәкне ватканчы кирәк шул, ваткач, соң була", – дия иде.

...Бөтен урам бала-чагасы бергә җыелып туп уйныйбыз. Тубы да уйнап туймаслык шул. Кунак кызы шәһәрдән алып кайткан! Ә минем тубым бөтенләй булмады. (1980 нче елларда авылда азык-төлек кибетләре генә эшли иде.) Уйнап арыгач, Камага су коеныргa төшеп киттек. Тупны исә, юл уңаендагы безнең мунча чоланына куеп калдырдык. Шул көе туп турында онытканбыз да. Ята шулай туп чоланда, мине кызыктырып. Берничә көннән, түзмәдем, урамга алып чыктым. Дус кызлар: "Туп алдылармыни?" – дип кызыксындылар. Мактанасым килде микәнни, әйе, дидем, горурланып, әни Казаннан алып кайтты, дип тә өстәдем әле. Авылда сүз тиз йөри: әнинең "Казаннан алып кайткан тубы" турында кызлар әбиләренә җиткергәннәр. Икенче көн, иртән (авыл кешесенең "иртә"се бик иртә бит аның!) әни мине йолкып диярлек уятты: "Тупны каян алдың?" Дусларыма әйткән сүзләрем исемә төште, үзем акланырга сүз уйлыйм... "Хәзер үк тор! Бар, хуҗасына кертеп бир!" Тордым... Тупны күршеләргә

керткәндә кызарып беттем. Көтү куып кайтып килүчеләр, әйтерсең бу турыда беләләр һәм күз карашы белән каезлый иде күк...

Әбисенә кайткан кунак кызы тупны бездә калдырган көнне үк китеп барган. Тик тупны үземнеке итәргә уемда да булмады ләбаса. Ә әниемнең каты тәрбиясе гомер буе иярә килде: "Кеше әйберенә кагылма! Үзеңнекен, рөхсәтеңнән башка алдырма!" Хәзер дә мин әни күрсәткән юлдан яшәргә тырышам. Кайсы вакытларда: "Тукта! Болай итмим әле, әни рухы риза булмас!" – дип тыелып калам. Әниләр тәрбиясеннән читкә тайпылмасак иде. Әниләр туры юл күрсәтүче, бары алар гына гадел хөкем итүче .

*“Ватаным Татарстан” № 222 (31.10. 2009) басылды.*

# Килешү кирәкме?

Быелгы җәйдә авылым урамыннан үткәндә, Хәлил абыйларның капка астыннан чыккан йонтәс этенә сары гына бер мәченең сарылып торганын күргәч, аптырап киттем: “Менә сиңа, мә - эт белән мәченең гомерлек дошман дигәннәре, минәйтәм”. Мондый күренешне беренче күргәнгә, муеным борылып беткәнче шул якка карап бардым. Күргәнем чын – шулай янәшә бер-беренә сыенып калдылар. Кайттымда бар эшемне калдырып, язма язарга тотындым. Бераз язгач, теләк сүнде – җан ияләре арасында иң югары аңлы зат – кешеләрнең, юк-бар сәбәп белән дошманлык эзләп, күрәлмас дәрәҗәгә җитүләре күңелгә килде дә, җирәнү хисе туды. Кәгаземне учыма йомарладым...

Ләкин бу темага әйләнеп кайту насыйп булган икән әле. Көзге урман карарга бардым да, анда соклангыч агач күреп, уйларым тагы шуңа барып тоташты. Кая барсам да, фотоаппаратны үземнән калдырмый идем, ни хикмәт, исемдә булып та алырга теләмәдем. Югыйсә, төшерә идем бит! Кемгә ничек күренәдер, миңа бик үзенчәлекле тоелды ул. Янәшә үсеп чыккан ике яшь юкә бер-берсен әйләндереп кочаклаганнар. Тирәли әйләнгәләп, бармакларым белән araларына тыгылып карадым, шаккатмалы - ничек шулай аерылгысыз үскәннәр?! Чыбык кебек нәзек чакта берәрсенең “кулы кычытып” борып, үреп

китте микән? Ничек булса – булган, бер-берсе белән килешеп, ярашып үсеп утыралар. Агачларның телен аңлау мөмкинлекләре без - кешеләргә бирелмәгән. Тереклек диеп, тирән уйларга бирелсәң – бу юкәләр дә, бер туфракның суын бүлешеп эчеп, ачы җилләрдән бер-берсен ышыклап, бозланып катарлык салкыннарда бер-берсен җылытып ярдәмләшәләрдер. Ә җәйнең талгын җилләрендә яфракларын лепердәдеп серләшәләр күк тоела. Бу - табигый ярашу! Без – кешеләр дә ярашабыз, килешәбез, җайлашабыз... Үземчә фикер йөртеп, әйләнә-тирәне аңларга тырышам, кешеләрен гыйбрәт өчен генә бәялим.

...Кызу канлы кешеләрнең холкына - сабырлыклар белән, даими эчкечеләрнең гамәлләренә - бармак аша карап үткәреп җибәрергә була. Акылы сәламәт булмаганнарның начар гадәтләрен авыру сәбәпле, хәер-хаклы буларак гафу итсәк, игътибар үзәгендә булу өчен ызгышырга яратучыларга – икейөзләнеп ярашып; сүзен өстен итәсе килүчеләргә - сүзләрен хуплап яраргa тырышабыз. Дан-шөһрәт, мактауларга хушы китүчәннәргә - ялагайланып килешүгә ирешергә була. Шулай ярашып-килешеп яшәүчеләр күп безнең арада. Һәркем куркынычсыз, тыныч, уңайлы яки төшемле яшәү өчен үзенчә җайлаша. Һәркемнең үз эше, үз күңеле! Тик менә күңеле мәкер, көнчелек белән янган, шул сәбәпле кеше күралмас дәрәҗәгә җиткәннәр белән ничек килешәләр дә, андыйларга ничек җайлашалар - һич аңлый алмыйм. Һәр кеше – Кеше. Һәркем үзен кешегә саный: түбәнлеккә төшкән адәм дә, дөм сукыр да, хәтта җинаятьче дә... Гомер юлында аралашырга, янәшә барырга туры килсә, алар белән дә килешергә тырышып яши күпләр. Кешене кешегә санамыйча, һаваланып йөрүчән кешеләр белән ничек килешәсе? Мин, мәсәлән, борын чөйгән кешеләр белән уртак тел табарга теләү түгел, бер сукмактан да йөрергә теләмим. Шәригать кануннары буенча, адәм өч көннән артык ачу-үпкә сакларга тиеш түгел. Дошманнар белән килешергә куша китап. Үзеңне түбәнсеткән, кешегә санамаган кеше белән күнел ничек ризалашсын инде, йә? Ярашырга тырышып, тагында түбәнлеккә төшергә кирәкмидер, минемчә. Тик шулай да, эт белән мәче дә килешәләр, бер-берсенә комачаулап үскән агачлар да җайлашып, үрелеп үсәләр. Ә кешеләр горур булып чыгамы, бу очракта?!

*Кыскартылып "Тат. яшьләре" №40 басылды*

# Алкышларны җәлләмик!

Үзешчән сәнгать осталары белән күп аралышырга туры килде. Күңелләре белән гадиләр алар. Халыктан үзеңне бер баш өстен тотканда, җаның-тәнең белән бирелеп җырлап та, биеп тә, гармунда да уйнап булмыйдыр ул. Сәнгать өлкәсендәге бизнесменнар турында язуым түгел, авыллардагы, үзебезнең арада яшәгән талантлар турында язам. ”Коры” алкышларга сөенеп, авылдашларының күңелен мәдәни сугарган актив кешеләр күп булмаса да, бар. Бу сәнгать сөючеләргә талантларын бәяләп акча түләү бер җирдә дә каралмаган, чыгышларга бәя – әлеге язып үткән алкышлар гына. Аларның тамашачылар каршына чыгу өчен күпме чыгым тотканын уена да китермәүчеләр бардыр. Күлмәген, туфлиен ала. Чәчне матурлау өчен генә дә күпме акча китә?! Косметика чыгымнарын, бижутерияне вакланып санап тормыйм инде, ярар, булганын куллана дип саныйк. Болар - үзешчән сәнгать остасының сәхнәгә бер чыгып керү өчен, ә зурлап язсам – күңелләрне җилкетеп бер җырлаганда, биегәндә тамашачының кәефенә тагы да яхшы тәэсир калдыру өчен матураю.

Берчак үсмер балалар түгәрәгенә яңа бала кушылды. Һәр хәрәкәт, мимика, һәр сүз басымы өстендә эшләгәнгә сабырлыгы төкәнмәде: “Монсында гына катнашам да, башка килмим”, диде. Чынлыкта шулай, һәр чыгыш нечкәләп өйрәнелә, шулай әзерләнеп тә каушау һ.б сәбәпләр белән алар юкка да чыгарга мөмкин - профессионаллар түгел бит! Шул чактан балаларга: “Гел сәхнәдә йөрмәссез, тамашачылар арасында булганда , алкышларыгызны беркайчан да җәлләмәгез! Чараларның авырлыклар аша, ничек әзерләнгәнен белеп үсәсез менә. Чыгышлар нинди генә булмасын, авылыбыз сәхнәсендә акча эшләүче “әртистләр” түгел, сезнең кебек үк тырышып, халкын хөрмәт итеп чыгыш ясаучылар торганын онытмагыз! ” – дип әйтә килдем. Ә авыл җирлегендә талантлар күп булалар. Кемнәрдер, җыр-биюгә сәләтле булып та, әзергә–бәзер рәхәтләнеп йомшак урындыкларда бәйрәм кәефенә төренеп, җыр-моңнар тәэсиренә изрәп, рәхәтләнеп ял итә беләләр. Ял итүләр ваемсызлык белән аралашмасын иде ул. Югыйсә, “алкышлыйм дип кул чапсам, арып китәрмен” дигән күк, кулларын кушырып утырган тамашачылар да бар. Шуны күреп йөрәгем әрни минем. Ошаткан чыгыш, ошатмаган чыгыш та була - сүз дә юк. Ләкин үзешчән сәнгатьне әйдәп баручыларның максаты бәйрәм кәефе өстәү, күңелле, файдалы ял иттерү, ә тамашачы шул кадәр хезмәтне рәхмәт белдереп алкышларга тиештер бит?!

*“Т.Я”да басылды.*

# Сабыр канатларыгыз сынмасын!

Кәефсез хатын, кая сугылырга, нишләргә белми әрле-бирле йөренде, туктаусыз сөйләнде:

-“Бер тынычлыгым юк! Улымның дусты ансат кына бәхеткә тиенде: берәүләрнең бердәнбер кызын эләктерде дә, туйга квартир ачкычын бүләккә алды, – кайнарланган башын тәрәзә пыяласына терәде, ерта язып изүен ачты. - Уф, кайный монау җирем! Кирәкме, бу күрше хатын бер айда йорт салып керде? Үләмм, каян тапты икән шул кадәр акча?!.. – стенка буйлап әрле-бирле йөренде, “шап” итеп креслага ауды, нурсыз күзләрен түшәмгә төбәде. Ә уйлар тынгылык бирмәде, - “Да-а, кыз да утызда”, дигәнме, берәү? Ээ, ник бер егет килеп сүз кушсын үзенә. Ә боларның әле мәктәп бетергән кызларын кычкыртып, лимузинга утыртып алып киттеләр. Шашып үләрсең, безнең кыз күк матур киенсә иде ичмасам, – кечкенә мендәр стенага сыланды. - Башым гөжли, кан басымым уйный, ахры... Уф, тәгәрәп китсеннәр лә, балакайларым сау-сәламәт, югары белемнәре, яраткан эшләре бар. Ирем хезмәт хакын тиененә кадәр алып кайтып учыма сала, йортыбыз ишегалдында 3 машина - кеше алдында ким-хур түгел, ансы... Күрмим дә, бүтән исем дә китмәячәк! Бер-ике төймә дару кабыйм да, ятып торыйм... Кара, каян исемә төште әле: боларның малайлары дисертация яклап маташа диме?! Аспирантура тәмамлап, зур кеше булмакчы инде?! Тагы косасымны китереп, телевизордан күрсәтерләр инде, сөймим шуны! Уф, битем яна, файдасы булмады ахры, бу төймәнең. Беләләр инде мине-е. Тыныч кына, күпне күрмичә яшә, диләр. Булмый шул, булмый, – хатын колакларын сагайтып, тәрәзә буена килде. - Лебер-лебер кемнәр сөйләшә анда? Бәтәч, каршы күрше нәкъ безнеке шикелле машина алып кайткан!!! Иии, нәкъ безнеке шикеллене алмаса, беткән иедер инде машина. Тагын бөтен кәеф кырылды. Тукта, бәлки безнеке күк кыйбатлысы түгелдер әле. “Матур булган!”, дигән булып, тикшереп киләсе булыр. Юкса, уф... чыдый торган түгел! – Яшь хатын элгечтәге курткасын йолкып алып урамга атылды...

Беркемнең дә гамь казаны буш булмас, ди. Кемнең казанында ни кайный бит?! Бар тормыш җитеш булып та, матур гына гомер кичерергә әнә шундый “кысыр” хәсрәтләр тынычлыкны бозарга бик мөмкин. Тормышта азга да канәгать булып яши белүчеләр - бәхетле кешеләр, ахрысы. Дөнья малыннан өстен булып, сабыр канатларын сындырмыйча, язмышка риза булып яшәүчеләр сокландыра мине. Ничаклы акыл, инсафлык аларда. Авырлыклар алдында сынмаган авылдашларыма карап, аларга карата хөрмәт хисем яңара. Җае чыккан саен, нинди юл белән булдыра алам - шулай бәяләргә тырышам аларны. Аздан да

күңел була. “Яхшы сүз дә сәдака”, - ди бит. Ә сәдака тиеш, тиеш аларга! Дөньяда иң ачы хәсрәт: балаларыңны мәңгелеккә озату. Әнә шул аналар турында язасым килә.

...Хәсрәт адәмне түбәнсетми, ахры, киресенчә кешелек дәрәҗәсен сыный. Тормыш мәшәкатьләреннән туктатып, уйга сала, дөньялыкның асылын ача. Кайгы килгәч, кемдер кешелек дәрәҗәсеннән түбәнгә тәгәри: исерткеч белән “онытылырга”, башны элмәккә тыгарга - шулай авырлыктан котылырга уйлыйлар. Бары, ихтыяр көче нык булганнар гына - тормышның вак, пычрак саналган уй-хисләреннән ерак торалар. Гаиләгә килгән хәсрәт, илгә килгән яу - тетрәндергеч хәлләр. Ярый әле тыныч илдә яшибез. Бөек Ватан сугышы әле дә күңелләрдә яңара - аны сугыш ятимнәре йөрәгендә саклый. Безнең Имәнкискәдән генә 147 яшь кеше гомере киселгән. Йөзләгән ана дигән сүз бит бу! Кемдер, ике-өч улын югалкан. “Ходай, күтәрә алмас кайгы бирмәм” дигән, диюен... Гайшә аптый дип йөртәләр иде без кечкенә чакта, Кәдим абый әбисен. Дөньялыктан картлык белән киткәндер ул - мин белә-белгәннән бик карт иде. Шул әбинең ире үлгән хәбәре килү өстенә, өч улыннан да кара кәгазь генә килгән. Ачы хәсрәт! Күтәрә алган бит, тик ничекләр итеп?! Эшем белән бәйле рәвештә күп истәлекләр тупларга туры килде. Әминә әби, бер атна эчендә кызамык ише авырудан, 4 баласын җирләгән. Ул да картлык көненә кадәр гомер кичерде. Аракы белән дә басмаганнар кайгыны, элмәккә дә тыкмаганнар башны... Әллә җиңел булганмы, катлы-катлы хәсрәт кичерү? Сугыш - сугыш инде, сугышның бар мәгънәсе җан кыю. Шуңа да өлкән буын, дога саен илгә-көнгә тынычлык тели. Ә менә безнең буын күреп белгән Мөкәтдисә апа шушы тыныч елларда да, тормыш корып балалар үстереп, яши генә башлаган өч улын мәңгелеккә озатты. Бәгыреңнән өзелеп төшкән бер түгел, өч бала бит ул! Берсен югалту да зур фаҗига. Кайдандыр укыган юллар исемә төшә: ”Үзе исән чагында балаларын гүргә иңдергән ана, туры җәннәткә бара!” Урыннары җәннәттә булсын! Дөньялыкта шул кадәр әрнүгә түзеп яшәгәннәре өчен җәннәт тиештер... Сабыр да, акыллы да соң безнең әниләребез. Ник бер ана кеше алдында сыгылып төшсен?! Кычкырып елау юк. Ризасызлык күрсәтеп, Ходайга тел тидерү юк. Сәгъдиева Әминә, Гәрәева Зәйнәп, Фәттахова Хәтирә, Шакирова Рабига апалар икешәр балаларын җирләделәр инде. Бер баласын җир куенына салучылар тагы да күп. Бу әбиләрнең сабыр, күркәмлекләре күзалдына килеп баса. Аналар башыннан никадәр хәсрәт үтә... Рабига апа шул кайгыларын кай җиренә яшереп йөртә торгандыр. Урамда очраган үз чордашларына гына түгел, яшьләргә дә, йөзен балкытып күңел җылысын кушып сөйләшүләрен - беркайчан онытмам. Үзеннән, үткән вакыйгаларны сораша башласаң, берничә җөмлә әйтү белән, онытам да мин дип, тиз төгәлли. Онытмый, онытамы соң?! Үз тирәсендә уңай

хәлләр генә сөйләргә күнеккән ул. Газиз балаларына атап чыгарган шигырьләре күңел түренә йөри аның. Урынлы булган җирдә,  бик кадерле ядкарь итеп сөйли ул аларны, исләрем китеп тыңлап торам:

*Өй түрендәге миләшнең*
*Бер чемен дә өзмимен.*
*Балаларым җыелгачтын*
*Нурисламымны эзлимен.*

*Урамымның чирәмнәрен,*
*Таптыйсың калган икән,*
*Гомерсезлегегезне белсәм,*
*Тапмыйсым калган икән.*

*Урманнарга менгән чакта*
*Өзеп алдым бер балан.*
*Үзәкләремне өзәдер-*
*Ятим калды бит балаң.*

*Яфраклар селкенәдер,*
*Әкрен җилләр искәндә,*
*Үзәкләрем өзеләдер*
*Балаларым искә төшкәндә.*

*Аклы ситса күлмәгеңне*
*Кызым, якаларын мин уйдым.*
*Җитмеш җиде яшемә җиткәндә,*
*Икенче баламны гүргә куйдым.*

Ә мин вакыты белән, күптән түгел суйган сыерыбызны сагынып йөрим. Әллә кайчан үлгән этебезне искә алып, күзләремне яшь пәрдәсе каплый да, сабырлыкка үрнәк аналарны искә төшереп, бик тиз шым булам. Күрмәгәннәргә ачы хәсрәт бирмәсен, күргәннәргә сабырлыклар бирсен, Ходай!

*Кыскартылып, “Т.Я” №69 ( 08.12.2012) басылды.*

# Барыбыз да язмыш кочагында

Бәйрәмнәр җитүгә таба, нидер эшләргә кирәк дигән уй белән яшим. Ияләнгән гадәт. Халыкара инвалидлар көне җитә. Бәйрәм дип атап булмый инде,

шулай да югары даирәдә утыручылар хөрмәт йөзеннән, календарьга билгеләгәннәр икән – рәхмәттән башка сүз юк! Инвалидлар декадасында масса-күләм чыганакларда бу турыда сюжетлар күрсәтерләр, якынрак тормыш итүләре белән кызыксынып, ярдәм итү юлларын эзләрләр, социаль яклау органнары - игътибарларын арттырырлар, шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыклары искә алып бүләкләр белән күңелләрен күрерләр... Ә мин кулга каләм алып, мәкалә сырламакчы булдым. Тик язуы гына читен: ни котлап булмый. Җылы сүз, якты караш, изге теләкләр белән алдагы санап үткәннәргә кушып – менә шулдыр инде, елга бер.

“Инвалид” сүзе күңелдә әллә ни авыр хис уятмый кебек, ә татарчага тәрҗемәсе күңелгә энә күк кадала. Гарип! Гарип дигәч, гариплеге күзгә ташланган кеше күзаллыйсың. Бу төркемгә кемнәр генә керми: сукыр, чулак, шикәр чирле, чукрак, аксак, акылсыз, хәрәкәтсез урын өстендә ятучы да... Барысын да уртак хәсрәт берләштерә – сәламәтлек җитми яки бөтенләй “ташка үлчим”. Гариплек бер дә рәхәт нәрсә түгел, үземнән беләм! Хәзерге вакытта, белешмәдә генә инвалид булып саналучылар күп булу сәбәпле, гарипләрне эшләмичә, акча-керем алучылар дип тә карыйлар.

Чынлап торып гариплеккә чыккан кеше беркайчан үзен мескенгә санамый - башкаларга комачауламаска тырышып, уйларына бирелеп, Аллаһы Тәгаләгә сыгынып яши. Кешеләрнең начар мөгамәләсе белән күп тапкырлар очраша торгач, кешеләргә ышанычы кими. Төптән уйласаң, җәмгыять гарипләрне күпмедер дәрәҗәдә чит итә. Тәкәббер җаннар, кимсетүле караш ташларга, йөз чөерергә, хәтта гамәлләреңнән кычкырып көләргә дә (!) уйлап тормый. Аңларга була, табигать закончалыгы бу! Хайваннар дөньясында шулай бит. Биш еллар элек сарыгыбыз ике бәрән китерде. Берсе аеруча матур: аклы-каралы, үзе шаян да. Тәҗрибәле карт сарык шул бәрәнен имезмәде, чит итте. Анысын кызларыбыз, бик яратып, шешәдән имезеп үстерделәр. Үстерделәр дим, үсмәде шул - кәрлә булды. Димәк, сарык аның гарип булуын тугач ук белгән: ана буларак, интегеп гомер итмәсен дип, инстинкт буенча юкка чыгарасы килгән. Аларда сиземләү сәләте көчле шул. Киек җанварлар арасында да шул: имгәнгән, авыру хайванны ашап, аны юкка чыгаралар. Үзләренчә, яхшы гамәл – санитар ролен үтиләр. Тик, без - кешеләр ич!!! Сиземләү сәләте көчсезрәк булса, акыл сәләте югары. Гарипләр белән аралашуы читен булса да, гарипләр дә кемнеңдер кадерлесе. Исләрем китә, кайберәүләр үзләрен гарипләрдән өстен булуын раслап, үзен түбәнсетә. Сәламәт кешеләрнең гарипләрдән өстен булуын сүз-гамәлләр белән расларга алыну - рухи гариплекне аңлата түгелме соң? Көрәш мәйданына үз кимәлеңдәге көрәшче белән чыгасың бит. Шул чакта гына көрәш ”чиста” була.

Гарипләрне кыерсыту күпкә җиңел, чөнки начарлыкка - начарлык белән түләми, бары рәнҗи генә. Мин үзем тирән кереп китеп, кешелек дөньясындагы гариплекне ике төргә бүләсем килә: берсе тән гариплеге, икенчесе сәламәт булмаган күңел дөньясы. Авыру күңелле тагы да куркыныч: күпме кешенең күңелен яралый. Дуамалланса тән җәрәхәте дә ясарга мөмкин. Читкә китмичә, сүз белән яралау турында язасым килә. Тән ярасы төзәлә, ә күңел ярасы күңелдән китми. Чынлап та, сүз ул зур көчкә ия. Яхшы сүз генә җанга дәва. Киресенчә булганда: " Кеше сүзе - кеше үтерер", - ди бит, халкыбыз. Күңел "гариплегенә" көнчелек, фәхишәлек, угрылык кебекләр дә керә. Моның ише нәрсәләрнең берсе генә күңелеңдә булдымы – үзе дә тынычлык күрмәс бәндә, тирә-юньдәгеләр дә... Ялгышлык булып, тәүбә итмәгән очракта, моңа да дәва юк. Чир китә, ә гадәт кала.

Инвалидлар сәламәт кешеләр эшләгән хезмәтләрне дә алып барырга, җәмгыятькә файда китерергә тырышалар. Хәтта артыгы белән! Чөнки гомернең һәр мыскал вакыты кадерен, тормышның ямен дә, эшнең тәмен дә беләләр алар. Күңелләрдә ниндидер изге омтылыш бар...

Телевизордан аяк-куллары хәрәкәтсез кыз-баланың авызына карандаш кабып рәсем ясаганын күрсәткәннәренә әллә кайчан инде. Мондый мисаллар күп, аларны күргәч, сөбханалла, дияргә генә кала. Теләк, тырышлык, омтылыш – чикле мөмкинлекләрнең киртәләрен җимерә. Кемдер аны, ике кулы, таланты булып та ясамый.

Төзек булмаган кампитр-ноутбугларыбызны кочып авылдашыбыз Әсләм абый йортына ашыгабыз. Беркайчан кире бормый. " Күземә нагрузка килә!"- дип үз бәясен күтәрми. Киресенчә, рәхмәткә эшли ул аларны...

"Т.Я" да, 4-5 еллар элгәре Миләүшәнең саллы язмалары басыла иде. Җир җимереп эшләп йөргәндә, автохәләкәттә гарипләнеп калгач, тормышка башка күзлектән карап язылган язмалары беркемне дә битараф калдырмагандыр. Ярдәмләшеп яшәгән дуслар, гарипләнгәч юкка чыгалар шул. Инвалид янында басып тору да гарьләндерергә бик мөмкин. Чын дуслык ярдәмгә мохтаҗ булганда сынала.

Чын гарипләр беркайчан зарланмый. Зөһрә әби кибеткә, медпунктка акрын булса да үз аягында, сукмакны күзлексез күреп, авылдашларының барсын да танып сөйләшеп килеп җитә. Аны караучылар бар. Тик ул бары үзенә генә ышанучан, көчле холыклы иң өлкән авылдашыбыз. "Имгәк инде мин. Бүген кулым бер дә җылынмый, тотып кара әле, кызым!"- ди, беркөнне. Хәленә кереп кулын җылыткандай итәсең итүен, тик ризасызлык туа күңелдә... Авыр сугыш

елларының михнәтен үтеп, бүгенге көнгә шушы хәлендә 95 яшькә (!) житеп, шөкер итмәве бик кызганыч. Яп-яшь көе урын өстендә ятучылар күпме?! Аннан да авыры юктыр?! Үз башына төшкән, үзе генә белә. Һәрберсе авыр: якты дөньяның матурлыгын күрә алмасаң, теләгән җиргә үз аягында бара алмасаң, эти-әниеңнең өзелеп дәшкәнен ишетә алмасаң... Алмасаң - алмыйсың инде, язмышың шулай булгач, дияр кемдер. Әйе, гомерең булгач, сыкранып булсада яшисең. Һәркемгә ихтыяр көчләре юлдаш булса иде!

Булган сәламәтлеккә шөкер итеп, әйләнә-тирәдәге инвалидларга җылы караш, ярдәм кулы сузыйк! Үзегезне өстен карашлы булудан саклагыз, югыйсә, сезнең файдага булмастыр. Кимсетелгәннәрнең күңеле җиңел яралanучан, рәнҗешләрен алмагыз! Бит, гарипләрнең бер гаебе дә юк. Барыбыз да дөньяга яшәргә килгәнбез! Һәм беркем дә: ”Мин шундый булмыйм!”- дип әйтә алмый. Ходай кулында, язмыш кочагында без.

*Кыскартылып, “Тат. Яшьләре” газетасында (№ 65)*

*29.11.2012 басылды*

# Алия “чишмәсе”

Авылдан ике чакрымнар ераклыктагы Әзе чишмәсен санамаганда – җирдән бәреп чыккан саф сулы чишмәләр юк бездә. Электән, кайда чишмә булган – шунда халык яшәгән. Имәнгол бабай авылга нигезне, әлбәттә чишмә янына салгандыр. Куйбышев сусаклагычы көмеш сулы чишмәләре белән бергә, хуш исле чәчәкле киң болыннарын, тирән күлләрен, шаулап торган имәнле урманнарын “йоткан да”, җәйрәп торган сулык хасил иткән...

Судан башка яшәүне күз алдына да китереп булмый. Чишмәләр булмаса – авылыбызда кое бар. Озак еллар суны Барый абый суыртканга, Барый абый коесы дип тә йөрттеләр аны. Халык, кое суын өйдәге краннардан агызып эчә. Чиста, саф суыбызны шәһәрдән кайтканнар, суыгыз тәмле дип, чумырып чүмечләп эчәләр. Соңгы елларны исәпкә алмаганда, сүз тидермәдек кое суына. Ләкин бер җитешмәгән ягы бар иде: бик каты – сабын начар күбекләнә, чәйнекләрне аз гына чистартмый торсаң, юшкын утырып, авырая. Ә бөерләргә

таш утырганын еллар үткәч кенә беләбез, әлбәттә. Тик ул вакыт инде, кирегә юл юк – буласы булган була. Шуны аңлап, авыл халкының күпчелеге эчәр өчен, 9 км ераклыктагы Урта Девятово авылындагы төзекләндерелгән чишмәдән машиналар  белән алып кайталар. Ул чишмә юлын күрү дә җанга сихәт бирә - бик матур эшләнгән. Челтер-челтер килеп чиста , йомшак су улактан туктаусыз агып тора. Авылда өлкәннәр дә күп, машинасызлар да бар, каты булса да,  кое суы эчәләр.  Сентябрь аеннан, авылның үзәк, күркәм урынында, республикабызның халыкны чиста су белән тәэмин итү юнәлешендәге программа нигезендә, артезиан су  киоскасы ачылды. Суның химик составы күрсәтелгән кәгазе дә бар- кызыксынганнарга. Суы тәмле, йомшак. Ләкин мин үзем суны кем кулыннан алу да тәменә, шифасына зур тәэсире бар дип саныйм. Бер карасаң,  китерелгән суны, богырдатып пласмасса шешәгә тутырып бирүнең ние бар, дияргә мөмкин.  Изге теләкләр ишетеп, яхшы куллардан алган суда уңай энергия һичшиксез була. Ә инде өйгә алып кайткач та, мәсәлән, бу очракта, сатучы Алия апаның ягымлы карашы, тәмле сүзләре, изгелекле күңеле барыбер бер искә төшеп, кәеф күтәрелә, елмаясы килә – бу шул уңай энергиянең үзе түгелме соң?! Әлбәттә, кырыс күңел белән моны төшенә торган түгел.  Беркөн, интернеттан ипи пешерү рецептларын карап утырдым. Берәү язган: ипине фәкать яхшы кәеф белән генә салыгыз дигән, сыналган – юкса уңмый дип, кисәткән. Сыналган, димәк. Мин дә сынадым, шуңа язам.  Чишмәдән түгел, киосктан алып кайткан судан чәй эчкәнче,  салган ашым пешкәнче, Алия апаның яхшы кәеф өләшүенә төшенәм, сөекле авылдашыбыз булуына  кат-кат иненам. Сәхнә түрләреннәндә чылтырап аккан сопрано тавышы белән җырланган кабатланмас җырлары да күнелгә килеп,  суны да чылтырап аккан чишмәдән алып кайткандай булам. Хәер, мин өйдән дә  шаяртып, Алия апа “чишмәсенә” суга барам, дип чыгып китәм...

Суларыбыз саф, чиста, йомшак булган кебек, күңелләребез  дә шундый булсын иде!  Ә Алия апа шундыйлардан.

*“Т.Я” да(02.03.2013)кыскартылып басылды.*

# Ак яулыгың кайда, әнием?

Бервакыт авылдашым Әлфира апа янәшәсендә атлаган өлкән яшьтәге апаны кем икәнен беләсем килеп озак кына артларыннан карап тордым. Юл

чатында кадаклап куйган күк басып торганыма үзем үк сәерсенеп, нишләп торам соң әле мин дип, борылырга булдым. Ләкин барыбер, кем икәнен фаразлагач та (К.Елгадан әнисе килгән), күземне алардан ала да, кузгала да алмадым. Мин шунда гына, кем икән бу дип түгел, ә бу ак яулыклы татар карчыгына карап, газиз анамны сагынуымны аңладым...

Беренче тапкыр ак яулыгын таратып япкан әбиләргә әнә шул көннән игътибар итә башладым. Әнине мәңгелеккә озаткан җәй иде ул. Һәр яулыклы авылдашым күңелемә тагында якын була башлады. Бигрәк сөйкемле икән бит безнең ак яулыклы татар карчыклары! Йөзләреннән аклык-пакълык, нур бөркелә. Җилфер-җилфер ак яулыкларыннан илаһи яктылык сирпелә. Моның шулай булганына, әни исән чакта игътибар итмәгәнмен икән шул...

Йортыбыз олы юлга (оренбург тракты) якын урнашкан. Авылдашлар почтага, кибеткә, я булмаса медпунктка - кая гына барсалар да олы юлдан үтәләр. Бүген дә күз карашым белән яулыгын язып (таратып) япкан әбиләр эзлим. Берәм-сәрәм генә шул алар. Өлкән яшьтәге апалар күп, анысы. Тик күбесендә кыйгач япкан яулык, бәйләнгән йон башлык, үзбәкләрдән күчкән ”баш формасы биреп тегелгән артка бәйләнгән косынка” һ.б. Матурлыкка - матур, сүз дә юк! Тик үзебезнең татар карчыгы образы түгел инде. Кибет-почталарга барганда (тагы кая барасың инде, авылда?) әбекәйләребезнең чын үзебезчә милли итеп киенергә, яулыкларын язып ябарга тормыш мәшәкатьләре чабуларыннан тарта микән? Алай дисәм, әни сөйләгәннәр искә төшә дә, теләкләре юктыр дип, нәтиҗә ясарга ашыгам. ”Без, бозау караучылар - Фатыйма, Сәлимә, Сәкинә, Вәсимә фермага барганда ак яулыкларны чөеп бәйлибез, канатлы алъяпкычларыбызны киеп барабыз. Салып эшлибез дә, кайтканда киеп тамбы (асфальт) юлдан тезелеп кайтабыз. Сәкинәнеке гел чигелгән булыр иде...”

Бу елларда хатыннарның хуҗалыкта эшләре бөтенесе дә кул хезмәте белән башкарылганы мәгълүм (автомат кер машиналар төшкә дә кермәгәндер). Миллилекне, гореф-гадәтләрне сугыштан соңгы елларда да саклаганнар. Уйлап карасаң, сабын да булмаган - көлдән селте ясап юганнар ул ак яулыкларны. “Марҗа кара ситсыдан тегеп кия, кер күтәрә торган булсын әле”- дип, ак төстән ваз кичмәгәннәр бит.

“Урак урганда, Асия апа төшке ашка кайткан арада канатлы ак алъяпкычны юып, кибәр-кипмәс киеп килә иде, дип сөйли иде, әни. Үзе көлә-көлә әйтер иде, хәерченең көне - җәй инде аның! - дип. Шул бер алъяпкыч иде инде барыбызның - алмашка бар чагы бар, юк чагы да бар иде.” Шундый

тузанлы эштә дә ак алъяпкыч, ак яулыклардан эшләгәннәр - тырыш, чисталыкка үрнәк татар хатыннары. Киемнәр бит мәдәниятыбызны, гореф-гадәтләребезне чагылдыра. Аны шул авыр елларда да хәерчелеккә, юклыкка сылтап үзгәртмәгәннәр - дәвам иткәннәр. Сатып алырга булмаган, тегүчеләргә тектергәннәр. Авылда ике-өч тегүченең берсе минем әни булган. Эштән кайткач, хуҗалыктагы эшләрне бетергәч, төнлә тегә торган булган ул күлмәкләрне. Ул заманнар артта калгач та, әни янына: “Зәмзәмия апа, син теккән теге күлмәкне бик яратып кигән идем, кибетнеке ошамый, тагы тегеп бирмәсеңме”, дип киләләр иде. Ә әни, аңа нинди күлмәк теккәнен дә, хәттә бизәген дә хәтерләп ала...

Тегүче эзлисе юк, кибеттә нинди генә күлмәк юк хәзер: балаитәклесе кирәкме, изүдән төймәлесе кирәкме - алып кайтып әниеңне сөендер генә. Әниең генә исән булсын! Ул баш яулыкларын алам дип сайлый башласаң, аптырап бетәсең. Шулай бер, яулык сайлыйбыз якын күршем белән. Икебез дә ак яулыклы әбиләрне үлеп яратабыз. “Безнең картлыкка яулык язып ябучылар булыр микән? Матур әби буласым килә минем!”- дим, күземне кыса төшеп, үземне - кырыкка җитмәгән башым белән яулыклы әби итеп күзалдына китереп.

Менә шулай, язып япкан яулыкка күптән гашыйк мин. Аны картлык билгесе дип тә санамыйм. Ак яулыклы әбиләрне урамда күрсәм, талгын җилдә тибрәлгән ак чәчәккә охшатам. Никадәр матурлык, аклык-паклык балкый алардан. Нигәдер өлкән апаларыбыз гына ашыкмый, язып яулык ябырга. Үзләрен яшьрәк хис итеп, әллә җитмеш-сиксәннәр тулуын көтәләр?!

...Көтү куу дигән бик матур күренеш бар иде элек авылларда. Монсын да язмыйча кала алмыйм. Хәер, хәзер дә бар ул. Авылның бетүгә барган кызганыч күренеше дияр идем, бүгенгесен. Ә ун еллар элек сабан туедай, үзенә күрә бер иртәнге бәйрәм булган икән ул! Һәр йорттан бер хуҗа яки хуҗабикә сыерны көтүгә юл буенча озата бара. Ялгыз әбиләр дә сыер асрыйлар иде бит ул елларда. Иртәнге саф һавада яше-карты гөрлиләр: хәл-әхвәл белешеп, яңалыклар уртаклашалар иде. Бер кеше дә абзарда сыер сауган киеме белән көтү кумады. Рәйсә апа (Пучты Рәйсә дип йөртәләр иде үзен, гомер буе хат ташучы булып эшләгәнгә) көтү чыкканнан, кара көзгә чаклы, шикәр күк ак яулыгын җилфердәтеп йөрер иде. Үзе җитез хәрәкәтле булганга, аныкы әллә кайдан күренер иде... Күңелгә якын, матур күренешләр еллар үтсә дә күңелдә калалар икән.

Ак яулык белән газиз әнкәйләр арасында бәйләнеш бар. Юкка мыни, күңел кылларын тибрәтерлек җыр-көйгә салынган алар?! Алыйк әле, сандык-

шкафлардан пөхтәләп төрелгән яулыкларны, булмаса - яңаны бүләк итик! Яптырыйк әле газиз әнкәйләргә, кадерле әбиләребезгә, хөрмәтле өлкән апаларыбызга! Каршы түгелдер алар. Нишләп каршы булсыннар, күңелләре иман тулы нур гына бит аларның.

...Табигатьтә кара күз хакимлек итә. Бик тиздән шушы кара күзләрне яктыртып, илне иңләп әниләр бәйрәме килер. Аннан инде ак кышларга да күп калмас. Әниләр күбрәк, өйдән дә чыгарга теләмичә, гаилә җылысын саклап яшәрләр. Исәнлек-саулыкта, балаларыбызның игелеген күреп, озын-озак гомер кичерсәк иде. Башыбыздагы ак яулыкларны җилфер-җилфер итеп, балаларыбызны, оныкларыбызны сөенеп каршы алырга, сөеп озатып калырга насыйп булса иде. Әниләр тормышыбызның бизәге, туган йортларыбызның яме дә, яшәешебезнең тәме дә. Гомер күзләребездә ак әбиләр булып гомер кичерергә насыйп булса иде.

*Кыскартылып“Татарстан яшьләре” газетасында,*

*(№58, 15 нче ноябрь 2012 ел) басылды*

# Уйларым – уенчыкта...

Оныкның кибет киштәсен тутырырлык күп сандагы уенчыкларына карап исләрем китеп утырам – төясәң бер олау булыр, билләһи. Үз балаларым үскәндә, бу кадәр уенчыклары бар идеме икән соң? СССР таркалып, кибет киштәсе бушады шул. Ләкин, илдә вәзгыять үзгәрми калса да, бу кадәр булмас иде дим. Чөнки безне акчаның кадерен белергә (мәсәлән, сберкассага салырга), артык исраф ясап, өсте-өстенә әйбер алырга ярамый дип өйрәттеләр. Ә бу киңәшләр тормышка яраксыз булып чыкты. Кызларыбызның санаулы уенчыклары арасында, сыңар аяклы курчак та бар иде. Ул “озын гомерле” булды. Хәзер искә төшә дә, әгәр алар күп булса, чыгарып ташлаган булыр идек дим. Базар экономикасына күчкәннән бирле, баланың уенчыгы булу-булмавын, кирәкме-түгелме икәнен уйлап тормыйбыз. Янчыкта бәрәкәтсез акча, кибет, базар тулы уенчык. Һәм нинди генә уенчыклар юк?!.

90 нчы еллар башында балалар нәрсәдән дә бушаган матур каплар белән дә уйныйлар иде. Бүгенге белән үткәнне чагыштырып язам: 20 ел элек машина итеп

тауардан бушаган картон коробка эченә кереп, бала үз фантазиясен эшкә җигеп машина итеп уйный иде. Бүгенге баланы чын машинаның кечкенә форматына мәҗбүриләп утырталар. Монда фантазия кирәкми, идарә ителешле кызыктыргыч матур машина панелендәге төймәләргә баскаларга өйрәнергә кирәк. Кайбер кереме күбрәк гаиләләрдә балаларның үзләре кереп утырышлы машина, мотоцикль ише техникаларына гараж салу проблемасы кузгатылу ихтималы юк түгелдер – өйдә атлар урын юк чөнки.

Инде үзең кадәр йомшак аюлар белән кеше шаккаттырып булмый. Шул йомшак уенчыкларны, киелмәгән ясалма туннардан, драп пәлтәләрдән тегеп утырган чакларым бар иде. Чөнки алырга юк! Ә халык аптырап кала торган түгел безнең илдә, һәрнәрсәгә яраклаша. Маймыл, эт, куян өлгеләре кулдан-кулга йөрде ул елларда. Кибетнеке кебек ыспай, матур ук килеп чыкмаса да, менә дигән уенчыклар иде. Хәзер дә ташларга кызганам әле – үзең эшләгән әйбер күңелгә якын була бит ул.

Без үскәндә, рәсемгә оста кызлар ак картонга кыз рәсеме ясап кисәләр дә, шуңа альбом битендә төсле карандашлар белән матур күлмәкләр “тегеп” кисә идек... Уенчык юк дип бала уйнамый тормаган. Ул җәйләрен, кукуруз басуына барып, кызыл, сары “чәчле” чәкәннәрне алып кайтып курчак итеп уйнауларны искә төшергәч тә күңелне рәхәтлек биләп ала. Урамыбызда бармак озынлыгы гына нәни курчак (пупсик) белән уйнау “модада” иде. Шуларга төрледән-төрле күлмәк-ыштан тегеп кигезү өчен, колхозның машина-трактор паркында гел була торган чүпрәк кисәкләренә бара торган идек. Өйдә дә булган бит инде чүпрәк кисәкләре, нигә анда барылгандыр? Сорап алырга куркабыз, күрсәләр әрләрләр дип, кочагы белән өелеп яткан ситсы кисәкләрен (тегү цехлары, механизаторларга мазутлы кулларын сөртергә җибәргәннәрдер инде) урлап алып кайта идек. Эзләгәнбез, тапканбыз, эшләгәнбез, аннан уйнаганбыз. Уенчыгым юк дип елап сорамаганбыз, ал дип аптыратмаганбыз. Хәзерге балалар кулында күбесе гади уенчык түгел – идарә ителешле “техника”. Уенчык кесә телефоны, ноутбуг, машина, вертолет һ.б. - барысы да кнопкаларга басып идарә ителәләр. Болар бар да баланың аң-зиһенен үстерәләр. Кулыңа китап тотып, әкият сөйли торган заман күптән искелек калдыгы саналадыр. “Маша и Медведь” мультиклары минем үземә дә бик ошый – онытылып рәхәтләнеп карап утырам. Тәрбия бирүен әйтә алмыйм, аң-зиһенне үстерә кебек. Баш ватып уйлап утырам, безнең аң-зиһенне ни-нәрсә белән үстергәннәр икән соң, әти-әниләребез? “Балаларны таптык та, кайнанага калдырып 40 көннән колхоз эшенә чыгып чаптык ”, дип сөйләгән өлкән апаларны күп тыңларга туры килде. Ул әбиләрне уйлап бер соклансам, икенче уйлап кызганам: уңайлыклары булмаган

көнкүрештә биш, аннан да күп оныкларын үстергәннәр, тәрбия биргәннәр... Без үскәндә менмәгән агач башы калмады, бармаган басу-кыр, үрмәләмәгән тау-ермак, йөзмәгән сулык, шумаган бозлык, чапмаган урам калмады. Ызгышканда көрәшү - көчле иткән, урам уеннары аң-зиһен белән бергә аралашу осталыгына өйрәткән. Өстәп, әби-бабайның Коръәнгә нигезләнгән тәрбиясе, кичләрен тәтегән әти-әни назы, акыл-нәсыйхәт кеше итеп формалаштырган дип фикерлим. Безне балачак уеннары көчле, җитез, тәвәккәл иткән. Вакыты җиткәч, теләге булганнар техника белән идарә итәргә дә өйрәндек. Әле өйдәгеләргә уенын-чынын кушып әйтеп куйдым: "Теге яки бу сәбәп белән су басу була калса (Алла сакласын!), агач башына мин-әби менәм, малайлар менә алмый.” Чөнки аларның агач башына менү түгел, компьютер каршыннан торып, авылның аргы башына барып килгәне дә юк. Шул урам башында яшәүчене, буй җиткергән бала авылдаш икәнен белмәскә дә бик мөмкин, әгәр аның вконтактеда бите булмаса һәм дусларына кушмаган булса...

Замана диеп шул кадәр исраф ясап, аң-зиһенен үстерәм диеп, кечкенәдән бала башын техника белән мәшгуль итү кирәкме икән? Танышларның өч яшьлек кыз балалары кәрәзле телефонны куллана белә, компьютерны да яхшы чамалый. Шулай күп белгәненә сөенәбез, сокланабыз, әлбәттә. Шулар белән булышып хәрәкәт итүе чикләнә, менә. Үсеп җиткәч, фитнес үзәкләренә йөреп кенә организмны физик чыныктыруга ирешеп буламы икән соң?

Компьютер каршында деформацияләнгән умырткалы асыл егетләребез армиягә яраксыз, ярты төнгә чаклы ноутбукка текәлеп утырган күз күреме бозылган кызларыбыз балаларын табигый юл белән табырга сәләтсез була бара. Аралашу күптән инде виртуаль... Техника, организмыбызга өзелмәс җепкә тоташкан бер әгъзабызга әйләнеп бетте бугай инде.

“Т.Я” да басылды.

# Күңелләргә мәңгегә уелган.

Сугыш чоры балаларының балачак хәтирәләре гел әрнүгә кайтып кала. Без - яшьләр, Бөек Ватан сугышы елларының михнәтләрен арабызда яшәгән сугыш һәм тыл батырларының үзләре сөйләгәннән күзаллап кына беләбез. Һәр авылда да сугыш еллары фидакарьләре сафы сирәгәя, инде Бөек Җиңүнең 70 еллыгына бәйрәм күрке итеп түргә утыртырлык сугыш ветераннары калмады диярлек.

Мәсәлән, сугышта катнашкан, әйләнеп кайткан 98 авылдашыбызның барысыда бакыйлыкка күчеп беттеләр. Алар безнең арада булмаса да, күңелләрдә сакланырга тиеш. Чөнки бу безнең тарих. Матбугатта, мәдәни чараларда авылыбызның онытылырга тиеш булмаган бу шәхесләрен, тарихи вакыйгаларын яктыртырга бурычлыбыз дип саныйм.

Мин сугыш чоры баласының баласы. Мәктәптә укыганда, Бөек Җиңүнең 40 еллыгын каршылап, сугыш ятимәсе булган укытучыбыз Руфия Хөрмәтовна, авылыбыздагы тол аналар белән зур кичә оештырган иде. Бердән, аларны кадер-хөрмәт итү булса, икенчедән укучыларга үткәнебез, шәхесләребез турында күп мәгълүмат бирүче тарихи-тәрбияви чара булды ул. Минем үзем өчен ул хезмәт юлымда, Җиңүнең 50 еллыгын оештырганда зур ярдәмлек булды дип әйтә алам. Өстәп, йорт саен диярлек йөреп сугыш еллары истәлекләрен туплаган идем. Шуңа да, авылыбызда сугыш елларында тылдагы хәлләр турында күңелемдә күп мәгълүмат йөртәм. Минем әти-әнием үзләре үк сугыш башланганда 12-13 яшьлек бала булганнар, сугыш тәмамланганда өлкәннәр белән хезмәт юлы үтеп, егет-кыз булып җитешкәннәр. Әни бу елларның тере “энциклопедиясе” иде. Күңеленә мәңгегә уелган иде аның балачагын урлаган бу сугыш еллары. Сөйлим дип сөйләми иде, җае чыккан саен тирән уфтану белән әйтеп куя иде. Кышкы әче җил сызгырганда, уйларына бирелеп, ”Эх-х!” дип ачыргаланган чаклары күп иде. Бер ымлыкка сыйган әрнүле күңел халәтен аңлап, сораулы караш белән төбәлү дә җитә – үзеннән үзе сөйләп китә: “Йөрәгемә ярамый шушы җил сызгыруы... Сугыш башланасы елда язын, энекәш ут белән шаярып, йорт-җирләр янып кара күмергә калды. Кышка алай-болай итеп йорт салып кердек. Ишегалды, капкасыз булгач, зур толыплар белән юлаучылар гел безгә кереп, кунып чыгарга сорыйлар иде Ул әче җилләрдә болай да салкын булган өйне карлы толыплар тагын да салкынайта иделәр. Эх-х, әни-җанашым, нишләргә белми иде...”

Ул михнәтле елларның хәтер-хатирәләре, җәрәхәт кебек саркып тораган күрәсең. Мунчаның кайнар су багы “доп-доп” килеп кайнаганда да сөйләмәс җирдән сөйли торган иде: “...Әбиең белән мунчада кер уабыз. Миңа өзелеп-өзелеп карый да, күрсенә. Арты белән торган көе әйтә бу, “урман кисәргә барырга кеше җыялар икән. Яшь дип тормаслар, бәдәнең бар. Җибәрерләр дә, шушы яшеңнән агач басып имгәк булып ятарсың... Тык ике кулыңны кайнар суга!” Тавышсыз елаганын, иңнәре калтыраганнан күрәм әнинең. Кайнап торган суга кулларымны сузам да, кире алам. Эх-х! Күрәләтә ничек пешереп булсын инде кулларны. Хәер, яшем җитмәгәнгә калдырдылар...” ди, әнкәм, яшьле күзләрен челт-челт йомып.

Авыр еллар булса да, балалык-яшьлек барыбер үзенекен эшләгән инде. Хәзерге көндә көләрлек булмаган нәрсәләрдән дә кызык таба белгәннәр.

- Маһирә белән тракторда сабан сөрәбез. Тракторны иярли беләбез, ватылса төзәтү безнең кулдан килми – дәү абыйны көтәбез (механик дип аңларга кирәктер). Япа-ялан кыр, салкынча. Маһирә әйтә, малай-җаным, бу җон оек бетләде ахры, тик утыргач кымтырыклаганы тоела, дип тездән югары җирдән бөрмәсен әйләндерә дә черт итеп үтерә бара. Мин дә юк, дим. Булмаган кая, көлешә-көлешә бет сытып утырганда,"Тапканнар көлешеп утырыр вакыт", дип пыр туздырып әрләгән иде шул чак, дәү абый. - дип, шундый кызыкларны да искә ала иде. Ә безнең бу "кызыктан" күзләр шар булып ачыла.

Иң авыры хезмәт түгел, ашарга булмавы үзәкне өзгән. Чордаш күршеләр, чәй табынына утырган саен шөкер итеп, "Ата-баба күрмәгән сый бит болар!" дияләр иде.:" Иркенәеп утырганнан, күрше әби әллә ничә сөйләгән хәлне сөйли: "Өй тулы бала-чага, ашарга юк чаклар да күп булды. Ашыйсым килеп, берәр көн бөгәрләнеп ятканым истә. Үзем теләк телим, тизрәк бәрәңге чәчәк атсын иде дип. Әнкәй мәрхүмә, бәрәңге чәчәк аткач, казып карарбыз, дигәненнән, ашарга бәрәңге була дип уйлыйм, шул чак".

Күңелләренә уелган бу еллар туктаусыз хәтирәләр барлата... Кемдер: "Җәен сөт эчемәсен, салкын торсын өчен, бака салалар икән" дигәнгә җилкәләрне җыерып чирканабыз. Әни җыерылмый гына тагы форсат табып сөйләп китә. Бала чакта кызык булмаган нәрсәне тыңлап торасы киләмени? Озак сөйләмә дисәк тә, тәфсиллап сөйләп бетерә. Кызыксынмасаң да, хәтер капчыгына тула бара икән ул!

– Гаилә ишле: Нәнә абый сугышта, сугышка яраксыз Дәү абый тракторчы булып килгән кызга өйләнеп, тагы бер кешегә арттык. Әти-әни, миннән кече ике туган... Һәр көн чишмәдән су ташып мичкәне тутыру минем вазыйфа. Әни мич казанында аш пешерә. Суны казанга салганбыз, чиләктәге баканы күрмәгәнбез – пешеп таркалган. Эштән кайтасыларга яңадан аш пешерергә вакыты да, ризыгы булмагандыр, чүмеч белән бака кисәкләрен чүпләгәндә, миңа беркемгә дә әйтмәскә кушты әни. Барысы да ашады, мин ашыйсым килми дидем. Дәү абый турыдан сөйләшә торган иде, "Зәмзәмия, юкка ашамадың. Ашы да, бака сыйрагы да тәмле булды!"- диде. Әни чүпләп бетерә алмаган, аягы аның тәлинкәсенә эләккән булып чыкты...

Өлкәннәр болай да үткәннәрне искә алып яшиләр. Сугыш чоры балалары күргән газап, михнәтләрне сөйләп тә, язып та, киноларда да күрсәтеп бетерә торган түгел. Күңелләренә тирән уелган инде ул. Тик ни генә сөйләмәсеннәр

”Аллага шөкер, хезмәт иттек, тырыштык”, дип горурлык белән тәмамлыйлар алар. Бу сүзләренә әнинең, институтта укыган, СССР таркалгач, сәяси күзәтүләрдән чыгып фикер йөрткән олы оныгы үртәлә:

– Әби, зря сез эшләгәнсез. Әгәр җиңмәгән булсак, на много лучше бы жили! – ди ул, урысчалы-татарчалы. Туган иленең ватанпәрвары – әбиебез, оныгының бу сүзләрен бер дә яратмый. Чөнки һәр совет кешесе кебек үк башкача күзалдына китерә алмый, күңелендәге фидакарь хезмәтләрен берничектә җуя алмый. Ә Ватан дигәннән, илнең сугыш чорындагы рәхимсез кануннары миндә дә нәфрәт уята. Шул кадәр халыктан мыскыл иткән инде бу югары даирәдәгеләр. Тупланган истәлекләрне барлап, яшәү җирлегемдәге тылдагы вакыйгалар турында хәтердә яңартам. Зөһрә әбине ике кечкенә уллары белән язмыш сынауларына калдырып, ире сугышка китә - әйләнеп кайтмый. Ачы хәсрәте, ирләр урынына җигелеп хезмәт итүе генә җитмәгән – күтәрәмгә калган бер колхоз сыеры үлгәненә гаепләнеп, төрмәгә утыртканнар. Йә, Ходa, нык та булганнар инде үзләре. Әле февраль аенда гына 97 яшен тутырып үлеп китте үзе. Болай да михнәт чигеп яшәгәннәр ләбаса, рәхимсез кануннар белән нигә шаярдылар икән шул кадәр? Сугышка кергән кешенең исән кайтмаска мөмкин икәнен дә, болгавыр елларда хезмәт авыр булганын да, ятимлекне дә, ач-ялангачлыкны да аңлап та, озакка киткәч, килешеп тә буладыр. Фронт өчен, илне аякка бастыру өчен үзләрен аямый хезмәт иткән, җиңү көнен якынайткан тыл батырларының, егәрләре бетеп егылмаска, балаларының тамагын ялгау өчен эшләгән вак кына урлашуны котычкыч җинаять кебек бәяләп, үз халкына газап ясаган илне ничек ярата алганнарына төшенә торган түгел.

Шул каһәр суккан елларда инде, авылдашыбыз Шәйхиева Фатыйма апаны, тамак ялгарга бөртекле ашлык алып кайтканы өчен гәепләп, өч баласыннан аерып, 8 айга төрмәгә утырталар. Ире үлеп калган хәбәре килгән Галиева Галимә апаны тентегәндә кесәсеннән 100 г ашлык табыла. 12, 8, 4 яшьлек балаларны абыйсы Гыйлметдингә калдырып киткәннән, 2 ел да 8 ай рәшәткә артында булып кайта. Ә Вәлиева Фатыйма апаныкы үлчәгәч, 200 грамнан арта. 4,5 елга китеп барган. Караучысыз калган 4 баланы балалар йортына тапшырганнар.

Болар барысы да шул чор кешеләренең күңелендә саклана. “Ии-и, ул көнне күршебез Җәмилә апаны авылыбыз белән елашып озаттык. Балаларны балалар йортына алып китәргә диделәр. Олы бала – Гыйзелбәнат җиткән кыз, 5 баланың кайсын җитәкләп, кайсыларын күтәреп чыкты да: ”Берсен дә җибәрмим, үлсәк бергә үләрбез!” дип, бирмәде туганнарын... Җәмилә апа шул балалар тамагын ач итмәскә алган башак өчен, өч ел утырып кайткач та, мантый алмыйча, үлеп китте, җанашым”, - дип, әни яшьле күзләрен яулык почмагы белән сөрткәли иде

дә, озак кына үз уйларына бирелеп йөри торган иде. Үзләренеке янәшәсендә, авылдашларының язмышлары да күңел түрләрендә урын алган.. Авырлыклар еллар артында калса да, һич онытылмый – вакыты белән гаделсезлекләре бик тә йөрәкне әрнетә. Гомумән, халык хәтере мәңгелек ул!

"Т.Я" да басылды.

# Гәҗите - саргайган, яшьләре - олыгайган.

Чормада актарынганда, "Т.Я" ның №9905 нче санын (2000 нче ел 11 нче июль) табып алдым. Ниләр язылды икән, яңа гасырга аяк баскач? Нинди мәсьәләләр күтәрде икән, журналист халкы?! Чормадан төшмичә, 12 ел элек чыккан гәҗитне тәмләп укып чыктым дияр идем, ләкин... тормышы шундый булгач - гәҗитнең чынбарлыкны язмый чарасы юк! Һаман да бер балык башы икән, шул! Гәҗиткә күзәтү ясыйк әле...

Гәҗитнең ал хәбәре булып, "Хөкүмәт чиновниклары безне тагын төпсез көймәгә утыртмакчы" – зур хәрефләр белән бастырылган. Әлеге дә баягы табигать көйсезлеге - ишелеп яуган яңгырлар аркасында су басулар барлыкка килгән: шәһәр халкын машина "бөкесе" җәфалаган, авыл кешесенең базына кадәр су тулган, үләт базларында чирләр яңгыр сулары белән өскә калкуы, хөкүмәт чиновникларының эшне вәгъдә һәм кәгазьләрдә генә алып барулары турында язып чыккан, мәкалә авторы М. Низамов. "Тагы 10-15 елдан аңыбызга килүдән куркасы юк – хуш, таныргбыз (хаталарыбызны, диюе - Г.Г.), төзәтергә алыныгрбыз. Без гомер бакый шулай үзебезгә үзебез проблема тудырып яшәрбез микәнни?"- дип чарасыз тәмамлаган.

Лилия Сөнгатуллина, җанисәпне 2002 нче елга күчерделәр дип хәбәр итә."Туктамас сугышлар, төрле авырулар, илне ботарлау халык санын кырды, туучылар саны кимеде" – дип халык санын алганчы ук, Русия иркенәеп калганын күзаллаган...

Зөләйха Кыдашева Татарстан журналистлары арасында (Р. Гыйлемхановтан башка) көчле сәяси күзәтүчеләр юк, дип борчылган...

Риман Гыйлемханов В.Путинның еллык юлламасына сәяси күзәтү ясаган. Мәкаләсен әзерләгәндә төш күргән: имеш, Путин белән бер бүлмәдә сөйләшеп утырганнар. Шунда: "Татарстан белән нишләмәкче буласыз? – дип сорадым. –

Борчылмагыз, Риман Солтанович, бары да элеккечә калыр”, -дигән. Бигрәкләр төше рас килгән! Бар да элеккечә бит инде...

Чытык чырайлы авыл агаеның (рәсемдә) яңгырлар артык күп яуганнан печәнен хәзерли алмавы, мәктәп баласының ниләрдән куркуы да (ләкин БДИ нең “духы” да юк әле ул елларда!), Нәзилә Сафиуллинаның роддомнан бала белән бергә “мәкаләгә чимал белән” чыгып, ана буларак киләчәкнең алсу таңы матур гына күренмәвен тәэсфирлап язуы да - бар да, бүгенге көн кадагындагы мәсәләләр. Редакциянең махсус адвакаты Роберт Туктаревка бирелгән сораулар – армиядән кемнәр кала алуы, уку кайчан-кемгә түләүсез була алуы, танышының зур сумма акча алып түләмичә - кәкре каенга” терәве турында; хосусый эшмәкәргә эшкә урнашканда хезмәт кодексларын ачыклыйсы килү- барысы да, язганымча, хәзерге көн кадагы мәсәләләре. Шулай ук, 15 яшьлек малайны балык тоткан җирдән алып китеп (иптәшләре оештырышкан!), салкын базга яшереп, ата-анасыннан 300 000 сум акча тәлап итү дә – җәмгыятебезнең ничә еллар дәвамында килгән черек үзәкле булуын күрсәтүче тагы бер мисал. Бу хәлләр артуга, куркыныч төс алуга бараганы барыбызга мәгълүм.

Күңелсезләнеп мәкаләләр укуымны дәвам иткәндә, күңелгә җылы йөгерде: арабызда мәрхәмәтле кешеләр элек тә булган. Әнә Казаннан Кәүсәрия ханым, Дәрвишләр бистәсендәге балалар йортына ярдәм күрсәткән. Гомумән, 12 елда яхшы якка үзгәрешләр булмаган да дип нәтиҗә чыгарганда, иң соңгы бит астында белдерү күренде: “стал оценкованная листовая...” 1995 нче елларда йорт салганда акчаны кулга тотып түбә калае эзләп җәфаланулар искә төште. Кая ул хәзерге кебек заказ биреп, сайдинг, профнастиллар кайтарту?! Каян нәрсә таптык, шуның белән эшләп куйдык! Базар игътисады - алгарыш икән, иптәшләр! Акча гына булсын, әлбәттә! Акча дигәннән, бәя гел үсеп бара. Әнә, Хәния Фәрхи концерты –Тәтештә 50 сум булган ул елда. 250 булсада карыйбыз, җырласыннар гына! Җырлап тора торган тормыш булсын!

Тик, бар да алга – тормышлар гөрләп, җырлап барырга тиешле илдә - һаман да бер күлдәвектә чыпырдыйбыз икән. Журналист халык белән берлектә чаң суга, таләп итә, кайгыра, тәнкыйтьләп көрәшкән дә күк үзе... Көймә гел комга терәлә. Тормыш диңгезендә матур гына тибрәлеп яшәргә иде, югыйсә. Ә көймәне ярдан кем этә? Мөгаен, түрәләр этеп җибәреп, без ишәргә тиештер дип уйлап куям. “Һе, эткән, ди... Алар яхтада йөзә. Күрми дә алар синең комга терәлгән көймәңне!”, - дип җавап бирә хыялый күңел, шунда ук.

Менә шулай, иптәшләр, гәҗитләр саргайган, үзебез картайган, кешелек дәрәҗәсе күтәрелмәгән, проблемалар чишелмәгән, ә бәяләр үскән. 12 елга гапгади фәлсәфә!

*Үзгәртелеп, "Шуның белән шул..." исеме белән,*

*"Т.Я" №69. 08.12.2012 басылды.*

# Куркаклык бәласе

"Курыкмыйм мин!", - дисәм, җавабы әзер иптәшемнең: "Караңгы мунчада балаңны калдырып чапкан куркак син!" - ди. Елмаям гына, чөнки дөрес сүзгә җавап юк! Хәл болаерак килеп чыкты...

Әни ишегалдысына мунча салды, абыем. Электр уты кертергә өлгермәдек, шәм кабызып юынабыз. Шул көннәрдә, абый шабашкада эшләп йөргән җиреннән, йорт-җирсез бер ирне җәлләп, мунча керергә алып кайткан. Яңа мунчада без дә юынып чыктык, ә теге ир : "Күптәннән мунча кергәнем юк иде", дип, абыйдан соң да чабынып калган. Мескеннең, соңгы тапкыр мунча керүе булган икән – кызуны йөрәге күтәрә алмаган. Абыем: "Ник чыкмый икән?" - дип барса, үлеп ята икән... Икенче көнне мәетне моргка озатып, ыгы-зыгы килдек, өченче көндә генә көндәлек мәшәкатьләргә керешә алдык. Шулай да, мунча ягына карагач, күңелгә шом кергән күк иде...

Кичке караңгылык төшкәч, ияләшенгән гадәт буенча, чәчне юып, фен белән киптерергә булдым. Кирәк бит, өйдә шампунь беткән. Ә мунчада барын беләм, тик барып алырга куркам. Фонарь да юк өйдә, кәрәзле телефон да юк (сирәк кешедә генә ул вакытта) . "Эшкә мондый чәч белән барып булмый инде", - дип, тәвәкәлләдем: дөм-караңгы ишегалды аша, күзгә төртсәң күренмәс мунчага - 11 яшьлек кызым белән шампуньга киттек. Өйдәге, 7 яшендәге кызыма: " Син курыкма, без хәзер апаң белән мунчадан шампунь гына алып кайтабыз!" - дидем. Ул караватында, ярар дип, ятып калды.

Мунча 3 бүлемле булып, тулы тавышка өсте-өстенә "Әгүзе-бисмилланы" әйтеп (курку басылган күк була), кулга-кул тотынып, беренче бүлемне үттек, теге кеше ятып үлгән икенче бүлемне үттек. Өченче бүлемнән шампуньны кулга тотып, кызымны алдымнан атлатып, чыгып барабыз. Икенче бүлемдә кулымнан йомшак бер нәрсә эләктереп алды. Секунд эчендә, башымнан, теге үлгән

абзыйның өрәге,  дигән уй йөгерде һәм... ничек чыгып чапканымны белештерер дәрәҗәдә түгел идем. Өйгә кадәр чапкан булыр идем, бәлки, тик...  өйдә ятып калган кызым, үкереп елап мунчадан чыгып килүен аңлап кына  туктадым , бугай.

Без мунчаның түр бүлеменә кергән чакта, өйдә үзе генә каласы килмичәме, курыккангамы,  кечкенә кызым безнең арттан кергән дә, минем кулымнан тоткан икән. Без аның кергәнен күрмәдек тә:  бар белгәнебез кычкырып , бисмилла әйтеп җен куркыту булды.

Менә шулай, олы кызым өстенә басардай булып, кечкенә кызымны дөм караңгы мунчада калдырып, көлкегә калып  чыгып чапканмын шул.

*“Безнең гәҗит” газетасы №2 (16 гыйнвар 2013 нче ел).*

# Очрашу күңелле мизгел.

Халык телендә йөргән “Очрашу үзе бер гомер” дигән әйтем  яратып әйтелсә дә, киләчәктә актуальлеген югалтыр шикелле. Чөнки интернет, кәрәзле телефон элемтәне югалттырмый. Виртуаль булса да, аралаша торгач, кабат күрешүләр гадәти очрашу шикелле тоела...

Бер дә белмәгән-күрмәгән, җиде ят кешеләр уртак максатлар белән йөргәндә, шулай ук очраклылык белән дә очрашалар да онытылмас дусларга әйләнәләр, йә булмаса якын танышлык барлыкка килә. Дуслыкның, күбрәк, яшьлектәгесе онытылмас булып күңелгә уелып кала. Бер елларда укыганнар, тулай торакта бергә яшәгәннәр олыгайгач та истән чыкмыйлар.

8 ел элек “одноклассники”, “вконтакте” сайтларыннан Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында бергә укыган кызларны ярты төнгә кадәр эзләп утырсам да таба алмаган идем. Соңгы елларда эзләп тапкач аңладым: яшьтәшләрем арасында компьютерга беренчеләрдән барып кергәнмен икән. Уңайлыкның бер рәхәте инде бу интернет челтәре! Бар эшне калдырып, үзенә тартканы өчен “әрлибез дә” инде үзен. Сүз иярә - сүз языйм әле, яшьләр кебек чамасыз утырмыйбыз шул, чөнки тормыш проблемалары чабудан тарта. Ата-ана булгач, меңләгән проблемалар чишәсе бар шул. Сүз башым, интернетта

табышулар, очрашулар турында иде бит. Табышкач, китте онытылмас очрашулар: Мамадыш – Актаныш, Питрәч – Балтач, Балтач – Лаеш һ.б. юнәлешләрдә кунакка йөрешүләр. 25 елдан соң очрашу бик татлы мизгел икән. Диплом алып таралышканда 19-20 яшьлек кызлар идек (группабызда бер генә егет иде) – инде кайберләребез әби “статусын да” алганбыз. Бер дә үзгәрмәгәнбез дип нәтиҗә ясадым. Бары, еллар күз читләренә җиңелчә сызыклар сызган, бераз ит кунган, йә ябыгып киткәнбез. Очрашканда күңел гел 18 дә булса да, йөзләргә җитдилек тә салынган. Рәхмәт интернет-компьютерга! Юллар кисешеп, язмыш кайчан очраштырыр иде икән әле?! Безне, 1987 нче елда Лаеш авыл хуҗалыгы техникумы (хәзер ЛТЭТ дип атала) берләштерде. Ничаклы бухгалтерлар, экономистлар, агрономнар әзерләп чыгарды икән ул?! Әмма илдә авыл хуҗалыгы тармагы “җан тәслим кылды да” белгечләрнең кирәге калмады. Беркем дә югалып калмагандыр - үз урынын тапкандыр дип уйлыйм. Лаеш техникумы электән ныклы белем бирүе, тәртипне нык тотуы белән югары бәяләнде. Укып чыкканнар моны яхшы беләләр. Белгәнемчә, хәзер дә “корыч” тәртип саклана. Бераз читкә киттем, үзебезне берләштергән уку йорты турында язмасам булмас дидем. Ел саен май ае ахырында искиткеч матур очрашулар оештырыла. Килүчеләргә ишекләре ачык! Ә безнең группа кызлары ел буе зарыгып көтә торганнардан түгел.

Язмамны тәгәлләп, иң мөһим әйтәсе сүземне ирештерәсем килә. Сабакташларымның әле парлы тормышлары көмеш туйларга кадәр үк җитмәгән. Шулай да, тормыш иптәшләре белән үзара мөнәсәбәтләрне җайлау, шәхси проблемаларны да уртак итә белү осталыгы белән тату гаиләгә ирешә алганнар, афәрин! Югыйсә, Татарстанны аркылы буйлы гизеп, тормыш, эш проблемаларын читкә куеп, машина иярләп, хатыныңның әллә кайсы елдагы сабакташына күрешү-очрашуга алып барырлар идеме?! Хатынының бер дә күрмәгән сабакташын якты йөзе, күңеле белән кабул итәр идеме икән?! Гомер иткән хатынын күрше авылдагы әнисен күрергә алып бармаучы ирләр әллә юкмы? Менә кайда ул киң күңеллелек, кешелеклелек! Шуңа күрә дә, сабакташларымның үзләреннән бигрәк, тормыш иптәшләренә рәхмәт хисләрем һәм кадер-хөрмәт белән озатып калдым. Кабат очрашулар насыйп булса икән. Очрашулар күңелле мизгел. Эзләгез бер-берегезне! Очрашмыйча калмагыз! Күп еллардан соң очрашканыбыз – үзе бер гомер.

*“Т.Я”№12(01.02.2014)дә басылды.*

# Килмешәк дигән сүз юк

“Күпер төбеннән” беркая киткәнем юк минем дип, уенын-чынын бергә кушып әйтергә яратам. Күпергә терәлеп диярлек торган йортта үстем. Тормыш коргач, нигез янәшәсенә йорт салып, шул күпер янында яшәп – гомер уртасына атладым. Бу минем, туган авылыннан читтә яшәүчеләрдән аермалы буларак - бер бәхетем булды! Миңа шушы тирәлектән дә матур, кадерле бер җир юк!

Җирсү дигән уй-хисне кичерергә туры килмәде миңа. Шулай да, ни икәнен күңелем белән тоям. Ярый әле, әйләнә-тирәмнең радиусы кечкенә булган, югыйсә, җирсү миндә ташкындай көчле булыр иде. Бер тәүлеккә кунакка чыгып китәргә туры килсә, ярты җаным туган авылымда кала – читтә күңелемә тынгылык таба алмыйм. Якыннарым беләләр - шуңа, чакырганда: “Килегез дибез. Беләбез инде, килмәгәнеңне!” - диләр. Кыюрагы әрләп “тәрбияләмәкче”: “Күреп туйгансыңдыр инде авылыңны! Гомер бетмәс эшеңне калдырып, ял итеп кайтырсың! Бер дә рәхәт күрәсең килми мени соң синең?!” – диләр. Авылымнан да, авылга хас булган бетмәс хезмәттән дә - бер дә туймаганымны, бер рәхәтлеккә алыштырмаганымны да, әйтеп-аңлатып тору файдасыз икәнен беләм. Шуңа күрә: “Кунакта рәхәттер, ә өемдә тагы да рәхәт!” - дию белән чикләнәм. Кул гына селтиләр. Аңламыйлармы?! Әллә аз гына булса да, шәһәр буйлап гиздерәселәре килә?..

Һәр йорт, тыкрык, су буйлары, шау-шулы машина юлы да, бакалы сулыгы да, сандугачлы таллыгы да, кычыткан лы ермагы да – бары да күңелгә якын шул. Имәнкискә, җәйрәп яткан сулыгыннан кала, табигатьнең гүзәл почмагына урнашкан дип, авыз суын корыта торган түгел үзе, ә миңа алыштыргысыз ул! Тәпи атларга өйрәнгән урамнарыннан атлау, бергә уйнап үскән дусларыңны, 10 ел буе бергә укыган сыйныфташлар, укыткан укытучыларыңны, гомумән, авылдашларыңны көн саен диярлек күрү, аралашу - яшәешнең бәхетле мизгеле икәнен, читтә яшәгән кешеләр кебек үк нечкәлекләре белән аңлыйм.

Мине еш кына , яшьлекләрендә авылыбызның егетләрен яр итеп, кияүгә килгән яки эш буенча килеп урнашкан гаиләләрнең авылны, кешеләрен яратып, хөрмәт итеп яшәүләре сокландыра. Бер генә, тормыш иптәшен генә яратып төшкән килен – яши-яши, тулы авыл халкын диярлек үз итә. Әлбәттә күңеле киң булса.

Мин бер әбине беләм. Чит авылдан сугыштан соңгы елларда кияүгә килгән. Бер генә кеше белән ачуланышса да, авыл халкын кушып тиргәргә бик һәвәс иде. Ярты гасырдан артык яшәп тә, авыл халкын ярата да, хөрмәт итә дә

алмаган ул. Ә үзе яшьли тол калып, бер туганы булмаган көе, 7 баланы авылдашлары белән аякка бастырган. Шулай да булырга мөмкин икән.

Татар халкында электән килмешәк, дигән сүз яши. Шул авыл халкын үз итеп, халкы өчен хезмәт иткән кеше - килмешәк сүзен ишетергә дә, кыек караш тоярга да тиеш түгел ул, иптәшләр! Җирле халык хөрмәт итмәгән көе, ничек ул торган җирне яратырга кирәк?!

Безнең Имәнкискәгә, "килгән җиргә таш булып төшеп", халкын, җирлеген яратып, авылдашларына һәрдаим хөрмәтен сиздереп, ярдәмләшеп яшәгән үрнәк кешеләр бар. Ике шәфкать туташыбыз Миләүшә һәм Мәдинә апалар халыкны чын күңелдән яратулары хезмәтләренә генә бәйле булмавы көн кебек ачык - күңелләре саф, игелекле аларның. 30 ел буе килмешәк була алмый, беркем дә. Укытучы балалар яратмаса, укытучы була алмый, диләр. Авыл халкыннан үзен өстен тотса, ата-аналарың хөрмәтен казанмаса, балаларга белем биреп кенә игътирам яулап булмый. Бу очракта, бәлки килмешәк сүзен сылап буладыр, ачу килгәннән... Ләкин андый укытучы күргәнем юк. Инде, 2-3 буын балаларга физика-математика, тарих-биология кебек авыр бирелә торган фәннәрне укыткан Зөфәр абый, Ания , Миннесрүр, Фәридә, Руфия апалар авылдашларыбыз арасыннан аерып чит кеше итеп карау уйга да кереп карамый, киресенчә, хөрмәтле авылдашларыбыз дип зурлыйсы килә. Кәүсәрия апа килгән кешеләр арасында гаҗәеп ярдәмчеллеге белән аерылып тора. Зур җаваплы вазыйфада хезмәт итеп, авылдашларының мәктәп-укучы проблемасыннан тыш та, гозерләрен үтәү, ярдәм кулы сузу, якын итеп төпле киңәшләрен бирү кебек игелекле гамәлләр башкаруы – авылдашларына булган хөрмәт йөзе икәнен искәртеп үтәсем килә. Кече күңеллелек, гадилек, халыкны игътирам итү сыйфатлары һәркемгә бирелми ул. Ул тынгысыз җан - авылдан читтә яшәгән авылдашлары өчен дә бәяләп бетермәслек игелекле хезмәт башкара: авылыбыз сайтын ачып, аны 2 ел дәвамында өстендә эшләп, гел яңарта, тулыландыра килә. Белмәгән булсагыз яки кызыксынучыларга – imenkovo.ucoz.ru сайтына кереп карарга киңәш итәм! Менә шуннан, килмешәкләр бармы?! - дип сорау куясы килә. Мин килмешәкнең кем булуын белмим. Кешене үз итмәгән очракта әйтелгәнен генә беләм.

Яңа гына авылыбызга ирле-хатынлы үзбәкләр сыер саварга эшкә килгәннәр. Әллә болар килмешәкләр микән? Авыл тулы эшсез, ник үзебезнең халык саумый? Алар бит безнең сөйрәлеп барган терлекчелек тармагын тартырга өстәмә көч булып килгәннәр. Рәхмәт йөзе белән карарга кирәк аларга. Туган җирдән тиккә генә кузгалмыйлар. Чит җирләргә бәхет эзләп чыгып китә бит кеше. Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар, ә дөнья киң, авыл зур - барыбыз

да сыя. Җирсү хисләрен баса-баса, чит җирләрне үз итеп, халкын яратып яши белүчеләрне киресенчә, бәяләргә кирәк! Бер-беребезгә булган яхшы мөгәлләмә тирә-ягыбызны тагы да ямьли төшә. Туган авылмы ул, торган авылмы – авылның киләчәге шунда яшәүчеләр кулында. Тормыш матур, әгәр яши белсәк...

*Басылды: “Безнең гәҗит” №50 санында (19.12 2012).*

# Атсыз авыл булырмы?

Минем әти атчы булып эшли дип яздым иншамда, башлангыч сыйныфта укыганда. Укытучым Хөршидә апа, “атчы” сүзен кызыл белән терлекче дип төзәткән иде. Атчы һөнәре юк шул, ә барыбер халкыбызның халыкчан телендә дә, әдәби әсәрләрендә дә атчы дигән сүз яшәп килә. Беркемгә сер түгел – авылларда атчылар да, атлар да бетеп бара.

Җәйнең кояшлы бер көнендә, юлда узып баручы BMW машинасындагы кәттә егет, өлкән авылдашыбыз Якуб абыйны җигүле аты белән, машина барган хутка фотосүрәткә кай яктан гына төшермәде икән?! Ат күргәне булмадымы, колакчыннарын тырпайтып бүрек кигән атчы бабай бик сөйкемле тоелдымы - белә алмадым. Күрше әйтә: “Фотохәбәрче булса, малай-җаным белмәсең, берәр затлы журналда Якуб абыйны күреп, сөенербез әле. Ул журналлардан озын ботлы, ярым шәрә кызлар, макияжлы чырайлар күреп туйган инде. Менә ичмасам, бу - чын, ялтыравыксыз тормыш чагылышы!” – диде. Чын, әгәр болай барса, татар авылларының бизәге булган атларны журналлардан карар көннәр килмәс, дип кем әйтә ала?!

Атлар авылларда күмәк крестьян һәм шәхси хуҗалыкларда ярдәмче эшче көч буларак тотыла. Елга бер , сабан туйларында чабу өчен генә ат тотмыйсың, билгеле. Елдан-ел терлек асрау кими, чөнки үстергәч тә, сатып табыш алу мөмкинлеге юк, диярлек. Шулай булгач, нигә чиләнергә? Малай чактан ат янында чуалып үскән авыл агае атка тугрылык саклый әле. Алар инде олы буын. Алардан соң, ата-баба гореф-гадәтләрен дәвам итәм диеп, “тимер атларда” җилдергән яшь егетләрнең ат иярләргә теләге булырмы икән соң? Ирексездән, уйлар 20 еллар элгәрегә кайта...

Авылым!.. Кайда ул синең Хәбибулла абый тәрбияләгән елкылдап торган атларың? “Рассвет”, “Прикамский”, “Коры елгадагы” мал көтүләрең?.. Гөрләп торган ”Маяк” колхозының Имәнкискә фермаларында гына да 600 баш савым сыер бар иде. Ә колхозга өч авыл керә иде. Ә анда эшләгән терлекчеләр саны?! И, авылым, авылым...

Авыл рухи авырлык кичерә. Шәһәрләшә барабыз: сөтне кибеттән алып эчәбез: ишегалдында мөгрәп торган сыерыңнан сауган сөттән каймак аертып, эремчек саркытасы да юк – кибет суыткычында , кил дә ал гына. Өстәлеңдә җитештергән ризыгың үзеңнеке булмагач, авылда яшим дип әйтерлек тә юк. Ашы да – бүтән, эше дә – читтән. Мәсәлән, бездәге күмәк хуҗалыкта терлекчеләр саны, бүгенге көндә, бер дистәгә дә тулмый. Шуларның өчесе атчылар - Юныс, Фәнис һәм Нуретдин инде 25-30 ел ат иярләп терлекчелектә хезмәт итәләр. Урамда буранмы, коеп яңгыр явамы, 40 градус салкынмы яки авырыйсыңмы – аларны алыштыручы юк. Атчыларга ни генә булмасын, елның 365 көнендә дә эшкә барырга тиеш! Илдә нинди генә җилләр исмәде, нинди генә шартлар тумады, сәбәпләр булмады – барыбер атларын калдырып башка эшкә күчә алмадылар. Чөнки ат җене кагылган аларга. Нәселдән килгән, атка тугрылык сыйфаты бу! Әтиләре - Бөек Ватан сугышы чоры балалары, 10-12 яшьләреннән Казанга заготзернага өлкәннәргә ияреп, ат иярләп ашлык илткәннәр. Картлык көннәренә кадәр аттан аерылмадылар. Кара исәп белән санап утырам: ата белән ул икесенә бергә 80 ел чамасы кара, авыр хезмәттә бил бөгәләр. Үзегез санап карагыз, югыйсә, ышана торган түгел. Мәсәлән, минем әтием Ибраһим 48 ел ат иярләп хезмәт итте. Җан дусты - Айсылу исемле атын, кеше кулларына калдырасы килмичә, сәнәген кулына тота алмый башлаганчы эшен ташлый алмады. Ат йөрәге белән, ир йөрәге бер булыр, ди. Ә кайнатам Һилалетдин бигрәк тә ат җанлы иде. Төрле металл, бакырдан ялтыравык тәнкәләрне үзе ясап, камыт, йөгән, эшләяләр бизәп авылда бер дигән ат тота иде. Атка тугрылыкны үлгән сәгатьләрендә дә саклады ул!

Атлар булса, атчылар да булыр – авыл да бетмәс кебек тоела. Республикабызда соңгы 20 ел эчендә атлар саны 2 тапкыр кимегән (интернеттагы мәгълүматтан күренгәнчә), 2011 нче елгы исәп буенча 33 мең ат бар икән. Ярый әле президентларыбыз (элеккесе дә хәзергесе дә дигәндәй) авылда туып үскәннәр. Алар тарафыннан ат үрчетү һәм ат спорты үсешен үз эченә алган программа әзерләнүен хәбәр иткәннәр иде инде. Казандагы һәм Норлаттагы ат заводлары нәселле атлар үрчетү белән шөгыльләнә. Ә эш атлары шулай шәхси хуҗалыкларда гына торып кала микәнни? Хәер, үз соравыма үзем үк җавап таба алам икән ич. Республика күләмендә күмәк хуҗалыкларда

терлекчелек тармагы “җан тәслим” кылып барганда, нигә соң атлар тотарга? Борчылырлык урын күп авыл тормышында. Болай барса, атларны спорт ярышларында, телевизор, китап-журналлардан гына күрү көннәренең килүенә шик юк. Ә бит авыл урамнары җигүле атлар белән күркәм. Хәтта каланың кәттә уллары да, авылны фотосүрәтләрдә ат белән күзаллый.

*“Т.Я” да (№ 9, 24.01.2013)*

# Битарафлык ахырзаманга илтә

Чаллыга баргач, сүз иярә сүз чыгып, газета хәбәрчесе (әле мин актив та түгел!) булуымны белеп алдылар. Бер дә күрмәгән кешеләрнең күптәнге танышлары итеп, кабул итүләре әллә ничек уңайсыз булып китте дииме – ни әйтергә белмәгәннән, уйланмаган сүз әйтеп ташладым: ” И-и, монда да укыйлар мыни әле, язмаларымны?”

- Укып кына калу түгел, телевизордагы сериал артистлары белән яшәгән кебек, гәҗиттә язылган хәлләргә сөенеп тә, көенеп тә яшәп ятыш безнең, кызым! – диде, өлкән яшьтәге бер апа. Алдагы, көтелмәгән сүздән каушап калсам, бусыннан аптырап ук киттем. Һәр әйткән сүз – аткан ук, ләбаса. Хәер, кешегә яла яккан юк, начар сүз язган юк. Вакыйгаларны гел яхшыга борасы килә, тормышны ямьлисе, пычрагыннан арындырасы килә... Чынлап та, бу апа әйткәнчә, газеталарда чыккан мәкаләләрдә тәсфирланган кеше язмышларына, вакыйгаларга битараф булмаганнар бар. Мондыйлар, гәҗиттәге сүрәткә, я булмаса, бастырылган исеменә карап, яшәгән җиреннән торып кына аларның борчуларын уртаклашалар, яхшы теләк телиләр. Ә “БГ” журналистлары әр-хур ишетеп, шул вакыйгаларда зыян күргәннәргә, ачы язмыш сынавы каршында ялгыз калганнарга ярдәмгә баралар. Ә шул ук вакытта, үзара ярдәмләшеп, аралашып яшәгән кешеләр, берәр хәл килеп чыкса, берни күрмәгән, берни белмәгән булып кыланалар. Мин үзем кеше хәленә бик тирән керәм (әйтерсең, үземнеке үземә җитмәгән!), чөнки игътибарсыз кала алмыйм, хәтта үземә битараф булганнарга да...

Ахырзаман галәмәтләре рубрикасындагы «Җитәкченең үченнән саклан!« (№35 сентябрь, 2013 ел) мәкаләсе басылганга айлап вакыт үтте, ә мин Мулланур

абый белән Тәнзилә апа килешә алдылар микән дип, уйлап йөрим. Оныткан булсагыз, мәкаләдә, ир кешенең сәхнәдә йөргән хатын-кызны аягыннан тартып егып имгәтүе һәм миңа иң тәэсир иткәне – шуны күргән ничә пар күзнең күреп тә «күрмәүләре» турында язылган иде. Чын дөреслекне яшерүгә корылган бу вакыйганың асылы – кемгәдер ярашу, шулай ук курку да...

Ахырзаман галәмәтләре - кешеләрнең бер-берсенә булган мөгалләмәләрен «күрмичә-дәшмичә» калу сәбәпле барлыкка килә диясем килә минем. Тәртипсезлекнең йөгәне юк: берсе шома гына үтеп китсә, икенче юлы да шулай үтеп китәчәк. Бу юлы дәшмәгән халык, икенчесендә дә "күз йомачак". Ләкин, шунсы да бар: дүрт аяклы ат та абына, диләр. Эмоциональ кешеләр артык кызып киткәндә ялгыш адым ясарга мөмкиннәр. Ничек кенә булмасын, камил акыллы кеше «суынгач» ялгышын аңлый. Һичшиксез, гафу итү-итмәвенә карамастан, гафу үтенә белергә тиешбез. Тоткан дәрәҗәгә, "югарыдагы" туганга ышыклансаң, вакыйга тагын да катлаулана гына ул. Күпме гонаһ, күпме рәнҗеш... Берсе дә җир өстендә ятмый. Һәр нәрсәнең үз урыны бар!..

Өлкәннәргә, җәмәгатьчел эшләрне калдырып ял итү мәслихәт. Җитмештән узган кешенең нервлары какшавы, гаҗәп тә, гаеп тә түгел. Тормышта ни булмас, ләкин кылган гамәлгә җавап бирү кирәк. Чын ир кеше хатын-кыз белән булышмый да. Әйткәләшүдә җиңелеп каласы килмәсә, ир кешегә бер сүгенеп чыгып китү дә ирләрчә була, ичмасам. Сүгенмәскә закон бар-барын, аннан ука коелмый - кеше имгәтүгә тиң түгел ләбаса.

Күп кенә ирләр, ачы телле хатыннарга түзә алмыйча, кул күтәрүгә баралар. Халкыбызның тел байлыгы чиксез: мәкаль- әйтемнәрен искә төшерү генә ни тора?! Алардан никадәр яхшы киңәш-табыш алырга мөмкин. "Кул ярасы төзәлер, сүз ярасы төзәлмәс", ди. Моны - белгәне бар, белмәгәне бар. Ә белергә теләмәгәне бик күп! Ызгышлар алар – талашырга яратучыларга (белгечләр фикеренчә, алар ызгышлардан - яшәү көче, адреналин алалар) үзен күрсәтергә, фикерен җиткезергә иң кулай урын, менә дигән форсат. Кайчак, үткән вакыйгаларны үз файдасына борганнарга һәм сөйләнгән сүзләрдән гаеп, кер эзләүчеләргә: «Алай түгел, болай гынадыр ул», – дип, яхшы мәгънә салырга тырышам, бер дә курыкмыйча, хупламавымны белдерәм. Игътибар иткәнегез бармы? Хупламасаң, андыйларга сүз барышы ошамый. Кикриләре бик тиз шиңә. Көр күңеленә канат куеп, биеклеккә күтәрелгән «киерелгән түш» кәефсезләнеп, кешеләр янына – җиргә төшә. Әлбәттә, кәефе кырыла. Ә без, хуплыйбыз шул. Рәхәтләнеп кешене, аның гамәлен кушылып тикшерәбез. Гаеплибез. Аферистлар көчле интуицияле була - башкаларның сүзен «егып салып», үз сүзләрен өскә чыгаралар. Андыйлар кеше сүзен тыңламый, киңәшкә колак салмый, үз фикерен

генә алга сөрә. Әйтеп тә, кеше пычрата икән, китеп барырга кирәк, яннарыннан. Гайбәткә катнашмасаң да, тыңлап тору да гөнаһ диләр бит. Ызгыш-талаш сөюче кеше, әгәр тыңлаучы, «әйе» дип хуплаучы булмаса, күккә карап дуласын мени?!. Бер акыл иясенең сүзләре һәрчак күңелемдә йөри. Татарча тәрҗемәсе, алай тәэсирле түгел. Шуңа күрә, күңелемдә ничек сакланса, шулай – үзгәртүсез язам: “Никогда не спорьте с идиотами. Вы опуститесь до их уровня, где они вас задавят своим опытом”. Бик акыллы сүзләр, шулай бит?! Ызгыш-талаш сөючеләр белән булышмыйм, ызгышмыйм. Үзем, фәкать үзем булып калам. Авыл җирлекләрендә һәрберебезнең кем икәнебезне беләләр. Үзеңне нинди генә кабыкка төрсәң дә, үзагач күренә инде ул. Үз сүзеңне өскә чыгарып кына дөреслеккә ышандырам димә. Татарда да бар андыйларга әйтем: «Тинтәк - җиңдем дигән, акыллы - юл куйдым дигән». Кул көче белән дә, әрләшеп тә җиңүче булып булмый. Сабырлык, тәкъвалык җиңә.

Бастырылган мәкаләдәге вакыйгада чит кеше булсам да, тагын шул турыда үз фикеремне җиткерәсем килә. Эшен җиренә җитереп эшләгән, атказанган исемгә лаек булырдай хезмәткәрне эшеннән чыгаруны бары - Аллаһы Тәгаләнең барын белмәгән һәм белергә дә теләмәгән, пычрак күңелле кеше генә башкара ала. “Үзенеке - үзенә кайтсын!”, диясе килә. Ә нигә әйтмәскә, әллә үз гамәлләренә үзләре лаек түгелме, андыйлар?! Тагын шунысын яхшы беләм: үзешчән сәнгать осталарының күзләре начар күргән очракта да, күңел күзләре бик яхшы күрүчән була. Ә Күзкәй авылында һәр икесе дә күрмәс булган... Гадәттә, без – кешеләр, зыянлы, мәкерле кешеләрнең начар гамәлләрен «күрмибез». Шулай, үз-үзебезне нәкъ Т. Шәйхнурова тарыган ситуацияләрдән «страховкалап» куябыз. Ә нәтиҗәдә агрессив, начар күңелле кешеләр «чәчәк аталар», яңадан-яңа начарлыкларга «бөреләнәләр». Җәмгыять үсеше турында сүз дә була алмый, бу очракта. Пычрак гамәлләр бетми торып, кешелек дәрәҗәсе дә күтәрелмәс. Ялганны – ялган, хакны – хак итеп күрсәтмибез, яраклашабыз гына бит, җәмәгать! Гаделлекне табарга, ялганны ачырга тырышып, яклауга мохтаҗларга ярдәмгә, ил буйлап, «БГ» журналистлары гына йөриләр кебек тоела. Кайсы гәҗиттә татар кешесен яклаганнары бар икән?! «Кыйблабызны табышырга ярдәм ит», дип эшчәнлекләренә шигарь күтәргәннәр дә, әле бер районда хакимият белән халык арасында туган аңлашылмаучанлыкны һәр ике якка аңлаталар, әле икенче районда мәдәният өлкәсендә булган вакыйгада зыян күрүчене яклыйлар, йә мәдәниятен күтәрәселәре килә. Кызганам мин журналистларны! Көчлеләрне кызганмыйлар кызгануын, ләкин... Йөзләгән чакрым ераклыклар аша кеше гозерен үтәргә киләләр. Үткән вакыйгаларга ачыклык кертергә булышу түгел, зыян күргән, ярдәмгә мохтаҗ авылдашына да булышырга теләмиләр. Кыйбланың кай якта булуы дөньяви эшләр белән аң

томаланганда, дәрәҗәлерәк кеше белән мөгамәләне саклап калырга теләгәндә – кай якта булса да барыбер. Кыйбла тарафлары, начар гамәлләребезгә Ходайдан зур сынаулар килгәч кенә искә төшә... Һәр җирдә шулай. Һәркем үзен генә кайгырта, ярдәм сораганнарга битараф. Дөнья түгәрәк, көннәрдән бер көн ярдәм үзеңә кирәк булачак! Үзеңә кирәктә, башкаларның сиңа битарафлыгы, һай үзәкне өзә... Сынаганым бар - тавыш-гауганы тормышны үз ягыннан торып кына аңлаган, башкалардан өстен карашлы, үз-үзен генә зурлаучы кешеләр тудыра. Ялгыш фикер йөртүләрен тыныч кына аңлатып карарга кирәк иде аларга. Җитәкчеме ул, гади кешеме – куштанланып, анда булган усаллыкны камилләштерәбез генә. Үз фикеребезне белдермичә, бер кайда да проблема хәл ителми. Яраклашсак, бер яклы гына хәл ителә. Ләкин файдасы кемгә икәне мәгълүм.

...Тукай районы бездән ерак, шулай да, зыян күрүченең кичерешләре күңелемә бик якын тоелды. Шуңа күрә, бу вакыйгада рәнҗетелгән кешедән, гаеплеләр соң булса да гафу үтенерләр, шулай булса, күңеле ярасы аз булса да төзәлер дигән уйлар йөртәм .

*“Безнең гәҗит” №40 (9 нчы октябрь 2013) басылды.*

# Салада - кала тормышы

Сөт эчәргә теләп, тотып савыт,
Кешеләр йөрер төркем-төркем;
Сыер асрамаслар ул вакыт,
Менә шундый көн җитәр, бәлкем.

Бу юлларны укыганнар, Алла сакласын диярләр. Җәйләү-кырларда сыерлар яшел үлән уртласын, абзарларда күңелле генә сыер мөгрәсен. Суыткычларда кибеттән алганы түгел, үзебез җитештергән сөт-катыгы, эремчек-каймагы була күрсен! Ләкин ни кызганыч, бу юлларның авторы да акыл сатып ачу китерә: хуҗалыгыбызда җигүле ат тотып, җир җимереп эшли алган ир белән хатын, ике сыерыбызны да бетереп, кешегә, йә булмаса кибеткә сөт ризыгына йөрибез. Инде быелдан үгезләрне дә урнаштырып, тагын алып үстермәскә дигән фикергә килдек. Ник дигәндә, һәркемгә билгеле - сатып булмый. Мәсәлән, үткән кышта симертелгән үгезнең арткы ботларына гына ия булды - алгы ботларны алучы юк. Бу проблема бер бездә генә түгел икәнен беләм. Ел саен алгы ботлар һәм кабырга үзебезгә кала. Елына ике-өч үгез үстереп суйган безнең өч кешелек

гаиләгә, бу кадәр ит күп, мәсәлән. Гомумән, авыл кешесе элекке еллардагы кебек ит күп ашамый, чөнки хезмәте дә чамалы гына – терлекне күп асрамый, я абзары бөтенләй буш. Терлек асрамагач, ат урынына җигелеп эшләми: печән хәстәрләми, иртүк торып терлек-туар астын җыеп түгәсе юк. Бакчада, кырда бәрәңгенең артыгы терлеккә булыр дип, бар булган җиргә утыртасы түгел. Суган түтәле чүбе утап, помидор-кыяр үстереп кенә умыртып ит ашыйсы килми ул. Эше дә аз, эшенә күрә ашын да аз ашыйсың. Кем әйткәндәй, калория исраф итмисең бит.

Әлегә авыл сөтен эзләп йөрер көннәр ераграк шикелле. Ашату чыгымнарын исәпләмичә, сыер тотучылар бар бит әле. Безнеңише сыер тотудан ваз кичкәннәргә үзләреннән артканны саталар. Бу катлам кешеләр чамасыз тырышлар – сыерсыз тормышны күз алдына да китерә алмыйлар. Аннан, сыерларын артык үз иткәнгә, суярга кызганганнар да юк түгел. Әгәр шуларны уйламасаң, сыер асрамыйсың, билгеле. Вакыты белән күңелемдә канәгатьсезлек туа - шуны язасым килә. Менә безнең авылда 270 хуҗалык, шуларның 25 ендә сыер тотыла. Сөтлебикә яшәгән хуҗалыктан ары да, бире дә тезелеп киткән дистәләгән йортлар. Аларда әллә нигә бер кайта торган дачниклар түгел, сыерсыз төп авыл кешеләре яши. Бар авыруларга каршы вакциналар ясалган, сәламәтлеге тикшерелгән, елкылдап торган сәламәт сыерлардан, үзебез күргән-белгән авылдашларыбызның чиста итеп яңа гына савып-сөзеп биргән сөтен сатып алмыйча, кибеттән “Эдельвейс”, “Вамин” сөтләрен сатып алабыз. Артык горурмы соң без, кеше капкасына гозерләп барырга? Якын-тирәдәге сыер хуҗасын өнәмәсәң, яки сөте ошамаса, 25 тән берсен сайларга мөмкин бит? Югыйсә, 10-15 йортка туры килгән бер сыерның сөте җитмәскә дә тиеш. Чиләк-чиләк сауган сөтне сөт җыю пунктына илтеп тапшыралар - литрын 12 сумнан. Ничек асрыйсы килсен инде ул сыерларны?! Инвесторларның терлекчелек комлекслары таркалса да, бер дә гаҗәп түгел – үзен акламый торган тармак икәне һәркемгә мәгълүм. Аннан, Голландия, Швецария сөтләрен эчәрбезме? Сырларын яратып ашыйбыз, сөтенә дә күнегеп булыр, алайга калса. Ерактан килә дип тә куркасы юк, кибет сөте эчеми лә ул. Ә бәлки чит илләргә ялынасы да булмас, сорау булган продукциягә бизнесны тиз көйлиләр безнең илдә – сөт порошогы ясау сыер асрау кебек авыр түгелдер әле. Бер мәшәкатьсез, секунд эчендә 1 калак порошок болгатып сөтле чәйне ясап эчсәк: “Булган ди, торган ди, җир йөзендә – сыер...”, дип әкиятләрдән генә ишетеп танышмагайлары - оныкларыбыз... Юк, юк, авыздан җил алсын! Язганнарым үзе әкият булсын! Сыерлар бетмәс, иншаллаһ. Язганымча, әле бернигә карамый сыер асраучылар бар. Ни өчен соң без: ”Хәленнән килгән кеше асрасын, булдыралар бит!”, диеп аларга файда китереп, сөтне алардан сатып алмыйбыз икән? Үзебез дә

кушылмасыз сөт алып отарбыз, сыер хуҗаларын да сөендерербез. Аздан да куанабыз бит, күп вакыт! Сатучы да: ”Тукта бетермием сыерымны, аз булса да сөте-каймагы сатыла”, - дип кире уйларга мөмкин. Кайчак күрше миңа: ”Каймак чыгарттым, кирәкмиме”, ди. Үлеп бетеп каймак ашыйсым килми, кирәкми дип әйтмим, сауган, аерткан бит (күпме хезмәт ул!) дип, хакын түләп алып чыгам. Суыткычта булса ашала, ашаудан башкага - ярамый!.. Болары мөгезле эре терлек турында булды.

Җәйләрен һәр ишегалдында тавык-чебеш мулдан була. Ишегалды яме өчен өч тавык, бер әтәчне суйдырмыйча калдырдым быел. Алдагы елда йомыркаиы кая куярга белмәдек, чөнки. “Авылда торып, ничек тавык асрамыйсың инде?!” дигән, язылмаган кануннан тайпылмаган өлкәннәр, пенсия акчасына бодайны тоннасын 8000 сумга сатып алып, каладагы кыз-улларына чиләк-чиләк йомырка җибәрәләр, рәхмәт төшкерләре. Бирүе рәхәт - булганда, анысы... Гаиләңә 10 каз алып үстерсәң, шул җитә. Тик, “Ник мин 10 казга таяк болгап йөрим әле (болынлыклар юк – капка төбе генә, саклап ашатырга кирәк), 20-30 итим”, дип үстерсәң – алучы юк. Алыпсатарлар сата, чөнки. Ә аларда күпкә арзан була. Шәхси хуҗалыкларда үзең өчен җитештергән продукциянең үзеңнән артканын сатып акчага әйләндерү юк дәрәҗәсендә. Әлеге дә баягы ит мәсьәләсенә килгәндә генә, 1-2 ел элек симертелгән үгезләрне без - үстерүчеләрдән сатып алып, ит сату ноктасына илтүче үзенә күрә бер бизнес белән шөгыльләнүчеләр бар иде. Алар да юк, хәзер. Чөнки базарларда һәр сату ноктасы үз кешеләре белән генә эш итәргә җайлашканнар. Анда да бәлки күрше Мари, Чуваш республикасыныкылар үтеп кергәндер, кем белә?! Нишләргә генә кала соң бу, авыл кешесенә? Бар кеше дә бюджет өлкәсенә сыешып бетәргә штаты юк бит, җирле идарәнең. Бер генә юл бар – авыл тормышына күңеккән күңелне мәҗбүриләп шәһәргә борырга. Ә анда эш бар! Җирсү хисләре күңелләрен артыгы белән биләмәгән алдыңгы карашлы кешеләр күптән инде тәртәсен калага борды. Казан каласында тәүлекле эшләрдә эшләп, шәхси йортларында 2-3 көнен дачада ял иткән кебек ял итеп яшиләр дә, тагы тәүлеген эшләп кайталар. Көн дә барып-кайтып эшләүчеләр дә бар. Әйбәт яшиләр – эшче катламга хезмәт хакы түләнә бит ул. Крестьянга гына түләнмәгән һәм түләнмәячәк тә...

Ничек кенә бу җиргә береккән күңелләрне үзгәртәсе? Ә бит, нинди генә авыр хезмәт булмасын, тамырыңны тирәнгә җибәреп яшәгән җиреңдә хезмәт итү бер бәхет санала иде. Эшләп аргач, күк йөзен иңләп бер кутәрелеп караганда да күз карашың иңләгән күк йөзе дә фәкать синеке генә күк тоела ул. Иркен итеп сулыш алу да үз җиреңдә генә рәхәтлек бирә шул. Чит җирләрдә хезмәт итүнең мондый ләззәте була алмый. Шәһәрдә гомумән, бер рәхәт нәрсә күрмим мин,

мәсәлән. Тик ни хикмәт, бар да акчага барып тоташа. Акчасыз тормышның рәхәте була алмый. Нишләп бетәр бу авыл тормышы? Илебез сәясәте авыл хуҗалыгы тармагының да  тамырын корытты. Авыл хезмәтчәннәрен җирдән аерды. Якын киләчәктә барыбыз да якын шәһәрләргә эшкә урнашып, авылдагы шәхси йортларыбызда дачниклар сыйфатында гына яшәрбез күк тоела. Ә ашар ризыкны кем җитештерә булып чыга инде?

*“Нәрсә ашарбыз?” исеме белән “ТЯ” №8 (18 июль 2013) басылды.*

# Эшегезне яратыгыз, ләкин чамасын белеп

Яратып укыган газетабыз  “Т.Я” ның 18 нче сентябрь санында  “Әллә безнең эш җиңелме?” дип исемләнгән мәкалә басылды. Укып чыккач, чарасыз калган клуб хезмәткәренә  нинди  җылы сүз язый м икән дип кулга каләм алдым. Хәер, җылы сүзгә дә, киңәшкә дә мохтаҗ түгел ул. Фәкать клуб хезмәткәрләренең хезмәте бәяләнмәвенә ачынып, мәдәният хезмәткәрләренә үзебезне яклыйк, диеп газета аша мөрәҗәгать итә.  Күңелемдә авыр хисләр кузгалды...

Күп еллар  авыл мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкардым. Ул вазыйфам – декоратор, режиссер, методист, сценарист, хореограф, тәрбияче, язучы (берничә пьеса да яздым), тегүче-модельер, сәхнә киемен юып, җыртык-сүтеген тегүче дә, буяучы-маляр, йөк ташучы (декарацияләрне кем күтәрә?!), кирәк вакытында идән юуучы, чүкеч тотып кадаклаучы да, һ.б. эшләрне берләштерде. Эше шул кадәр күп булсада, бер дә авырлыгын тоймадым – и-ии, яраттым да инде эшемне! Ашкынып барам, очып-очып эшләп йөрим. Өйдә булганда, ни эшлисем турында план корам. Күңелгә чара үткәрү турында идея килә дә, тәмам аны сәхнәгә чыгармыйча торып, ашавым - ашау, йокым - йокы булмый иде... Ходайның рәхмәте белән, төрле жанрда иҗат итеп, кабатланмас чаралар сәхнәгә куела килделәр.

...Авылыбызның уңган-булган, чибәр ханымнары нинди генә бәйгеләрдә катнашу бәхетен татымадылар икән?! Нәни кызлардан алып буй җиткән сылуларыбыз тоткан бәйгеләр тамашачылар күңелендә гомергә урын алдылар. Кадерле әбекәйләребезнең ”Супер әби” бәйгеләрендә катнашулары өчен аркаларыннан чәбәкләп-чәбәкләп сөясе (татар карчыкларын сәхнәгә чыгару үзе бер могҗиза!) килә.

Ир-егетләрне пассив дибез, чакыра белеп чакырырга гына кирәк ! “Ир солтаны”, “Ягез әле, әтиләр” кебек бәйгеләрне искә төшерү генә ни тора?! Бу бәйгеләр генә. Минем уйлавымча, сәхнә ул талант ияләре чыгышы өчен мәйдан гына түгел, авылның мөнбәре дә. Ә мөнбәргә мәдәни чыгыш ясарга теләүче һәркем күтәрелсен. Мәсәлән, үрнәк гаиләләрне ник менгермәскә сәхнәгә? Афәрин, яши беләләр! Үрнәк ал да, яшә матур итеп! Бергә 50 ел гомер кичереп, 5-6 бала үстергән игътирамга лаек парларның ”мөнбәргә” менергә хакы юкмы? Күрергә, бәяләргә кирәк авылдашларны! Тамашачылар, яңа язып үткән ”Пар балдаклар”, “Алтын туйлар” кичәләрен карап beləсезме күпме киңәш-табыш, яхшы сыйфатлар туплый үзенә? Халкыңны данлау да була ул.

Кайвакыт кичә үткәрү өчен юктан да сәбәп барлыкка килә: матур гына яшәгән килен белән кайнана арасы бозыла . Татуландырасы килә, ләкин “ут кызуында” кеше киңәше кирәкмени?!. Бер төн эчендә, кайнаналарны олылаучы, киленнәргә киңәш бирүче тәрбияви чара - “Кайнанам талмас канатым” күңелдә туа...Үзләре килен булып, аннан кайнана булып яшәгән хөрмәтле әбиләр, киңәш базары ачалар – чакыр гына... Бу мисал нигезендә мәдәни агартуны искәртәм.

Ун ел эчендә өч тапкыр Имәнкискә авыл телевидениесе (ИАТ) “күрсәтте”. Сәхнәдә видеосюжетлар белән, нәкъ ТНВ ның бер көнлек тапшырулар программасы кебек күрсәтелде. Ә нәрсә, көтеп торасымы берәр каналдан безнең авыл уңышларын, горурланырдай кешеләрен күрсәткәнне? Төшермиләр алар безне. Без – аларга түгел, үзебезгә - үзебез кирәк! Журналист та, диктор да, корреспондент, видеооператор, тапшырулар редакторы да булырга туры килде. Зарлану юк. Яраткан эштән зарланалар мыни? Нигә язаммы, боларны? Шуның кадәр хезмәтне кирәксезгә чыгаручы кеше - җансыз-хиссез кеше ул! Шушы чараларны финанслаучы директор Хисам абый Исмәгыйлев булды. Һәрчак эзләнде, тапты, тәэмин итте. Моңа күп үҗәтлек, тырышлык кирәген һәркем аңлый. Кабинет саклап утырып, чаралар үткәрергә акча китереп бирмиләр шул. Тырышкан таба, ташка кадак кага, дигән борынгылар.

Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәте бик кирәк, бу болгавыр заманада. Мәкалә авторы язып үткәнчә, без психологлар да әле. Әле мондый хәл, әле тегенди уңышсызлык, фаҗига, өмет киселү... Киләчәккә ышаныч уятасы килә – күңелдә ”Киләчәккә сәяхәт” кичәсе туа. Кем күргән әле киләчәк көннәрдә ни буласын? Сәхнә кадәр сәхнәдә уйныйлар икән, ә нигә булмасын киләчәкнең без хыялланган үрләре? Бер кечкә булса да, тамашачылар күңелендә ышаныч туа. Ә ышаныч яшәргә көч бирә. Димәк, без мәдәни агартабыз, талантлар үстерү өстенә, киләчәккә ышаныч белән карарга да өндибез.

Катнашучы юк диюләренә исем китә минем. Авылыңның сәхнә түренә утыртып хөрмәтләрдәй, горурланырдай кешеләре булганда тематик кичәләр оештырыр гына. Балалар шул кадәр актив, һәр чарада катнашырга әзер, өйрәтеп кенә өлгер...

Ялгызы гына бала үстергән ул тол хатыннарны гына бәяләү ни тора?! Игътибар белән карагыз әле авылдашларыгызга , кичәләр оештырып сәхнә түрендә бәяләмәслекмени алар? Халык мәнфәгатьләрен, җәмгыятьне күтәрү өчен гомерләрен багышлаган җитәкчеләребез белән горурланмаслыкмы? Мин үзем шундый шәхесләрне күреп, соңгы елларда гына да "Замандаш", "Без көчлебез", "Чын күңелдән" кичәләре үткәрдем. Тамашачылар яхшы кабул итте.

Шунысы куанычлы, бездә мәдәният йорты мәктәп белән тыгыз бәйләнештә. Укучылар да, укытучылыр да активлар. Һәр авылда да мәктәп директоры мәдәни җанлы булса, эшләр җиңелрәк бара, сүз дә юк. Ул яктан бәхет булды. Күп еллар дәвамында Гаянова Кәүсәрия Гаяз кызы гозерләрне гел уңай хәл итте. Сездә ничек , иптәшләр? Бездә шулай!

Мәкалә минем күңелне башка яктан күзгаткан иде, ә мин кереш өлешен күбрәк язып ташладым. Автор әйткәндәй, үзебезнең эшне үзебез язмасак, кем языр. Ләкин мәдәният хезмәткәрләре иҗат-сәнгать эшләре белән "авырып", үзләрен оныталар, иптәшләр. Менә шулай бәйрәмнәрдән - кичәгә, кичәдән - спектакльгә, спектакльдән -бәйге-тамашаларга күчә-күчә, 22 ел хезмәт юлымны үткәнемне сизми дә калганмын. Өемне, иремне, балаларымны икенче планга куйганымны соңрак, хезмәтемне кирәксезгә чыгаручы булгач кына аңладым шул. Монысы аерым тема. Гаилә-эш темасына әйтер сүзем бар.

Артистлар, гомумән сәхнә әһелләре, ни өчен гаилә корырга ашыкмыйлар? Ә парлылары нигә аерылалар?! Сәхнә тормышыннан ерак торганнар: "Тотрыксыз алар", - дияргә яраталар. Алай түгел ул, иптәшләр! Төп сәбәбе - сәнгатькә артык бирелгәнлек. Әгәр сәнгать кешесе гаиләле икән, тормыш иптәше аңа эшләргә комачауламаган, яки аңлап эшләргә ярдәм иткән. Ни өчен бүлеп, яки-яки дип язаммы? Комачауламаган - үз иркенә куйган. Ярдәм иткән - аңлашып-ярашып яшәгәннәр, димәк. Болар икесе ике нәрсә. Мәдәният хезмәткәре вазыйфасы, эш вакыты белән исәпләшә торган хезмәт түгел. Эш вакыты кысаларына сыеп хезмәт итүче хезмәткәр ул - урын биләүче генә. Халыкны күңелле һәм файдалы ял иттерү максаты куйсаң, гаилә тормышын, шул исәптән, сәламәтлегеңне дә "онытырга" кирәк. Россия күләмендә танылган Абдуллов кебек актерлар яман шештән үлеп киттеләр, үзләрен ахыр чиккә куеп, "онытылып" эшләгәнгә бит. Иҗат эше баштан аяк чумып эшләгәндә генә татлы

җимешен бирә. Ул җимешне тамашачыга тәгъдим иткәнче, әллә никадәр ачысын татып өлгерәсең. Күпме нерв сарыф ителә: ” Әй, ни булса - шул булыр!”- дип кенә булмый шул. Чөнки куеласы чара өстендә эшли-эшли, балаң күк газиз булып бетә. Идеалыңда тудырып, сәхнәгә “тәпи йөрергә” чыгарган җанлы чара бит ул! Тамашачылар бер нәрсәне белми: күп көчләр салып әзерләнгән чараның тамашачылар караганы - салынган хезмәтнең 70-80% чамасы гына ул. Сәхнә артының катлаулы проблемалары “йота” аны. Һәряктан гүзәл, хөрмәткә лаек, талантлы авылдашларыбыз бар. Көндезләрен эшләп кайтып, кичләрен репетицияләргә йөреп, сәхнәдә чыгыш ясаулары бер дә җиңел түгел. Игътибар иткәнем бар. Һәр авылда шул бер үк талант ияләре. Ә бит, арттырып язсаң, ярты авыл халкы җырга да биергә дә бик маһир. Тамашачыларны сөендергәннәре өчен, Ходай, әҗерен күпләп кайтарсын, үзләренә!

Билгесез авыл клубы мөдире колхоз эшенә кушуларыннан зарланган. Зарланмыйча, кичен тагы үз эшеңә барырга кирәк! Кичке эш сәгатьләреннән азат итсеннәр алайса, клуб хезмәткәре дә адәм баласы бит. Тик колхозның эше түгел, үзе дә калмады бугай ич инде?! Мөгаен, күп еллар эшлидер, элекке елларны истә тотып язгандыр. Ул еллар да онытылмый...

Хәтерлисезме, 1990 нчы еллардагы клубыгызны? Соңгы еллар б-н чагыштырыгыз әле. Хәзергесе яхшырактыр, шулай бит? Әгәр, элеккесен сагынсагыз, яшь чагыгызны хәтерләткәнгә генә уңай бәялисездер. Ул вакытта, сез ата-ана булып, балаларыгыз клубка йөрсә, клубны тәнкыйтьләр идегез. Ул елларда да клубта эшләдем мин. Советлар Союзы исән чакта, яшьләрне контрольдә тоту булмады. Дөрес, комсомол оешмасы бар иде. Аннан, халык та культуралырак иде. Мәдәният йортларының эш вакыты югарыдан расланмады микән, әллә буйсынмадылар микән, әйтә алмыйм - төнге сәгать 12 дән иртә бикләнмәде ул. Сәгать бергә кадәр эшләгән чаклар да гадәти иде. Чөнки һәркөн диярлек, 2 шәр серияле совет, һинд кинолары күрсәтелә. Халык күп, өйдә компьютер юк, каралы- аклы телевизор барлы–юклы 2 канал күрсәтә (анда да, өлкәннәр татарча - Казан каналын карый, беренче каналга бордырмый!). Колхозда эшләүче яшьләр күп. Кыскасы, клуб тулы кеше. Кино беткәч, дискотека. 1-2 сәгать биемичә туктау юк. Авыр иде ул елларда яшьләр белән эшләве. Яшьләрнең клуб хезмәткәренә таләбе югары иде. Әле җитмәсә, СССР таркалып, илдә тәртипсезлек башланды. Тормышлар болганды, клубларга йогынтысы зур булды. Илеңдә булмаган тәртипне клуб директоры гына каян алып урнаштырсын? Елның 365 көнендә дә клуб ачык булырга, алар теләгәндә генә ябылырга тиеш! Шулай булмаса, вату-җимерү. Җимертеп булмый инде - эшлисең... Кайчан кайткан үсмер бала өенә? Кайчан кайтса да, эти-әнисенә, син

кайда булдың дигәч, клубта идем дип җавап кайтаргандыр. Чөнки, әйтүемчә, бик соң ябыла иде ул. Ә кем белә, бәлки ул клубта булмагандыр да?.. Ә хәзер балаларга контроль ясавы җиңелрәк. Ата-ана белә: клуб кичке сәгать 10 га яки 11 гә кадәр эшли. Клубта тәртип яхшы һәм күптәннән - Хисам абый Исмәгыйлев мөдирлек иткән вакытлардан килә. Бу тәртипне "революция" ясап яулады ул. Революциягә тиңләми хәл юк, еллар дәвамында "үз иркемдә ни эшләсәмдә ярый" принцибы белән чыгымлаган яшьләрне "тәртә арасына" кертү җиңел булмады. Нәкъ тарихтагыча, астагылар - өстәгеләрнең идарә итүенә риза булмадылар. Яшьләр, тәртип урнаштырырга теләгән Хисам абыйны "бәреп төшерергә" тырыштылар. Олы яшьтә булсада бирешмәде, барыбер тәртип урнаштырды. Хәзер дә ул тәртип дәвам итә: тәмәке тарту тыела, исерекләр клубка кермиләр, керсәләр дә куып чыгарылалар. Сездә ничек? Бездә шулай! Ләкин яшьләр, менә шул матур, якты мәдәни учакларны кирәксенмиләр дә: һәрберсендә машина, машинада дөмбер-дөмбер үзе теләгән музыка, затлы телевизорлы кебаб-кафелар... Тормыш-көнкүрешләр башка. Ләкин, яшәсен авыл клублары! Ул яшьләр дә олыгаялар, ул дөмбердәп торган музыкалар яшь барган саен туйдыралар. Адәм баласына чын сәнгати театр-тамашалар кирәк. Тимәгез, клуб хезмәткәрләренә! Рухи азыксыз яшәү ямьле түгел!

Мәкалә авторы, балаларының, әниләрен көтеп аргач, елап йокыга китүләрен йөрәккә тиярлек итеп язган. Мин мәдәният йортында эшләп йөргәндә, ике балам үсеп "канатярганнар икән"... Күңел күземне еракта калган елларга төбәп, нәни чакларын барлыклап, еладылар дип тә яза алмыйм икән. Дөнья еламаска өйрәтә адәм балаларын: ике бала бер бәйрәм күрмәделәр генә түгел – бәйрәмнең "җәфасын" татыдылар. Ул көннәрдә әнкәләре капкалап алырга, тегеләй ит, болай ит дип эш кушарга гына күренеп киткәләде. Берберсенә иптәш булып, эш эшләп, өй саклап үстеләр. Олысы бик иртә олыгайды, бала булырга "вакыты" булмады. Әниләре халыкны мәдәни агарту юлында армый-талмый чапты. Декрет ялында да ни кешесе, ни иҗат-сәнгатькә бәйле күңеле тыңгы бирмәде - эшкә атлыгып торылды... Шул дәрәҗәдә сәнгать эше мине үзенә суырды, хәзер уйлыйм да, дөрес эшләмәгәнмен икән дип, газаплы уйлар кичерәм. Күз алдыннан "гомер эпизодлары йөгерә".

Төннәрен күңелгә килгән сценарийларны торып язам...

Барабанлы кер машинасында кер юам. Алюмин капкачын бидон өстенә куеп, әледән-әле кулны корылап күңелгә килгәннәрне терким...

Өстәлдә иркенләп утырып язган чакларымда, кызларым яныма: "Әни...", - дип киләләр. Ә мин, аларның теләкләрен үтисе ана: "Китеп тор әле, кызым, хәзер язып кына бетерәм", дим. Ә язып бетереп булмый. Бала нәүмизләнеп китеп бара. Аннан өйрәнделәр инде, әниләре язганда килмәс булдылар...

Бервакыт ата-аналар  җыелышы ничектер көндез булды. Мәктәпнең укыту эшләре урынбасары ялкынлы чыгыш ясый: “79 баланың көндәлеген чирек саен өчәр тапкыр карап чыгам. Елына 948 көндәлек тикшерәм. Үпкәләмәгез, чын дөресен әйтәм, балаларыгызның көндәлеген елга бер тапкыр да кызыксынып ачып карамаучылар бар арагызда...” Аска таба убылып төшәрдәй булдым. Оят иде, оят - берсе мин идем бит аларның. Ул көнне утырып көндәлек кенә түгел, дәфтәрләрен карадым. Тик бик тиз эшкә барыр вакыт җитте... 22 ел кичен өйдә булмаган ана бит мин! Кичләр бит алар, гаилә сәгатьләре. Сәнгать җитәкчесенең эш вакыты гаилә өчен яраклы түгел бит аның: балаң мәктәптән кайтып кала, йә юк - түгәрәкләр эшенә чыгып китәсең. Анда сине ишек янында тезелеп көтәләр. Ярый  хуп, бию өйрәтеп шыбыр тиргә батып өеңә кайтып киттең,  ди. Кайтып кергәндә, кичке якка эшкә барырга бер сәгать вакыт калган була. Ашарга да пешсен, терлек тә каралсын - хет нишлә!  Мәдәният йортын вакытында ачам дип, чабасың. Чапмыенча,  көн саен аралашкан яшь дусларың көтеп торганын беләсең.  Кирәкле кеше булуыңны тою рәхәт мизгел бит ул!  Була шундый вакытлар, кичке 7 не суга сәгать, күрәм, ашыгам. Шул ашыккан чакларымда өйдәгеләр тарафыннан:  “Сәгатьне күрәсеңме?” - дигән кисәтү ясала.  Димәк, кичке 7 дән соң миңа өйдә урын юк. Язылмаган канун - мин өйдә булырга тиеш түгел! Түгел!.. Минем өчен кызык та, кызганыч та...

Әйе, иптәшләр, хатын-ана сәнгать  җитәкчесе икән, бу – ир һәм балаларның бәхетсезлегенең бер өлеше.  Аңлаган, эшләргә рөхсәт иткән иргә рәхмәт! Эшләтмәгән булса, тагында рәхмәт буласы булган...

Ун еллар элек, сабан туенда сәхнә вазыйфасын трактор арбасы башкара иде әле. Вакыты белән, иске кинокадр кебек, шул чаклар исемә төшә. Келәм, аллы-гөлле ситсы, чигүле сөлге, шарлар белән бизи идем, шактый матур  була иде. Шул матурлык өстендә сабантуйлар алып бара идем. Ә арба астында, кызуда әлсерәмәсен дип бәйләп куелган тәкә янында, матур күлмәк-бантикларда минем ике кыз: “Лимонад эчәсе килә, морожный алыйк инде. Бетәме  әле, кайтыйк инде”, -  дип тыңгысызлыйлар иде.  Берәр якын кешегә ияртеп кайтарып җибәргәч, бераз җиңел була торган иде. И-и, Аллам, шушыны гына искә төшергәч тә, сәнгать җитәкчесе балалы булырга тиеш түгел дип нәтиҗә ясыйм. Әнә шулай кайгыртучан ана булып булмады инде. Эшләп-эшләп тә яхшы хезмәткәр дә булып булмады.

Мәкалә авторы , “Кит ул эшеңнән”- дип әйтергә урын калдырмаган. Юк, китмим, - дигәнсез.  Эшләгез, зарланмагыз! Эшегезне яратыгыз, ләкин артыгы белән яратмагыз! Эшегезгә караганда үзегезне, якыннарыгызны яратыгыз! Эш - эш ул. Көннәрдән бер көн синеке булмый.  Ә гаиләң - синеке! Балалар бит,

үзебез үлгәч тә, фәлән улы яки кызы исеме белән йөри. Эшнең, фәлән кеше эше дигәннәрен ишеткән юк әле. Ничек кенә тырышып эшләп, уңышка ireш - барыбер гаеп табып пычратучы табылыр. Кеше белән кеше арасын бозып, гайбәттән тәм табучы, кеше каралту юлы белән үзен агартучы кешеләр бар бит алар. Андыйларның “вазыйфалары” әнә шулар, ә кайдада эшләп файда китерү түгел. Сәнгать корбаны булмагыз!

Дөнья тулы гыйбрәт. Безгә сабак кына аласы да, сакланасы канә. Хезмәтләрен артыгы белән ятратканга сәламәтлекләре, хәтта гомерләре белән түләүчеләр, һәркайда бардыр. Лаеш районында да бар.

Дистәләгән еллар мәдәниятны үстерүгә бар тырышлыгын биргән, күп конкурсларда җиңү яулап, “Мурзилка” балалар театры белән Мәскәүгә чаклы барып җиткән Светлана Мурзина;

Әйтеп бетермәслек күп хезмәт, чыгымнар сораган Бөек җиңүнең 65 еллыгы чараларын, данлы Каравон бәйрәмнәрен оештыруда  күп көч салган сөекле мәдәният бүлеге башлыгыбыз Людмила Макарова;

Авылыбызның булдыклы, искиткеч кешелекле җитәкчесе Рәшит Галиев һ.б. Болар барысыда  диярлек хөрмәт яулаган атказанган хезмәткәрләр. Бик аяныч: халык өчен, җәмгыять өчен җан атып эшләп, алар ярты сәламәтлеген салдылар, эшләреннән китәргә мәҗбүр булдылар, хәтта гомерләре белән “түләделәр”.

Ә яман уйлы кешеләр өчен барыбер эшлекле була алмыйсың. Хәер, җан атып эшләгән кеше беркайчан да  кеше яхшы сүз әйтсенгә эшләми - күңеле шулай кушканга хезмәт итә. Шуңа күрә, никадәр ачынып: “Эшегезне артыгы белән ятратмагыз!”, дип  сөрән салып кычкырсам да, эштән ямь һәм тәм тапкан кеше исе дә китмәячәк. Ничек эшләгән булса, шулай дәвам итәчәк.

Шунысы куанычлы, ярый әле без, 1937 нче елларда яшәмибез. Халыкка хезмәт иткән өчен зинданнарда  гомеркәйләребез үтәр иде. Ә бит ул шомлы елларда да белемле, халкы өчен хезмәт иткән, булдыклы кешеләр халык дошманы исеме астында кулга алынганнар. Һе, халыкның  дошманы булмаган алар! Авылның берничә көнчелекле, пычрак  җанлы кешеләренең дошманнары булганнар. Ни гаҗәп, начар уйлы кешеләрдә аферистлык галәмәте көчле була. Үз артларыннан йомшак, үз фикере булмаганнарны ияртә алу шаукымы  мулдан бирелә.  И-ии, үзләренең кулларыннан эш килмәгән, кеше уңышларына эче пошкан, кеше күралмас шапшак җаннар...  Авылдашларын, хәттә якын күршеләрен озатырганнар бит, Сталин килеп  алып китмәгән!..  Хәзер дә бар

алар безнең арада. Ул мескеннәр көнләшүдән, һәркемгә тигез нурын сипкән якты кояш җылысын да, искән ягымлы җилне дә тоймыйлар, аяк астындагы туендыручы Җир-ананы да күрмиләр. Югыйсә, Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәне камил итеп яралткан: дөнья матурлыгын күрү өчен күзле иткән, илләрне аркылыга буйга иңләп йөрергә аяк, эшләргә парлап кул биргән; яратырга күңелгә хис салган, акыл... Тагы ни җитмәгән?! Дөнья кысан мени соң? Сиңа комачауламыйча, халыкка хөрмәт йөзе белән хезмәт итеп, эшеннән тәм табып эшләгән кешене таракан урынына күреп "басып сыткач", әллә соң дөнья киңәеп, матурлыгы ачылып, күңелгә рәхәтлек килә микән?! Бәлки шулайдыр... Рәхәтлек өчен әллә ниләр кыла шул адәм баласы. Ләззәт татып, хезмәт итә. Тантана итәр өчен начарлык эшли. Һәркемнең үз күңел калыбы. Тагы ни диярсең?! Тагын, эшегезне яратыгыз, артыгы белән яратмагыз! - дияр идем.

*Кыскартылып "Татарстан яшьләрендә" (№38,*

*27 нче сентябрь 2012 нче ел) басылды.*

## Күңел кояшың сүнмәсен!

*Чәчкәләрнең нигә кирәге бар,*

*Өзеп бирер кешең булмаса?!*

*Нәрсә соң ул күктә янган кояш,*

*Үз кояшың балкып тормаса.(Нәсимә Абзалова)*

Бу җиһанда тулы бәхетле булу өчен күктә янган кояш кына җитми шул, күңелеңдә балкыганы һәм фәкать синең өчен генә янганы кирәк. Югарыда язып үткән җырның тирән мәгънәсе - ялгызлар күңеленә генә тәэсир итә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в): "Толларның бусагасы алтын булса да, сәдака тиеш", дигән. Сәдаканы акча дип кенә аңлый әле күпләребез. Бу очракта җылы сүз күздә тотыладыр дип уйлыйм мин. Хәер, җылы сүз дигәне дә ике яклы бит әле. Юкка мыни, толларның кыңгыраулы була шул, дип үпкә-зарларын белдерәләр алар. Мин үзем парлы кеше. Кайвакыт шундый уйлар килә, шушы кадәр зур өйдә ялгыз калсаң нишләрсең? Яшәү тирәлегемдәге барлык толларны уйдан кичереп чыгам. Бик күпләргә соклану, хөрмәт хисләрем яңара. Авылыбызда яшьли тол калган Хөсниҗамал һәм Зөлфия апалар дүртәр баланы

үстереп олы тормыш юлына чыгарганнар. Руфия апа биш баланы үстереп кеше иткән. Ике, өч бала белән тол калучылар тагы да күп. Толлыкны, ялгызлыкны мактап: ”Рәхәтләнеп үземне-үзем карап яшәп ятам”, диючe юк бугай. Мин бервакыт, яшьлегем белән, эчәргә яраткан ирен җирләгән хатынны, хәленә кереп, тынычландыру уе белән: ”Ул кадәр бетенмә әле. Менә фәлән ир ни хикмәт кылган, ишеткәнсеңдер, шул гыйбрәтләрне уйлап булса да тынычлан азрак”, дидем. Ә ул: “Алай түгел икән шул ул... Гел яхшы ягы кына искә төшеп үзәкне өзә бит!” димәсеңме?! Башка мондый сүзне ялгыш та әйткәнем юк.

Парсыз калса да, балалы толлар ялгыз калган дип әйтеп булмыйдыр әле. Иллегә җиткәндә тол калган авылдашымның сүзләре күңелемә кереп калды. “Язмыштыр... Башны ташка орып булмас ансы... Тормыш иттек, 3 бала үстердек. Кемдер, насыйбы булмыенча, кияүгә дә чыкмый кала бит”, диде. Сабырлык, язмышка риза булу һәркемгә дә бирелми.

Сөенеп, сөелеп, сөеп яшәгәндә күңел кояшы якты яна. Күңел сүрелдеме, тормыш та сүрәнләнә. Тол хатыннар балалары хакына сүрелдерми бугай аны. Тормыш учагында яна-яна, балаларым кимсенмәсен дия-дия тырышалар алар. Ә тол ирләр алай ук була алмыйлар шул. Ялгызлык ачысын исерткечләр белән баса торгач, бар тормыш яме, йорт бәрәкәте китә. Ирләр үзләре дә бала кебек кайгыртуга мохтаҗ - пешереп ашатырга, сүтек-җыртыгын тегеп, өс-башын юарга кирәк. Хатын белән яшәгән ир бу хезмәтләрне башкарырга сәләтсез була. Хатыннары вафатыннан озак та тормый ирләрнең кабат тормыш корулары бәлки шуннандыр дисәм, юктыр, мондый ярдәмне ялгыз туганына һәркем башкара ала. Күңел җылысы кирәк адәм баласына! Күп вакытта озын телләләр кабат өйләнгән, кияүгә чыкканнарга “үтә дә хисле” ярлыгы тагалар. Парлы түшәк тансыккан, имеш. Ялгызларның җан ярасына тия бу сүзләр. Ир белән хатынның бар тормыш мәгънәсе шунда мени соң? Һәр парлының үзенчәлекле ярашып-ятатышып бер җан булып яшәвенә мисал итеп, әти болай дия иде: “Габдулла әйтә икән, өйгә кайтып Мәстүрә апаң белән әйткәләшеп алмасам, җанга нидер җитми кала, ди икән, дип”. Әйе, барлыгыңны белдереп әйткәләшеп алу өчен дә, пешкән кайнар ашың белән сыйлар өчен дә өчен дә, кара-каршы утырып чәй эчәр өчен дә тормыш иптәше кирәк... Парлы озын гомер кичергәннәрнең кайсы да вафат булганын ишеткәч, “ашын ашаган инде, яшен яшәгән...” дип, ялгыз калган әби-бабайны артык кызганмыйбыз. Аңлап бетермибез бугай. Берничә ел элек, 50 һәм аннан да күбрәк парлап гомер кичерүчеләрне мәдәният йортына чакырып “Алтын туйлар” кичәсе үткәрергә туры килде. Кичәне уңышлы үтешенә әзерлек рәвешендә йортларында әңгәмә корып материал туплаганда, чын тормыш мәктәбе үттем. Үземнең кичерешләремне, сүз иярә сүз китеп, өч студент

балалы тол хатын белән уртаклашырга туры килде. Сүзебезне йомгаклап, ул миңа әйтә: “Беләсеңме, Гүзәл, тол булсам да, балалар өйдә чакта мин бәргәләнеп, елап яшәмәдем. Тулы булмаган гаилә дә – гаилә ул. Шул ук хезмәтләр, кайгырту, балаларга бирәсе тәрбия, наз... Тормыш тулы көчкә бара. Балалар таралгач, япа-ялгыз яшәүләр бик авыр икән. “Алтын туйчылар” өлкән яшьтә булсалар да, бер-берсенә ничек кенә кирәк әле! Яшәсеннәр, бер-берсенә иптәш, терәк булып. Һич югы тагы 5-10 ел... Яраткан кешең белән яшәлгән 50 ел гомер, 5 ел күк тә тоелмыйдыр ул!..”

Ходай безне парлы итеп яралткан. Ләкин вакыты җиткәч, үзе белеп парыбызны да үз хозурына ала. Тигез, озын гомерләр бик сирәк парларга тәти. Кемне ничек сынайсын үзе белә, Ходай.

...Гыйбрәтле сүз, вакыйгаларга зур игътибар бирәм мин. Бервакыт өлкән яшьтәге ир авылдаш кыз туганы белән сөйләшеп утыралар. Үтеп киткән яшь, тол хатын артыннан, мактыйсы килеп, әйтеп куйды, абзый кеше: ”Кара инде син, Римманы (исеме үзгәртелде), маладис! Бер генә ир-атка да күтәрелеп карамады. Ике баланы үстереп җиткерде.Үрнәк тол хатын, маладис...”

-“Маладис... кеше өчен! Ә үзе өчен нәрсә? Ни рәхәт күрде соң ул бу тормышта?” дип сүзен бөтенләй хупламады. Абзый үз фикерендә калып, “маладисын” кабатлап калды, мин - очраклы кеше, сүзгә кушылмыйча, күңелдән җавап эзләдем. Тормышы күз алдымда. Йә, ни рәхәт күрде? Ялгызлык, ялгыз тормыш тарту, бар барлыгын балаларына багышлау, тормыш максатлары белән шыплап тулган йокысыз төнле ялгыз түшәк...

Тормышка артык исе китмичә, балаларын язмыш кочагына ташлап, ирдән-иргә йөрүчеләр дә бар. “Унга бар, уңганчы бар”, дигәннәр. Мин монсын аңлый алмыйм. Һәр кеше үзенчә гомер итсен. Мәңгелеккә күчкән яшьлек ярларына гомергә тугрылык саклаучы толлар күбрәк. Күңелләренә башка берәүне кертмичә яшиләр алар. Мәшһүр “Әлдермештән Әлмәндәр” спектакле персанажы - Әлмәндәр карт: “Рәхмәт, Хәмдебану, 25 яшеңнән тол калып, ялгыш кына да ирең рухын рәнҗетмәдең!” дигән сүзләре белән толларның тугрылык бәясен күтәрә. “Театр туры юлга, нурга илтә” дип бәяләсәләр дә, Коръәндә бу җәһәттән рух рәнҗи дигән нәрсә юк. Киресенчә, гыйддәт вакыты (билгеләнгән 4 ай да 10 көн вакыт) тәмамлангач, өйләнү, кияүгә чыгу рөхсәт ителә.

...Алтмышка җитеп килгән ир, сөйгәне кайту хәбәрен белгәч, йөзенә шатлык куна, сүлпәнлеге, җитезлеккә алышына. Атна буе юылмаса да исе китмәгәнне - табак савытын да ялтыратып юа, паласларын да кага, мунча

моржасыннан ургылып төтене дә чыга. Боларны күргәч, миңа “фал” ачыла: “Эһе, сөеклесе кайта!” Үзе шаян кешегә шаяртып сөйләшәсе килә, очраса сүз кушам.

- Карт гашыйк! “Мәхәббәтең” кайтамени?,- дип елмаям.

– Эһе, гашыйк та буласың икән ул!

– Алтмышта нинди ләбүф инде ул?!, дим, нинди дә кызык сүзен ишетәсе килеп.

- Менә шул алмышта кирәк тә икән ул, любовь дигәннәре, - дип куя җитди генә. “Уңышсыз шаяртуым” сәбәпле, елмаюым да ирен читендә эленеп кала...

Ялгызлар насыйп ярларын очратсалар, бернигә карамый парлашсыннар – ялгызлык утында янмасыннар. Дөньяның бер почмагында ялгызлыктан бер ир-егет аптырый икән, Ходай аңа туры килгән хатын-кыз белән ике йөрәкне тоташтырырдай җеп сузса икән дә, ялгызлар кимесен икән. Күктәге кояш балкышына сөенеп, тормыш арбасын парлап тартып, пар канатлар белән хыял дөньясын гизеп, киләчәккә матур уй-максатлар белән, гөрләшеп яшәргә насыйп булса иде икән. Ә кеше тормышын, бәхетен, бәхетсезлеген тикшерергә хакыбыз юк!

*“Т.Я”№11(30.01.2014)дә басылды.*

# Укучыларыгызның хөрмәтен тоеп яшәгез!

Гомер уза аккан сулар кебек. Еллар постларын алыша, буыннар буыннар белән алышына. Шулай дисәм дә, без – урта яшьтәгеләрнең мәктәптә укып йөрүләребез күптән түгел генә кебек. Мәктәп еллары – гомернең бер кайгысыз, рәхәт мизгелләре. Хәтер барлаганда, укытучыларыбыз да искә төшә. Күпләре инде арабызда юк...

Бәйрәмнәр арасында мин белем бәйрәмен яратам. Авыл сәнгатен җитәкләгәндә күп санда төрле бәйрәмнәр оештырырга туры килде, ләкин беренче сентябрь көнендәге кебек шат күңелле, киенеп-ясанып килгән, һәрберсе чәчәк бәйләме кочкан тамашачылар да, уйнаучылар да күргәнем булмады. Яңа уку елы ул яңа эш башы – җитди бәйрәм. Шаян сүз, җыр-бию белән дә күңел җилкетүче юк, югыйсә. Ләкин бар да елмая, куана. Кемгә ничектер, бу тантанада

куанычым тулы булсын өчен, миңа үземне укыткан өлкән укытучыларыбызны ерактан булса да күрү кирәк. Ә аларның сафлары елдан-ел сирәгәя. Туган мәктәбемнән бүгенге көнгә кадәр эземне суытмасам да, күңелемдә укыткан укытучыларым мәктәптән аерылгысыз булып күңел түремә эленгән. Мөхәммәт Мәгъдиевның "Кеше китә – җыры кала" дигәне - китап исеме генә түгел, канатлы сүзе дә дип саныйм. Укытучының биргән белеме белән бергә күңел түрендә кабатланмас җыры да кала, димәк. Әнә шулай, күнел түрендә урын алган онытылмас укытучыбыз Сәляхова Гөлҗиһан Миргасыйм кызы турында язып үтмәкче булам. Аның эшләгән дәверендә яулаган исемнәрен дә, аның тырышлыгы, үҗәтлеге белән салынган мәктәбебезне дә, утызлап бәбкәне җил-яңгырдан, тилгәннәрдән саклап канат астына сыйдырып үстергән ана каздай коллективны бербөтен итеп тотучы көчле җитәкче булуын да язырга җыенмыйм. Зур көч сораган бу хезмәтне җиренә җиткереп башкарган җитәкче-хатын-кызның, укытучы буларак укучылар күңеленә матур юл салуын бәялисем килгәннән кулга кәлам алдым. Гөлҗиһан Миргасыймовна укыткан елларда күпме укучы мәктәпне тәмамлады икән?! Үпкә белән искә алучы бер генә укучы да юктыр дим.

Гади була белде, һәр балага аналарча хәер-хаклы карады. Начар укучыга да, тәртипсез балага да әзәрлекле караш белән каныгу кебек сыйфатларны ят итте. Тетмәңне тетә торган сүзләр дә кулланып әрләмәде. Аның үзенә генә хас борчулы шул ук вакытта ачулану сүзләре бар иде: "Син инде, Фәләнов, йә, нәрсә инде..." Тәмамлап та бетерми иде җөмләсен, ләкин үзенең яхшылыгы белән яулаган хөрмәте, шул сүзләре белән идәнгә сендерә дә куя иде. Линейкалар да ачыктан ачык күренә иде бу сыйфаты.

Пионер, комсомол оешмалары гөрләгән чакта урманга менү, тарихи сыерчык тавына бару кебек экскурсияләрдә, өлкән гәүдәле мөгаллимәбезнең яшьләрчә активлыгы бүген дә искә төшә дә, сокландыру хисе били: пионервожатый, сыйныф җитәкчеләре шунда булса да, берәр күңелле уен уйнатып, укучылары белән әвәрә килеп ала торган иде. Гадәттә, җитәкче үзен гади тотса, түбәндәгеләр саннамаска шартлар туа. Шул җәһәттән, язып үтәм – укытучылар да, ата-аналар да, укучылар да тирән хөрмәт итәләр иде аны. Дәресләре (география) шул кадәр җанлы, кызыклы була: ишек шакып берәрсе чакырса, күңелдә ризасызлык туа иде. Кайбер укытучылар, дәресендә нәни генә тәртипсезлекләргә дә директорны алып керә иделәр. Фәкать, эшләрен күрсәтергә теләгән алар! Югыйсә, дәрестә тәртипсезләнгән укучыны җиңмәс түгелләр иде - көчле иде укытучыларыбыз. Гөлҗиһан апа усал, нәфрәтле караш та, ачы тиргәү сүзләре дә кулланмады. Бу мәсьәләләрне чишүдә иң әүвәл аның үзенә карата

яулаган хөрмәте ирешкәндер, тавыш күтәрмичә матур итеп әрләгән, җиңелчә оялткан сүзе - тәрбия асылы булып җитешкән, күрәсең. Укучыны хурлап әйтелгән сүз белән хөрмәт яулап та, тәрбияләп тә булмый. Кире нәтиҗә генә бирә шул.

Мәктәпне тәмамлап, хезмәтләре белән матур, кешелеккә үрнәк укытучыларыбыз дип хөрмәт йөзе белән карап яшәгән елларымда, мәдәни чараларга кунак итеп чакыргач, хезмәтләре белән тагын да якынрак танышкач - тагы да сокланырдым мин аларга. Бөдрә чәчле (һәрхәлдә, прическа ясалган), хуш исле ислемайлар бөркелгән, зәвык белән киенгән бар барлыгы белән дәрес биргән укытучыларыбыз, коммунистлар партиясе кушканча актив булып, иртәнге контроль савымнарга фермага да барып кайтканнан соң дәрес биргәннәр икән. Хатын-кызлар советы җитәкчесе булып сайланганга күрә, көннең (бәлки төннең дә) авылыбызның ир һәм хатыннары арасындагы гаилә низагларын чишәргә ярдәм иткәннәр, (ата-ана һәм бала проблемаларын чишү хәзер дә бар), бәйрәм саен кичләрен лекция уку, колхоз кырларындагы уңышны җыюда катнашу, макулатура, көл җыю һ.б. – болар барысы да укытучыны кешелектән чыгаручы гамәлләр ләбаса. Шундый шартларда ничек күркәм холыклы, итагәтьле кеше булып кала алганнар? Бу юлларны укыган яшь укытучы: “Аның каравы, ноутбуг булмаган! Ике журнал тутырмаган”, дияр. Һәркемнең үзенеке - үзәктә. Авырлыклар һәркайда, һәрвакыт булган, бар, булачак. Укытучыга күпчелек хөрмәт белән карый, хезмәтләрен зурлый. Шулай да, бер сүзнең шаһиты булырга туры килде. Укытучының хезмәтен олылаучыга - берәү: “Укытса?! Һәркем эшли. Мин дә 20 ел сыер саудым. Колхоз сыеры савылсын дип түгел - тормыш, балалар дип, акчасы кирәк булганга эшләдем”, - диде. Укытучы хезмәте белән чагыштырып булмаса да, ул да үзенчә хаклы. Ләкин һәр хезмәтнең башлангычы, олы юлбашчыбыз – укытучы бит! Өлкән укытучыларыбыз үзләрен искә алмаганга күңелсезләнмәсеннәр. Хезмәтегезгә иң зур бәя газетада басылган мәкалә түгел – укучыларыгызның сезгә карата ихлас хөрмәте. Ә бүләк – укучыларыгызның ихтирамын тоеп яшәгән Ходай биргән гомерегез!

Авылыбызның легендар шәхесе Гөлҗиһан Миргасим кызы дөньялыктан китте инде. Соңгы юлга озата барганда кышның зәм-зәһир салкын көне иде. Укытучы буларак күңелдә сакланган якты истәлеге, онытылмас кайгыртучан җылы карашы - салкынга бирешмәскә ярдәм итте. Күзләр яшьләнде, иреннәр бер үк сүзләрне кабатлады: “Урының җәннәттә булсын!”

...Кабер ташлары арасында мөгаллимәбезнең үткен карашлы, сөйкемле йөз сүрәтлесе дә бар. Туктап сөйләшми, догалар укымый мөмкин түгел – әледән-әле тере чәчәкләр куелган булуы белән дә еракта җәлеп итә ул.

*“Безнең гәҗит” газетасында басылды.*

# Коръән укы

Безнең балачак динсез Совет илендә үтте. Күпчелек гаиләләрдә әби-бабалар, әти-әниләр иманлы, динле булса да, балаларына “ашаганчы, эш башлаганчы бисмиллә әйтергә кирәк” кебек иң гади дини тәрбия генә бирделәр. Чөнки җәмгыять: мәктәп, хезмәт коллективлары атеистлар тәрбияләде. Без - 1970 нче елдан соң туган балалар, җитлегеп, тормыш корган елларда динебез көчәеп, мәчетләр калыкты, телевидение программаларында ислам динен күәтләү, дини матбугат басмалары (мәсәлән, минем өчен, “Юлдаш” газетасының “Дин вә йола” кушымтасы шул елларда кирәкле ярдәмлек булды), догалар, намаз өйрәнү өчен китапчыклар басылып дөнья күрде. Кыскасы, дини гыйлем алуга, дин тотуга хөррият ачылды. Ләкин моңа безнең ишеләрнең күңел калыбы әзер түгел иде әле...

Хәзер инде, Советлар Союзының без – “бәхетле балалары” олыгая барабыз. Яшь барган саен кеше тормыш кыйммәтләре турында уйлана икән. Уйланабыз, асылына төшенәбез, ә гамәл кылмыйбыз. Ничектер, без булдырмас эш кебек. Иман ныклыгы җитеп бетмиме, әллә тәвәкәллек юкмы? Коръән кушканча яшәргә теләк бар, дәрман юк дигәндәй – кереп китеп булмый. Аллаһы Тәгалә коръәнне кешеләргә туры юлны күрсәтер өчен, хакыйкатьне ялганнан аерып, дөрес итеп яшәү өчен иңдергән. Нәрсәнең хәләл, нәрсәнең харәм икәнен дә бик яхшы белсәк тә, күпләребез аерып тормый... Иң башта, күңел дөньясын үзгәртү өчен коръәнне үзеңә аңлашылган телдә укып чыгарга кирәк дип саныйм мин. Тәвәккәлләп Коръән укырга күпләребез курка. Беренчедән, аңга сеңгән буенча аны өлкәннәр яки дини гыйлемгә ия булганнар гына укый дип фикерлибез. Аннан, нәрсәне дә булса килештермичә, гонаһлы булырбыз дигән уй да юк түгел...

2003 нче елда мин, “өйдә Коръән булырга тиеш” дигән уй белән, Коръәннең Рабит Батулла тарафыннан татарча мәгънәви тәрҗемәсен (2001 нче елгы басма) сатып алган идем. Анда гарәпчә язылышы да, транскрипциясе дә юк. Аны укырга, кызыксынуым көчле булуы гына этәргеч бирде. Ә наданлыгым белән гөнаһлы булдым – таһәрәтсез укырга ярамаганын белмәдемме, әллә белепме үтәмәдем. (Ходай кичерә күрсен, берүк!) Укыдым мин аны. Укыган саен күзләрем зуррак ачылды, камиллегенә исләрем китеп, урыны-урыны белән туктап та калдым: “Менә сиңа гаҗәеп дәрәҗәдәге тәрбия гамәлләре, күркәм яшәү рәвеше!” дигән соклану уйлары баш миемне сызып үтте. Ләкин уку теләгем сүрелгән урыннары да булды. 10 еллар элгәре дөньяны, үз – “алсу күзлегемнән” чыгып кына фикер йөртә идем шул. Коръәнне укыган кеше белә: бәкарә сүрәсенең 178 нче аятендә “үч кайтару фарыз...” диелгән. (Арттырып эшләргә ярамый!) 179 нчы аятендә: “Ий, акыл ияләре, үтергән кешене үтерүдә сезнең өчен яшәү көче бар..” ди. Кечкенәдән, иманлы әти-әниеңнең “таш белән аткан кешегә дә, аш белән атканын” күреп үскәннәргә, бу аңлашыла торган түгел шул. Акыл туплагач аңладым: начарлыкка начарлык эшләргә рөхсәт шуннан, зыян күрүченең күңеле тынычлана. Бу - авырмас өчен! Югыйсә, рәнҗү ул күңел халәте һәм гомер буе иярә килә. Ә үпкә-рәнҗүләр төрле авыруларга, шул исәптән онкологиягә кадәр җиткерә. Юкка гына табиблар яман шешнең стресс, үпкә-рәнҗүләр нәтиҗәсендә булуын расламыйлар?! Бу булды – бер! Икенчедән, шапшак җаннар тетрәнсен, сабак алсын өчен...

Коръән һәр яктан камил! Барысын да яшь бараган саен аңлыйсың... Газиз әти-әнием ахирәткә күчкәч, белгән догаларымны рухларына багышлап дога кылырга өйрәндем. Китаплар күп, берсендә: “... бәндәләргә мохтаҗлыгымны төшермә” дип ялварасы. Холкым, кеше ни әйткән - шуңа ияреп йөри торган түгел. Башта “бизмәнгә салып үлчим”, аннан үз фикерем дөреслек ягына күбрәк басса – үземнекен эшлим. Монда да шулай: “Ничек инде, - дип уйлыйм, - кешеләр белән бергә-бергә, ярдәмләшеп яшиседер бит?!. Күңелем белән кабул итмәгән бу җөмләне күп еллар төшереп калдырып кыла килдем. Соңгы елларда гына өстәп әйтә башладым... Дөрес булмаган нәрсә юк ислам динендә - Аллаһ бер кимчелексез итеп яраткан! Бер Аллаһы Тәгаләгә таянасы, аннан гына өмет итәсе! Ә иманлы бәндә, Ходай кушканны үти ул (тыйганыннан тыела) - мохтаҗларга үзе булыша, ярдәм сорап торасы түгел.

Коръәне дөрес итеп уку өчен гарәп хәрефләре белән укырга әйтәләр. Шулаен шулай да, югарыга менү өчен астан күтәрелергә кирәк бит. Үзлегеннән өйрәнгәндә үзеңә аңлашылган телдә укып асылына төшенмичә, гарәп хәрефләре белән яки транскрипциясе белән уку, коръән укуга ныклы адымнар була алмас

дип беләм. Ана телендә укып мәгънәсен аңлау кирәк! “Кириллица белән җиренә җиткереп укып булмый!” диләр, дини гыйлем ияләребез. Шул ук вакытта, “Укымаудан - уку хәерлерәк!”, дип өстиләр. Гыйлемгә омтылган кеше гарәп хәрефләрен дә өйрәнә ул. Туганым, транскрипциясен авырлык белән укыгач, бозамдыр дип күңелсезләнә. “Коръән укучыга бер хәрефкә 10 савап булса, өйрәнгәндә азапланып хәреф җыючыга икеләтә савап булыр”, дигән хәдис бар дип тынычландырам аны. Изге ният белән укыгач, гонаһ булмас, иншаллаһ. Госел-таһәрәт алырга өйрәнү дә бер дә катлаулы эш түгел. Коръән укыйсы килү теләге үзе госел-таһәрәт аларга этәргеч бирә. Һәр нәрсәгә ирешеп була. Аллаһ ярдәменнән ташламасын! Күңелебез саф, гамәлләребез ихлас булсын! Язмамны Рәдифә Хәсәни шигыре белән тәмамлыйм.

*Күңелеңне пакләр өчен,*
*Бу дөньяны аңлар өчен*
*Коръән укы.*
*Сөенечле хәбәр килсә.*
*Йөрәккәең дулап типсә,*
*Коръән укы.*

*Авыр сүздән күңелең тулса,*
*Күңелеңдә борчу булса.*
*Коръән укы.*
*Бары шулай синең җаның,*
*Сафлык ала.*
*Кайгыларың югала һәм*
*Шатлык кала.*

*Ак-караны аермасаң,*
*Туры юлны табалмасаң,*
*Коръән укы.*
*Җаның-тәнең шифа алыр,*
*Күңелләрең гел ак калыр.*
*Коръән укы.*

P.S. Күңелләрендә булып та тәвәккәлли алмаганнарга, бу язмам коръән укуга этәргеч бирсә иде. Сүз иярә – сүз: Коръәне булмаганнарга раннур нәшрияты чыгарган гарәпчәсе, транскрипциясе, татарчасы бер китапта булган коръән алырга тәгъдим итәр идем. Бәясе - 2000 сум чамасы тора. Аны интернет-кибеттән дә алырга була.

*“Авырмас өчен 101 киңәш” газетасында басылды.*

# Җәберме, әллә кадерме?

Илдә халык телennән озак төшми торган вакыйгалар гел ишетелеп тора. Баксаң, бар да тормышта очрый торган  хәлләр. Ләкин үткән вакыйгаларга һәркем үзеннән өсти торгач, әйбәт үк куера – фаҗигага әверелә. Кемгәдер шул гына кирәк тә, болай да тузгыган ояга таяк тыгу - иң отышлы вакыт! Уйлый торгач, аптырап бетәм: кешелек дөньясы яралып камильләшкәненә ничә гасырлар үткән, ә кешелек дәрәҗәсе, үзаңы бер дә югары күтәрелмәгән икән, ә бәлки гел төшә бара дияргә ярыйдыр.

Көнчелек, бер-береңне күралмау, кеше уңышсызлыгына канәгатьлек хисе кичерү, бәхетсезлек очрагында - гәепне гаепсезгә сылау, киң җәмәгатьчелеккә үз фикереңә кушып, кайдан-нәрсә ишеткән – шуны кушып гайбәт куерту кебек хәл һәр җирдә тамыр җәйгән...

Чит илгә Русиядән опекунга алынган бер бала җәберләнүе турында әллә ничә каналдан  тыңлый  торгач, әллә башка проблема юкмы бу илдә, дигән сорау бораулаган иде  мине. Инде Алексеевск районында асылынган бала фаҗигасын сөйләп бетерә алмыйлар. Я, Ходаем, тәрбиягә бала алу да куркыныч ич! Күршеләренең улы интернетка куйган хәбәре, тагын шул ук гаилә сөйләгән сүзләр белән, үз балалары янына чит балалар сыйдыра алган олы йөрәкле гаиләне - кешелексезлектә гәеплиләр. Хакмы, нахакмы - белешеп торучы юк. Бер авыздан чыккан – бар гавәмгә таралган!  Әллә кешенең начарлыгы чыгуын көтеп кенә торабызмы соң? Һәрхәлдә, кызулык, ялгышлык белән арттырып җибәрелеп эшләнсә дә, гомер иткән күршеңнең начарлыгын кеше алдына чыгару килешле эш түгел бит. Балигъ булмаган баланың хупланмаган гамәл кылуын аклагандай, ярты гасыр күрше булып яшәгән авылдашыңа пычрак ат инде, ә? Әллә ул баланың геннарында үз-үзен күралмау, суецидка бирелү кебек галәмәтләр булган?! Бу вакыйгада чит кеше булсам да, кемдер гәепләнгәндә битараф кала алмыйм. Уйлап карасаң, тәрбиягә алган бала түгел, йөрәк астында йөртеп, үзең тәрбия биргән бала да үз гомерен үзе өзә бит, әгәр тәгъдиренә язылса. Мондый уйны күңеленә керткәннәрнең, күңеленнән алсын, Ходай! Ярар, бу очракта тәрбиягә алынган баланы яратмыйча, җәберләгәннәр дә, ди. Ә кем соң үз баласын кимсетә яки җәберли, асылынып дәрәҗәгә җиткерә?! Кеше гәепләгәнче шуны уйлап карагыз! Көне белән, үзең нәрсә уйлаганны, башка берәү беләме йә, әйтегез?! Нинди генә уй кереп чыкмый башка – дөньяга үпкәсе дә, рәнҗеше дә бик булырга мөмкин. Гел оптимист булып бетеп булмый бит.

Имеш, чоланга бикләп куйганнар. Ә кем күргән? Яки, ә бикләсәләр ни булган? Ә бәлки тәртип бозгандыр? Һәркемнең үзенчә тәрбия бирү алымнары

бар ич. Үз балаң өчен бер җирле органга да җавап тотмыйсың – бары шул гына. Күп кенә аналар: ”Атагызга әйтәм!” дип, талканы коры аталарына таянып, тәрбия кылалар. Ә аталары, берәр тапкыр булса да бу сүзнең мәгънәсен “гамәлдә кулланып” караган була, шулаймы? Югыйсә, әйтеп кенә кайсы баланың шаярудан туктаганы бар? Мәсәлән, безнең гаиләдә эти йомшак табигатьле булса, әни тәртипне каты тота иде. Яшермим, кирәк урында кыенны да ашадык. Кечкенә чакта риза булмасак та, тормышны аңлый башлагач, әнинең каты тәрбиясенә мең рәхмәтле булып яшибез. Искә алабыз да, бәялибез. Дөрес эшләгән, дибез. Һәрнәрсәдә тормыш мәгънәсе, гыйбрәт бар! Бервакыт, эшкә китәр алдыннан гына, 4 бала арасында килеп чыккан ызгышка “суд” ясаганда, кулындагы таягы белән абыйга берне ”кундырырга” туры килгән, әнигә. Әлбәттә, шуның белән ызгышка “нокта” куйган. Беркем кысылмаган, гаепләмәгән - үз баласы ич! Апаларым елаган энеләрен кызганганнар да, икенче юлы сукмасын дип, үтемле чара уйлаганнар. Әни эштән кайтырга, каршысына апа чыгып: “Менә, Исмәгыйльнең кулы сынган!” , дигән. “Йөрәгем “жу” итеп куйды. Әйбер белән сукмаска сүз бирдем үз-үземә”, дип искә алып сөйли иде әни.Үзебезнең гаилә мисалында ашыгычлык, артык кырысланып китү белән дә әллә ниләр килеп чыгарга мөмкин диюем. Акыл-насыйхәт белән генә тәрбиянең катырак алымнарын кулланмый бала үстерүче кешеләр моны язганга гаепләрләр. Сер түгел бит: элек һәр ишле гаилә матчасында тармаклы чыбык кысылып тора иде. Ул гадәти тәрбия чарасы булган. Иптәшем дә, ул сыек чыбыкны татыганын өчен бер дә бабасына ләгънәт укымый, шулай кирәк булган дип искә ала. Миңа үзем генә үскәнгә чыбык татырга туры килмәде, ләкин бер очрак гомергә истә калырлык булды. Өйгә вакытында кайтмыйча онытылып уйный торган гадәт бар иде. Дустым Рәхиләнең әнисе Әминә апа кичке савымнан кайткач кына таралабыз. Кышкы кичләр караңгы. Әни әрли тора, мин соң кайта торам. Барып, әрли-әрли алып кайткач, бер ара бармый тордым да тагы “шылырга” йөрим. Әни сизде дә: ”Караңгы төшкәнче кайтмасаң, бәйгә куям, бел!” диде. “Ничек бәйгә куя алсын инде, мине?”, дип куана-куана чыгып киттем. Тагын онытылып уйнаганмын, караңгы да төшкән. Әни әрләр инде дип кайтсам, бер сүз әйтмәде. Ишегалдына чыгып аркан алып керде дә, бусагада утырып торган көемә, ” Мин сиңа бәйгә куям дидемме”, дип аркан белән гәүдәмне чорнап та куйды. Авыртырмады да, ләкин гарьләнеп елаганым бик яхшы истә калды. Шул көннән кичке караңгыга калып уйнаулар бетте, кылт итеп теге юан аркан искә төшә дә кайтып китәм. Матур ук булмаган бу тәрбия алымын монда язуымның хикмәте бар. Бүгенге җәмгыятьтә өйдә генә булган хәлләрне халык каршына чыгып чәчәбез. Ул “Пусть говорят “ кебек тапшырулар җәлеп итсә дә, кайчак бигрәк күңелне чыгара. Үземнекен язуыма килгәндә – бу җәһәттән әйтер сүзем бар!

Әгәр мин тәрбиягә алган бала булсам, шуны безгә гел кереп йөргән Гайнелхәят әби күреп, сер итеп бер кешегә чишсә, сүз йөри торгач, тиешле органнарга барып ирешкәч, бар масса-күләм чыганаклар, бар дөнья вакыйгалары белән беррәттән, гади генә керсез күңелле бер авыл хатынының тетмәсен тетәр иде. Ә мин - "зыян күрүче бала", шунда әйтсәм: "Ни хакыгыз бар кысылырга?!"- дип. - Мине вакытында ашасын, өйдә булсын дип үтемле чара кулланган, бары шул гына. Юк шул, бала чакта алай уйлый белмисең.Уйласа да, ничек әйтү җил уңаена була, шулай әйттерәләр дә... Илдә хәл ителәсе проблемалар хәттин ашкан . Җыелып фикер алышырга яратабыз бит, бәлки уңай хәл ителер – ил күләмендәге мәсьәләләрне чишәргә тырышыйк! Шуның белән, җәмгыятьтә алга китәр. Нәрсәгә ул, гаилә эчендәге җыен вак-төякне ил белән бергә уртага салып тикшереп утыру. Ә бу очракта, шыр ятим яки ваемсыз ата-анадан артык булган балаларны кемдер күңел җылысын биреп гаиләсенә сыйдырган икән, рәхмәт диик! Кайгыга дучар булган - хәленә керик! Тәрбиягә бала алу һәркеше булдыра торган эш түгел бит. Мәсәлән, безнең Имәнкискәдә асрамага бала алган кеше юк әлегә. Әгәр ул бала файда китергәненә эчегез пошса, үзегез алып тәрбияләгез! Сезнең дә керемегез дә, эшче көчегез артыр. Тик нигә шул ягын гына күрәләр икән? Пешереп ашатырга, җыеп юарга да күпме вакыт кирәк. Кеше күп булган саен проблема күбәя. Аны хәл итәргә акыл, сабырлык сорала. Нигә шуны уйламыйлар?

Авылыбызда ачык йөзле Нурия исемле кыз бар иде. Үзе зыянсыз булсада, кечкенәдән акылга тулы булмады. Авылыбызның бер сөйкемле сөяге булып, гел халык арасында кайнашты ул. 45 яшьләрендә микән, әнисе үлеп китте дә караучысыз калды. Кыю гына бер хатын тәрбиягә аласы килүен белдергәч, китте фикер алышулар, алмаган-булмаганны тикшерү: имеш, аңа юл кырында әйбер саттырачак, имеш, күчемсез милегенә кызыккан һ.б. Китте Нуриябез картлар йортына... 1-2 елдан ник, ничек үлгәнен дә белмичә туган авылына җирләп тә куйдык. Элегерәк, шул гаиләдә калса, йөргән булыр иде әле, без - авылдашларына шатлык өләшеп дип уйлый идем. Ә хәзер, ярый ла калмаган дип уйлыйм. Кичтән авырмыйча йокларга ятып, иртән үлгән дисәләр, гәеплэп гомергә башын ашарлар иде ул хатынның. Ә болай, җәсәде белән кайткан хәбәрне беркем дә тикшереп сөйләп тормады. "Татар башын - татар ашар" дигән сүз дөрес булып чыга. Үзе дә сыендырмый, кешегә дә ирек бирми.

Шулай да бар әле арада бернигә дә карамый чит кешеләрне сыйдырган изге күңелле кешеләр. Гөлсинә апа Махмүтова килен булып төшкәндә кайнанасы үлеп, кайнатасы 6, 11, 17 яшьлек балаларны калдырып яңа хатын белән башка йортка чыгып киткәннәр иде. Юныс абый белән барысын да тәрбияләп, туйлар

итеп олы юлга чыгардылар. Иренә ерак туган ялгыз карчыкны да тәрбияләп соңгы юлга озатты  Гөлсинә апа. Һәм менә 13 ел инде йортсыз-җирсез бөтенләй чит бер ирне үзләрендә яшәтәләр. Мин моны киң күңеллелек дип бәялим. Миңа, мәсәлән, тау кадәр акчасы булса да кирәкми ул өйдәш. Ә гаеп табучылар бар! Тырнак астыннан кер эзләгән кешегә: ”Үзеңдә яшәтеп кара!”,  дим мин. Гәепләп сөйләгәнче, башта үзеңне шул кеше урынына куеп карагыз! Булдыра аласызмы? Булдыра алам дип уйласагыз да, әле ул булдырасың дигән сүз түгел – хыяллану гына, иптәшләр.  Кемдер авырлыклар аша үтә-үтә  күрсәткән кадер- хөрмәтне, җәбер дип бәяләмик инде!

*“Т.Я” №27, 28.02.2013  санында кыскартылып басылды*

# Кабул итәрлек булсын икән

Миңа ясалмалык ошамый. Ошамый дип кычкырып йөрмим, әлбәттә. Гади генә әйткәндә, күңелем кабул итми. Һәрберебезнең холкы төрле, шуңа эш-гамәлләребез дә төрлечә башкарыла. Кешене үзгәртәм дию ялгышлык икән. Шуңа да, күңелне иркен итеп, барысында сыйдыра белергә кирәге аңлашыла. Раббыбыз, ихтыяр көчләре бирсә иде. Бу мәкаләне язуым, күңелгә сыймаганнан түгел. Күңел бер төрле халәттә тора алмый. Үзең белән үзең килешмәгән вакытларда, үзгәрергә омтылышлар били күңелне. Шундый чакларда, бәлки бу язмам кемгәдер ярдәм итәр...

Сөйләм телдә,  “Алла сакласын!” дигән сүз-тезмә күп кулланыла. Бу гади җөмлә - ихлас күңелдән зур ышаныч белән Аллага ялвару, ягъни бәла-каза, бәхетсезлекләрдән һ.б. сакла диюебез. Күпләр - көфер, кирәкмәгән сүзләр артыннан да иярчен җөмлә кебек кулланалар аны. Аралашкан танышларым арасында берсе, гомере буе кешене тәкыйтьләп, “тәмләп” тикшергәннән соң, йомгаклау сүзе итеп, “Алла сакласын!”, диеп куя. Үзенчә изге күңелле булып калуы инде ул. Авыл җирлекләрендә, бер-береңне белгәнгә, авылдашлар тормышында килеп чыккан вакыйгаларны телгә алмый мөмкин түгел. Борчу-кайгыларны уртаклашып яшәргә бурычлыбыз. “Шулай, болай булган икән... Алла сакласын! Биргәнгә – сабырлык, күрмәгәнгә – күрсәтмә!” диясе генә бит. Юк шул, күп вакыт шул турыда сөйләү сәгатьләргә сузыла. 2 кеше башлаган сүзгә, кушыла торгач, бер төркем кеше җыела. Сөйләшә торгач, кайгы-борчулар

бу кешегә ни сәбәпле килгәнен дә “белеп” санап чыгалар. Ә бит, ни сәбәпле сынау җибәргәнен, бер Ходай үзе белә. Мондый төркемнәргә, Ходайдан ерак торганнар гына кушыла. Бу бит чын гайбәт! “Алла сакласын!” ничәмә-ничә тапкыр кабатлана шунда?! Саклар микән соң?! Ходайның, гайбәтчеләргә каты ачулы икәнен, ислам дине турында аз мәгълүматлы кеше дә белә ләбаса.

Эчкән баштан рульгә утырып, кеше гомерен куркыныч астына куйчы шофер да, ике күзенә терәлеп торган “Алла сакласын” тасмасын алып куйсын!..

Ялган сөйләгәндә дә кеше ныграк ышансын өчен, ахыргы сүз: “валлаһи”. Төгәл белмим, Аллаһы Тәгалә исеме белән ант итәм, дигәнне аңлатмыймы икән ул?..

Тагы бер ясалмалыкны кабул итә алмыйм. Кайберәүләр, дәвамлы начарлыклар кылып яшиләр дә, көннәрдән бер көн оятны нәрсә икәнен белмичә, берни булмагандай, дусларча сөйләшә үк башлыйлар. Гафу үтенә белмәсә дә, чын күңелдән булмаган яхшылыкларын да эшләргә бик мөмкиннәр әле. Түзеп кенә тор! Каршы килмәвеңне чыраеңа чыгармасаң, китә төчеләнү: “Саулыгыгызны бирсен, Ходай!”, “И-и, бигрәк матур инде син!”, “Бер үк бәхетле була күрегез!”. Бер хутка киткәч, “Ходай бүләге син миңа!” диюгә кадәр барып җитүчеләр бар. Урыслар бу хикмәтне “показуха” диләр, бер сүз белән. Теләкләр кабул булсын өчен, иң әүвәл күңел калыбын чистартырга кирәк. Дәвамлы начарлыкларны ялгышлык димәс идем мин. Ул күңел халәте. Чир китә, гадәт кала... Элекке танышларым арасында, кеше күп йөри торган җирләрдә кайнашырга ярата торганы бар иде. Сөйләргә ярата, сөйләгәнен җөпләгәнне ярата. Осталыгы шул кадәр куәтле - авызына гына каратып тота. Аны тыңлаганда эшең дә кала, чөнки дөньяңны оныттыра. Озын-озак итеп урамда сөйләнелгән сүз, гайбәт булмый ни булсын инде?! Аның җанлы хикәясендә, Ходай сүзе - мәчеттә укылган вәгазьдәгеләрдән күбрәк. Урынсыз шул кадәр: нигә “чи” гайбәтне, олуг сүзләр белән “болгатырга”? Гайбәт сөйлисең икән, гайбәт кенә сөйлә! Ходай дип сөйләшеп кенә изге кеше булып булмый ул. Һәр сүзнең үз урыны бар!

Ислам динен җәелдерү һәр мөселманның бурычы икәнен беләбез. Ләкин бер күренешне тәнкыйтьләргә булдым. Дөрес аңлата алсам икән. Казанга баргач, РКБ тукталышында чандыр гына гәүдәле мөселманча киенгән хатын, татар чырайлы кешеләргә ятлаган нотыгын сөйли. Матур сөйли – тыңлап кына торасы килә. Ләкин урынсыз. Аның максаты, дингә чакыру, исламны җәелдерү, савап җыю. Юлчының максаты, барасы җиренә вакытында барып, тизрәк әйләнеп кайту. Аның дингә чакыруына “мохтаҗ булмасам да”, изге максат белән йөргән

кешедән йөз чөерә алмау сәбәпле, миңа кирәкле маршруткаларны күз чите белән генә озаттым. Икенче юлы барсам, тагы шул апа шул ук тукталышта каршыма басып, шул ук нотыгын сөйли башлады. Канәгатьсезлек биләп алды күңелне. Кирәкме инде бу гамәл, йә? Орлыкны да бит шытсын өчен туфракка чәчәләр, асфалтька чәчеп кадерсезләмиләр. Суны да сеңәр җиргә сибәләр. Сүзне дә кабул итәрлек урында гына сөйләсәләр икән. Тыңлап бетермичә утырып киттем. Ул тагы кемгәдер сөйләнеп калды. Бу очракта, исламны җәелдерүгә файдасын әйтә алмыйм, ә менә кире нәтиҗә бирергә мөмкин. Коръән Кәримдә, ислам диненә тәэсирле вәгазьләр, хикмәтле сүзләр белән чакырырга дигән. Хаклыкны төшендерергә тартыш һәм көрәш тә хуплана. Ләкин иң күркәм юл белән, дигән ("Нәхел" сүрәсе, 125 нче аять). Күркәм юл белән дигән шул! Ашыкканда, очраклы бер кеше әйдәгәннән генә беркемдә дингә тартылмый. Алладан вакыты җитмичә, күңел калыбы тәмам өлгереп җитмичә, газиз анаң көн-төн тукыса да файда юк. Каршы килә дип гаепләмәгез. Һич юк! Урынлы җирләрдә вәгазьләр тыңлаганда (күңелгә карап) аз гына булса да кабул ителә ул, чөнки кирәксенеп, теләп барасың андый урынга. Күркәм урында күркәм юл белән генә үтемле ул, диясем килә.

Берничә ел элек кунакта булганда, хуҗабикәгә ияреп, бер дә белмәгән кешегә мәҗлескә барырга туры килде. Кечкенәдән, коръән ашларына чакырырга барганда, әни: "Кунагым бар дип, әйтә икән, кунагыгыз белән килегез дип әйт!", дип өйрәтеп чыгара иде. Бу күркәм гадәт бездә генә түгел икән! Кая барганымны язмыйм - уңайсызлыкка калдырасым килми. Кешенең начарлыгын уртага (кеше каршына) чыгарырга кушмаган, Ходай. Әйтәсе сүземне үтемле итү өчен генә телгә алам бу хәлне. Мәҗлескә җыелып беткәндә, күрер күзгә 50 яшьләр чамасындагы сөйкемле бер хатын килеп керде. Күрешеп чыкканнан соң, нигәдер үзенә урын табалмагандай, үзен сәер тота башлады. Кунак бүлмәсенә табын артына утырыша башлау белән, "Битем яна, йөземә чыктымы?", - ди. Юк, диешәләр янындагылар. "Уф, кызам, янам...", ди. Кан басымың күтәрелде мәллә соң, диеп, хуҗабикә шкафтан дару ала башлады. "Юк, борчылмагыз, кирәкми. Мин табынга утырмам, сезнең тирәдә булышкалап кына йөрермен, каршы килмәсәгез", диде. Мәҗлес матур гына тәмамланып, үз кешеләр генә калгач, бу апа "чишелде". Баксаң, Коръән укучы хатынны күңеле кабул итмәгән: "Гомеремдә дә гафу итәсем юк! Җизнине сөйдергеч-сихерләре белән үзенә каратып, 2 баланы ятим, апаны тол итте. Ул гына җитмәде, мәктәптә укыганда шул балаларга үч итеп каныкты. Хәзер коръән тотып түрдә утырган була..." Акыллы киңәшләр биреп, тынычландыруларны күрмәде дә, кызуын дәвам итте: "Минем башыма укыган бер сүрәсе дә, аяте дә керми. Күңелемнән һич китми торган пычраклыклары күзалдыма килеп баса. Ник кенә шул гонаһларын

кичерүен сорап, өендә генә укымый икән ул коръәнен? Сезгә дә, беткән иде мени түр башына утыртып, коръән  укый ала торган ак әби, ак бабайлар...”  Сүзсез калдылар. Ахрысы, дөреслек бар иде бу хатын сүзләрендә. Бүген дә шул искә төшә дә, тирән уйларга биреләм. Кем хаклы соң?  Бер карасаң, игътибар да итмәскә кирәк кешенең кабул итү-итмәвенә, үзең теләгәнчә яшә дә, яшә... Алай дисәм, еллар дәвамында үпкә-рәнҗү белән сугарылган күңелне, кемдер укыган дога белән “юып” бетереп тә, ихтирам да яулап та булмый икән. Бу өлкән укытучының да күңеле чистадыр дип уйлыйм. Күңеле саф, ихлас булмаса, 5 вакыт намаз, Коръән укый алмас иде. Кешене алдалап булса да, үз күңеленне алдалап булмый бит! Кешелек дөньясы яралаганнан бирле барган бу каршылыклар: ошату-ошатмау, килешү-күрәалмау - мәңге чишелмәс, мөгаен. Ләкин ничек кенә булмасын, яшьлектәме ул, картлыктамы,囗эштә карьера ясыйсың киләме яки үз бәхетең өчен көрәшәсеңме – күтәрелергә, дан-шөһрәт яуларга нинди генә уңайлы форсатлар тумасын, кешеләр генә түгел, Ходай үзе риза булырдай гамәлләр кылып яшәргә насыйп булса икән. Аллаһы Тәгалә ялгышулардан үзе сакласын!

*“Б Г” №43 (30 нчы октябрь 2013) басылды.*

# Канаты каерылган ирләр + йөрәк яралы хатыннар =

# = Чишелешен кем табар?

“Иреннән аерылып кайткан икән” - авылда мондый сүз элек тә йөргән, хәзер дә ишетелә. Тормыш катлаулы, сәбәпләр күп. Хатыннарның иреннән аерылуы гайре табигый хәл түгел. Ә менә ирләрнең гаиләсен калдырып, аналары янына кайтуны ничек аңларга?!  Әллә  ирләрдән күрмәк, хатыннар да кул уйнатып, я көнләп җәберлиләр микән, мескеннәрне?

Мескеннәр дип яздым. Көчле затлар дип аталсалар да, күп кенә ирләр тормыш зил-зиләләренә каршы тора алмыйча, бик тиз бирешәләр. Нигә шулай ул? Аптырыйм мин. Кайсы каян, әвен кадәр гәүдәле, алып батырны егардай көчле, Аллаһы Тәгалә  өеп сәламәтлеген дә биргән үзләренә. Ә акыл? Акыл бер чәркә эчү белән спирт күк очып юкка чыга.

Авыл тулы исерек ир-егетләр. Шуларның күбесе өйләнмәгән һәм дә өйләнәчәге дә юк! Кайсы гаиләсен калдырып каладан кайткан. Авыл җирлегенең

күңеле киң – авылдашыңың җәсәден дә, гаиләсенә сыймаган исереген дә сыйдыра, кыйбласын югалтканнарны да кире бормый. Ярый әле туган нигезләр, игелекле туганнар, барын да күңеленә сыйдыра алган әниләр бар.

”Дүрт аяклы ат та абына”, дигән әйтем бар халыкта. Абынуын – абынасың, ятып калмыйсың бит, барыбызда торып баса. Баскач, әлбәттә тирә-якка карыйсың. Менә шул әйләнә-тирәңә караганда бары да күренә инде: кем кызык табып көлә, кемдер кызгана, якын иткәне аякка басырга ярдәм итә. Шул чак кемнең кем булуы да, кайсы түмгәккә абынганың да аңлашыла. Аңлашыла... тик хатаны төзәтәсе дә бит, әмма тәкәбберлек комачаулый. Ай, шул тәкәбберлекне! Ничекләр җиңәргә?! Гаеп күп вакыт абынучыда. Төртеп егу турында түгел, тормышның гади генә түмгәкләренә абынуыбыз турында гәп куертам. Гәепсез - бер Аллаһы Тәгалә. “Тәүбә итегез!” -дигән Ходай. Тәүбә ит тә, якыннарыңнан гафу сора! Тәкәбберлек ирек бирми дисезме, кадерле ирләр?! Ә бит, эчеп бар горурлыгыгызны аяк астына салып таптарга бернигә тормый сезгә. Гафу итмәсләр димәгез,гафу итә белә хатыннар. Тик, тукран тәүбәсе кирәкми - туйдырды , ирләрчә булсын! Ант кебек!

“Ни җитми хатыннарга?” - дип язалар иде элек. - Ни җитми ирләргә? Нигә җылы якка оча алмаган гарип бәбкә күк канатларыгызны салып йөрисез? Тормышта үзегез сызасы, артыгыздан гаиләгезне ияртәсе туры юлыгызны “онытып”, кибет юлларында нигә туктаусыз каңгырап йөрисез сез? Бомж лар түгел бит сез! Җылы, төзек йортларыгыз, тәмле ашлар пешереп торган хатыннарыгыз, эти дип өзелеп торган үз балаларыгыз бар, югыйсә. Ни җитми ирләргә? Рәхәткә түзми ирләр! Эчкечелекне авырулар рәтенә кертәләр. ”Эчкечелеккә бәйлелек” дип атала бугай ул. Нинди генә төр авырулар юк, җир йөзендә. Дәваланабыз бит. Чит илгә барып дәвалану өчен дә миллионнар табабыз, яшисе килгәч. Эчкечелекне дәвалау өчен, миллион кирәкми – бер теләк кенә кирәк. Юк шул, теләк дигәннәре. Чөнки бик “рәхәт” авыру белән авырыйлар. Рәхәт, кәеф яхшы, тормыш бара, хатын китми - ябышып тормыш итә, балалар үсә тора. Акчаны хатын таба, чөнки кешедән ким яшисе килми, ут-газга түләнгән, утын килеп ауган, мунча ягылган. Кеше алдында сер бирмичә, ир итеп күрсәтәсе вакытта, күтәреп дигәндәй, юындырып чыгаралар, киендерәләр. Ашарга пешкән, алдыңа китереп куелган. Чиста урында ауный-ауный йоклыйсың. Баш чатнап уянсаң, торып тагы эчеп кайтасың... Терлек каралган, бар проблема чишелгән! Ә ник эчмәскә? Мондый рәхәтне патша да күрмәгән. Патша дигәннән, патшаның хезмәтчеләре хезмәткә яраксыз хәлгә төшсәләр яки үлеп китсәләр, аның урынын башка хезмәтче биләгән. Ә гаиләдә, гомер иткән хатының урынына башкасы килер, дисезме? Көт менә килә, ди! Мондый

хикмәткә бары яшьлектә сине сөеп яр иткән, бергә балалар үстереп, йорт-җирләр җиткереп яшәгән хатын гына түзә. Түзүен түзә, ләкин гомере бәрабәренә. Ә гомер бер генә тапкыр бирелә! Җүнле яшьлеген күрмәгәч, матур картлыгын күрәсе киләдер ул. "Ыңгыр-шыңгыр" итми генә, оныклар сөяр бәхетне татыйсы да килә бит. Ә аның өчен, я аерылып матур картлык өмет итәсе, яки исерекне "кеше" итә-итә вакытсыз гүргә керәсе... Ә бит шуны аңлаган хәлдә, хатыннар ахыр читкә кадәр гаилә учагы саклыйлар. Дөньяда, мәхәббәт дигән бөек хис бар бит әле. Нәфрәт кичә-кичә, мәхәббәтен саклый күңел! "Хатын-кыз яратмаганын сәгате-минуты белән белдерер, яратканын күңелендә гомер буе саклар" - ди. Бик дөрес сүзләр! Саф мәхәббәт хисе генә кичерә алмастай хәлләрне гафу иттерә. Ә кем аерылган, димәк, тәүге хисләрне саклый алмаганнар. Аерылганнарны гаепләмәс идем мин. Алар булган вакыйгаларны бизмәннәргә салып үлчәп, алга карап яшәүче көчлеләр дип бәя бирәм, үземчә. Димәк, башкача була алмаган. Ә менә гаиләсен аракы, кәеф-сафага алыштыручыларны берничек тә аклый алмыйм. Тормышта тирә-яктан гыйбрәт ала белмәгән кеше икеләтә бәхетсез. Кызыклы ачыш ясадым әле беркөн: булдыксыз хатынны ир беркайчан да ташламый икән. Сәбәбен бик яхшы беләм: көчсез хатын янында ирләр күпмедер өлеш үзләрен көчле дип саныйлар. Ә тормыш йөген, ирле көе дә үзе тарта алган хатын янында көчсез хис итәләр. Аннан, ни хикмәт ул көчсез хатыннарның көче – "күз яшендә" була, елап җәлләтә. (Елатып кара син, ире эчкән хатыннарны! Дөнья еламаска өйрәтеп бетерә шул аларны.) "Салырга" да маһир булалар мондый хатыннар. Ир мескен ни җүнле ашау күрми, ә барыбер үзен бәхетле дип саный. Аңламассың, бу тормышны! Адәм баласы рәхәткә түзми, михнәткә түзә, дип аңлыйм.

Озак еллар бергә яшәү нәтиҗәсендә хисләр суыну дигән нәрсә бар. Моны бу өлкәдәге белгечләр дә раслый. Талчыктыргыч бертөрлелектән хисләрне яңартырга кирәк, диләр... Бервакыт мәдәният йортында чибәр ханымнар арасында бәйге үткәрдем. Сорау-җавап өлешендә: "Ирегез белән ачуланыштыгыз, ди. Эшләр бер-берегездән читләшүгә таба бара. Һәм сез...?" – дип ситуация каршында калдырам. Бәйге тотучы бер хатын бик төгәл, кыска җөмлә әйтте: "Мунча ягам!". Шул чак, тамашачыларга карадым. Тормыш төбеннән күтәрелгәннәр, тапкыр җавапне бәяләп, алкышладылар. Мәгънәсен төшенмәгәннәр - кызык табып көлделәр. Мин исә, бу сүзләрне "хәтер янчыгына" салып куйдым: "Әһә, минәйтәм, юкка гына 4 бала үстереп, матур гына яшәп ятмыйлар икән болар!". Ә ирләр нигә гаиләне саклау өчен аз гына башларын эшләтмиләр? Әллә аларга гаилә, арттан сөйрәүче койрык кына микән? Айныдыңмы? Гамәлләреңә нәтиҗә ясап, яхшылык, миһербанлык эшләп гөнаһларыңны юу! Алып кайт бер букет чәчәк - юктан да күңел була, кайчак.

Хатыныңнан дип әйтмим, балаларыңнан гафу сора. Шуны ишеткән хатының, үзеннән гафу сорагандай кабул итәр. Күп кирәк мени хатыннарга: бер җылы караш, бер җылы сүздән, сүз ялгарга әзер бит алар. Ирне бит, күлмәк алыштырган күк алыштырып булмый!

Ирләре эчкән хатыннар газетага язмый. Минеке дә эчми. Кая барсам да, тирә-якны күзәтергә яратам, ә кеше хәленә бик тирән керәм мин. Тирә-яктан үзем өчен гыйбрәт җыярга яратам. Ләкин гайбәт белән бутамагыз! Игътибар итәм гел: ире эчкән хатын, киңәш тә сорамый ул.  Алай да бер яшь хатын : ”Ничек яшәрмен икән? Бик эчә. Син ничек түздең?” - дип сораган, олы яшьтәге хатыннан. Әби әйткән: “ Әгәр учыңда утлы күмерне кысып тоткан хәлдә, йөзеңне чытмыйча, әрнегәненне сиздермичә түзә аласың икән, ирең белән яши алырсың,” - дигән. Булган сүзмедер, юкмы - белмим. Әмма ләкин, күңелләре тулы кайнар күмер йөртеп тә, укытучы, кибетче, җыештыручы кебек - халык белән аралаша торган хезмәтләрдә дә, берни белдермичә, елмаеп, эшләрен җиренә җиткереп башкарган хатыннарның булуына иманым камиль. Утлы күмердән берни калмый, бар да яна-көя. Ә йөрәк җәрәхәтләнә. Вакыт – дәва, төзәлә төзәлүен, тик шулай да, яраламагыз  йөрәкләрне, кадерле ирләр! Матур итеп яшәүгә ни җитә?! Аек акыл, дустанә мөгалләмә белән яшәүчеләр дә бар бит арабызда. Берсе дә мөгезле түгел, койрыклы түгел - бар кешеләр кебек. Әле дә соң түгелдер... Гомерлеккә сайлаган ярларыгыздан гафу сорап, кадер-хөрмәт күрсәтеп, үз балаларыгызның әти-әни дип өзелеп эндәшкәнен ишетеп, һәр туган көнгә өмет белән карарга исәп тотыгыз!  Кирәкмисез сез- туганнарыгызга, аларның үз гаиләләре бар! Кирәкмисез сез- әниләрегезгә, алар сезгә канат куеп очырганнар инде. Сез бары гаиләгездә бәхетле! Туры юлга басыгыз! Кадерсез үткән гомерләр әрәм. Ә ул - ике килми!!!

*Язма кыскартылып, “Ни җитми ирләргә?” исеме астында, ”Т.Я” №71 (13.12.2012) дә басылды*

# “Син, малай, әдәби телдә сөйләшәсең!”

Милләтебез каһарманнары бәйсезлек, милләт, татар теле өчен көрәш юлында байтак кына көч-куәтләрен салганнан соң, ярым урыска әйләнгән телебезнең күп кенә сүзләрен татарчалаштыру еллары булды. 1990 нчы еллар башы иде бу. Тел галимнәре, журналистлар, татар теле укытучылары зур тырышлык салдылар ул елларда. Яңарышларны яратуым сәбәпле, сәхнәдә үткәргән чараларда гел кулланышта булып килгән урыс сүзләрен саф татар телендәгеләргә алыштырып, кичәләр алып барырга бар тырышлыгымны биргән идем шул елларда. Әле катнашучылардан да шуны үтендем. Очрашу кичәләрендә авылча, апа-абый димичә, яки исеме, әтисенең исеме белән әйтмичә, әфәнде, ханым, туташ дип эндәшеп алып бара башлаган идем, ләкин алар кулланышка кермәделәр. Ярар, сәхнә - сәхнә инде, күпшы сүзләр дә урынлы санала, гәеп итүче булмады шикелле. Ә урамда берәр авылдашыңа шулай эндәшеп кара, юләргә караган шикелле карыйлар. Өстәп, “тозсыз” дигән бәяләмә аласың. Ә “тозсыз” дигән сүз авылыбызда артык зыялылардан тыш, һәркемнең теленнән төшмичә йөри. Килешсез сүздән, кабул ителмәгән гамәлдән соң ошатмыйча, тозсыз дип әйтеп куялар, бездә. Үсендереп мактаганда, молодецны татарчалаштырып әллә ничәгә төрләндерәбез: муладис та, маладис та була, ләкин афәрин дип “тозсызланмаска” тырышабыз. “Әбизәтелне, запрысты, кәнкрит әйткәндә, вүпчем (в общем), эпсәлүтне, пужалуй, һ.б. сүзләр татар теленнән төшәсе юк. Яңа “чүп” сүзләр дә кулланышка керә. Соңгы елларда яшь егетләр “бырат” дия-дия, яңа, соклану сүзен керттеләр: “каты булган бу!” Яки гади генә: “кааты-ы” дип, гаҗәпләнү тойгыларын белдерәләр. Сүзенә күрә, мәгънәсе туры килмәсә дә, шулай дигәч күңелле булып китә. Нинди генә булмасын, яратып әйткән сүз кеше күңеленә яхшы үтеп керә бит. Тик, кирәкне - үз итмибез, кирәксездән - арынмыйбыз. Шундый кавем булган инде безнең милләт.

Культурасы алай бик югары булмаган бер хатын, миңа әйтә беркөн: ”Син малай, штуты, әдәби телдә сөйләшәсең!” Елмайдым гына. Малай булмыйча, кыз-хатын төркеменә керсәм дә, ул бит авылыбызда гасырлар дәвамында кулланышта булган якын эндәшү сүзе белән сөйләшә. “Штутыны” “чаваты” белән алыштырып әйтсә дә, “тозсызланып” төзәтергә җыенмыйм. Чит телләр белән чуарланмаган, матур әдәби тел - әдәбиятчылар теле булып саналуы гына кызганыч. Халыкның сөйләм теле, нәрсәгә тотынган, шуны кулдан ычкындырмаган күк, матур сүзме, юкмы – буыннан буынга тапшырыла. Тел байлыгына таянып, камиллеккә омтылмагач, шулай булмый ничек булсын соң?! Саф татар телендәге сүзләрне кабул итмибез, ә урам сүзләре тиз үз ителә. Теге

елларда яңарышны, алгарышны кабул итәр өчен милләтеңне, телеңне хөрмәт итәргә, киң карашлы булырга кирәк булгандыр шул. “Утның кызуында сугалар” диләр. Тик, учагынмы яхшы үрләтмәдек, әллә ут кызуында суга белмәдек?..

“Т.Я” да басылды.

# Яшь каласы килә

Көтеп-көтеп тә әбиләр чуагы булмады ахры, быел. Табигать үзенекен итми калмас, анысы.  Шулай да, көз соңлый күк тоела - каеннарга карап шулай фикер йөртәм.  Алар әле һаман җете сары шәлләрен ябынасылары килмичә шаулашалар. Без, урта яшьтәге хатыннар да, оныклар туып: “Син әби!” дип сугылган мөһер белән саннашырга теләмичә, гел яшьлеккә омтылабыз. Чәчләрне күпертәсе, йә китәртәсе килә. Тырнакларны да буяп, матурайтасы, тыйнак кына булса да бизәнәсе дә килә. Дөрес, “әбилек тә” чабудан тарта – яулык ябып йөрергә куша күңел. Ләкин яшьлек күбрәк җилкетә: “аллы-гөлле” буялган чәчләрне йомшак җилләр иркенә таратып йөрү күңелгә хуш килүчән... Каеннарның җәйдән көзгә керәсе килми тарткалашуы да, урта яшьтәгеләрнең картлыкка бирешәсе килмәүләре дә бик табигый. Күңел гел матурлыкка омтыла, гел яшь килеш каласы килә...

Фән-техника казанышлары заманында яшибез. Яшь, матур булып калу өчен нинди генә эликсир, гель, крем-лосьоннар уйлап тапмыйлар хәзер. Йөзләгән косметика компанияләре (орифлейм, эйвон һ.б.) эшли. Коры яки майлы бит тиресенә туры килүче кремнар, күз читендәге җыерчыкларны бетерү өчен гель, тән тиресендәге целюлит белән көрәшүче кремнар, ярылучан, мазольле үкчәләрне йомшартучы, шомартучы крем һәм җайланмалар, һ.б. Барысы да алдынгы технологияләр дә, кешенең, бигрәктә, хатын-кызларның матурлыгын саклау өчен эшләнәләр. Бары, керемеңә туры килгән бәядән, үзеңә кирәклесен сайлап  алырга гына кирәк. “Болар барысы да бизнеска корылган, бер файдасы юк дияргә ашыкмагыз.”. Даими кулланучылар күп, файдасы булмаса, икенче кабат алмыйбыз бит. Шуны беләм: һәркемнең организмы үзенчәлекле булганга, килешү бар, килешмәү бар. Рәсми медицинада да, бер кешегә килешкән дару, шул ук диогноз булса да, икенче кешегә килешмәскә мөмкин ич. Косметика компанияләре кулланучыга индивидуаль якын килеп, һәр продуктның үрнәк-пробникларын тәгъдим итәләр. Бәясе дә “чүп” кенә. Югарыда мин,  матурлыкны

тышкы яктан, ягъни тән тиресен тәрбияләп саклау турында язып үттем. Тагы, БАД (биологические активные добавки) дип аталган препаратлар сатыла. Яңалык язмадым, әлбәттә. Яшелчә, җиләк-җимешләр ашасак та, ашаган ризыгыбыз, рациональ туклану таләпләренә җавап бирә алмый. БАДларда көнлек кирәкле минераллар һәм витаминнар белгечләр тарафыннан кирәкле микъдарда көйләнелгән була. Составлары буена алар гел үләннәрдән торалар. Һәр кешенең үз фикере. Сайлау мөмкинлегебез зур, информация чыганаклары күп. Интернетта, үзең ясап була торган кремга игътибар бирдем, бер көн. Кул астындагы үзең белгән, күргәннәрдән ясалган кремны, яхшы теләкләр белән битеңә сөрткәндә, файдасы ничек булмасын икән?! Иренмәгән, вакыты булган кешегә ясау берни түгел алар.

Ходай биргән матурлыкны саклыйк! Үзебезне кайгырту өчен күбрәк вакыт табыйк! Гомер көзләре үзенә күрә бер матур булса да, ашыкмыйк әле. Алда гомерләр булса, ансына да өлгерербез...

*“Т Я” №48 (24.10. 2013) кыскартылып басылды.*

# Тәрәз төбем –гөлбакча.

Тәрәзә төбенә таянып, кышкы урамны күзәтәм. Тирә-як ап-кар... Шул аклыкта үсемлекләр дөньясының барлыгын искәртеп, ям-яшел чыршы күзгә ташлана. Ул да, күз тидермәсеннәр дигәндәй, ботакларына күтәрә алган кадәр кар япмасы “япкан”. Шулай табигатьтән яшеллекне күрергә нәүмизләнеп торганда, саксыз хәрәкәт белән гөлемнең сабагын имгәттем. Үземне үзем битәрләп, гөлем белән булышканда, кабат гөлләр дөньясына кереп киткәнемне абайламый да калганмын. Кышкы урамнан нигә яшеллек эзлим, гөлләрем булганда?! Күңелемне шатлык биләп алды – тәрәзә төбем гөлбакча бит минем!

“Гөлсез дөнья – тәрәзәсез бер төрмә”, - дигән, Фәнис абый Яруллин. Ә мин: ”Гөлләр дөньясы – рәхәт күңел дөньясы” дип тә өстәр идем. Гөлләр үстерү белән күптәннән шөгельләнәм. Җанга – дәва, күңелгә – тынычлык, өйгә – ямь бирәләр алар. Гөлләр үсеп, чәчәк аткан саен – күңел үсә. Кышларын да яшеллеккә күмелгән, чәчәк аткан гөлләр үскән йортларны гөлбакчага тиңлим мин. Яшәгән йортымда тәрәзә төбем унау, тәрәзә төбе саен гөлләр. Нindиләре генә юк – һәрберсе үзенчә матур. Гөлләр тәрбияләү четерекле эш. Һәрберсенә аерым тәрбия кирәк. Су яратулары да төрлечә, һәр җан иясе кебек авырый да

beləlәр, корткычлар да зыян сала. Бегония ел әйләнәсе матур чәчәкләре белән сөендерә. Ләкин без генә түгел тля да бик “ярата” үзен. Бер зарарланса, ни кызганыч - көрәшү нәтиҗәсез диярлек. Гөлләрне су белән сугарудан, ашламалар белән тукландырудан тыш тагы яратарга кирәк. Кызык тоела инде бу, беренче карашка. Тик үсемлекләрдә җан булганы расланган. Һәр җан - эчкерсез яратуны яхшы кабул итә. Аннан, башка җан ияләреннән аерылмалы, яхшы карашка, кайгыртучанлыкка матурлык белән җавап бирәләр: күкрәп үсеп китәләр, шау чәчәккә күмеләләр. Миңа килгән кешеләр үземне күргәннән соң, тәрәзә төбенә таба китәләр, гөлләрем чакыра чөнки. Кызыксыналар дию генә дөрес түгел шикелле, гөлләргә кызыгалар. “Ботагы юк!” дию кебек “җайлы” сүзләр әйтәсем дә килми, кем дә үзендә шундый матурлыкны булдырасы килә икән – алсын, үстерсен. Җир йөзендә матурлык арткannan миңа ни зыян?! “Кул китә” дигән ырымны дөреслеккә чыгарасым килми. Әгәр дөрес булса, минем бер гөлем дә калмаган булыр иде инде. Сирәгәйтү өчен йә картларын яңартыйм дип ботарга туры килгәндә, суга тыгып куйган күплэгән гөл ботаклары тамыр җәйгән икән, үзеңнән артканын ничек ташламак кирәк? Килгән-киткәннәргә үзем үк тәгъдим итәм – кемнеңдер өен ямьләп, үзен шатландырып үссә - күңел бик риза. “Гүзәл, теге гөлең чәчәк атты” дип елмаеп миңа ирештергәндә, куаныч булып үземә әйләнеп кайта. Гөлләр үстерү нечкәлекләрен интернеттан да, махсус китаплардан карап та белеп була. Бу ярдәмлекләр булмаганда, дустым Алмаздан (егет кеше булса да гөлләргә бик ис-хушы китүчән иде) калган истәлек гөл – калланың ни сәбәпле чәчәк атмавын белә алмаган идем. Бездәге сазлыкларда үскән камышлар кебек, Африка сазлыкларында үсә торган үсемлек икәнен алданрак белгән булсам, зуррак савытка утыртып, күп итеп су сибеп чәчәк атуына ирешкән булыр идем дә, бетермәгән булыр идем. Бик юксынам, аның озын сабак чыгарып, кабатланмас ак чәчәк атулары үзе бер бәйрәм күк булган икән. Тагы декабрист гөле чәчәк атмавына аптыраганым исемдә, ахырдан күрше авылга - җирле үзидарә бинасына илттем. Анда хәзердә шау чәчәккә күмелә. Кабат үстерергә кызыгам, соң булса да, аның да ни өчен чәчәк атмавын белдем: һава коры булуы да килешми, чәчәккә бөреләнгәндә урынын алыштыру түгел, борып куярга да ярамый икән. Чүлмәге белән гөлләрем кайларга гына китми. Шуңа, кая барсам да, гөл чүлмәге алып кайтам – аның сатуда ниндие генә юк?! Үтте, буяудан бушаган калай савытларга утырткан вакытлар. Төбен кадак белән тишеп, ак, ялтыравык кәгазь белән уратып куя торган идек - буяуга катмачланганын. Гөл никадәр матур булса да, чүлмәгенә күз төшә шул.

Бу базар икъдисады дигәнебез сатудагы гөл савыты төрлелегенә генә түгел, гөл туфрагына да рәхәт чиктерә. Һәр гөлнең үз төренә килешле җир ачылыгы балансы көйләнгән, суалчан, корткычларга каршы эшкәртелгән,

минералларга баетылган туфракны сайлап кына ал. Гөлгә туфракны үзлегеңнән эзерләү катлаулы эш. Урманнан кәс туфрак, ком, черемә, уңдырышлы көпшәк туфракка ничәгә-ничә нисбәтеннән кушасын белеп эш итәргә кирәк шул. Нинди генә юллар белән суалчансыз туфракка ирешергә тырышканым бар, барыбер чүлмәктә суалчан була. Гөлләр дөньясы да, иҗат эше күк үзенә бәйли. Гөлләр яраткан кешене гөлләрдән биздерәм димә икән. Тагы-тагы утыртасы килә. Кызыгып йә сатып алам, йә кешедән сорыйм. Гөлләр яраткач, бүләк итүчеләр дә күп. Ул "бердән-бер" булганнарны - тагы үрчетәм. "Кая утыртасың, урының да юк ич инде",- дип ачуланды апам, соңгы кайтканында. "Һи, яхшы сүзгә күңелдә урын табылмыймы соң?! Гөлгә дә табыла!", минәйтәм. "Ничә чүлмәк гөлең бар синең?" дигән соравына илтифатсыз гына иңбашымны сикерткән идем, ул санап ук килгән: "Балакаем, 100 дән арткан ич инде, тагы нәрсәгә?" дип, санаганнан зур ачыш ясагандай миңа төбәлә.

- Мин аны бармак төртеп санамасам да шул чама икәнен беләм. Һәр тәрәзә төбендә унлап чүлмәк булгач, шулай була инде ул, - дим. Апамның мине кызганып әрләвен аңлыйм. Ул "тәрбия сүзен" бер башлагач, төгәлли алмый: "Тәрәзә төбе черетеп, пәрдә пычратып... Идәндә - гөл, стенада – гөл! Туя беләсеңме син? Ясалма гөлнең тыштан караганда бер аермасы юк, әнә... Штораларны да күл белән гел тотмыйсың, пычранмагач гел юасы да юк..."

Ясалма чәчәк - чәчәк мени ул?! Ел әйләнәсе күп төрдәге сенполиянең (миләүшә), сезонлы гөл - актыр, кызылдыр эре кыңгырау чәчәк ата торган синнингия, шулай ук бегония, яраннарның чәчәккә күмелеп ямь, матурлык бирүләрен бер генә ясалма чәчәккә алыштыра алмыйм. Ясалма гөлнең гүзәллеге булмый, булмагач - күңелгә дә кучми.

Озакламый март ае туа – яз җитә. Кояш нурларын мулдан сибеп, тәрәзәләрдән туры карый башлый. Гөлләрне язын күчерәләр, үрчетәләр, чөнки язын яхшы тернәкләнеп китәләр. Мин тагы, ай циклына да игътибар бирәм. Тулган ай барлык җан ияләренә начар тәэсир итә, шул исәптән гөлләргә дә. Әлегә кыштан файдаланып, кар эретеп, йомшак кар суын сибеп, гөлләрне сихәтләндерергә була. Язны сизә башладылар инде, синнингия бүлбеләреннән яшь үсентеләр калыкты. Шунсы да алда тормыш барын күрсәтә. Гөлләр куаныч китерми дип кем әйтә алыр икән?!

Ун еллар элгәре, автобуста кайтканда, юлаучы бер хатын әйткән иде: "Сезнең авылда йортлар бар да зәңгәр, тәрәзә төпләрендә тик яраннар гына үсә. Әллә башка төс тә, гөл дә яратмыймы сездә халык?" Ни дип җавап биргәнемне хәтерләмим, ә менә автобустан төшкәч, нәкъ шулай икәненә игътибар иттем:

күпчелек йортлар зәңгәр буяуга буялганын, тәрәзәләрен чәчәкле яраннар “каплаганын” да яңа күргән кебек булган идем. Хәзер дә шул ук йортлар... Тик алар җете зәңгәр дә, яшел дә түгел, заманча матур пластик белән тышланганнар, күпләрендә тәрәзә төпләрен ясалма гөлләр бизи. Тотып карамасаң, аерып та булмый үзләрен. Тәрәзә саен чын яран гөлләр үскән йортлардан күңелгә җылылык, үзенә бер ямьлелек сирпелә. Халкыбыз яран гөлләрне аеруча ярата, газиз әнкәйләр белән бергә җырларга да салына - яраннар белән аналар арасында бәйлелелек бар күрәсең... Үзәк урамда, халык күп йөри торган сукмактан ике яклап урнашкан Равия – Рәшидә апалар, Әнисә апа – Һава әби йортлары сукмакка күз дә төшертми: шул йортларның тәрәзә төпләрендәге гөлбакчалар күз карашын яулыйлар.

“Т.Я”№19 (15.02.2014) да басылды.

# Эчтәлек

Автордан..............................3

Гамьсезме ул, балачак?..............................4

Изгелек онытылмый..............................6

Матурлыкны тудыра алмасак, күрә белик..............................9

Онытырлык кешеләр түгел сез!..............................11

Китек язмышлар..............................14

Рәхмәт сиңа, әни!..............................15

Килешү кирәкме?..............................17

Алкышларны җәлләмик әле..............................18

Сабыр канатларыгыз сынмасын!..............................19

Барыбыз да язмыш кочагында..............................22

Алия “чишмәсе”..............................25

Ак яулыгың кайда, әнием?..............................26

Уйларым – уенчыкта..............................29

Күңелләргә мәңгегә уелган..............................31

Гәҗите – саргайган, яшьләре – олыгайган..............................34

Куркаклык бәласе..............................37

Очрашу күңелле мизгел..............................38

Килмешәк дигән сүз юк!..............................39

Атсыз авыл булырмы?..............................42

Битарафлык ахырзаманга илтә..............................44

Салада - кала тормышы..............................47

Эшегезне яратыгыз, ләкин чамасын белеп........................................................................50

Күңел кояшың сүнмәсен!.......................................................................................................57

Укучыларыгызның хөрмәтен тоеп яшәгез!...........................................................................60

Коръән укы!..............................................................................................................................63

Җәберме, әллә кадерме?...........................................................................................................66

Кабул итәрлек булса икән.........................................................................................................69

Канаты каерылган ирләр + йөрәк яралы хатыннар = Чишелешен кем табар?.............................72

“Син малай, әдәби телдә сөйләшәсең”.........................................................................76

Яшь каласы килә......................................................................................................................77

Тәрәз төбем – гөлбакча............................................................................................................78

*Белешмә*

*1970 нче елның 9 нчы июлендә Лаеш районы Имәнкискә авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, махсус урта белем ала һәм 1989 нчы елдан 2012 нче елга кадәр авыл мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкара. Халкыбыз мәдәниятын күтәрүгә зур өлеш кертүе өчен ТР мәдәният министрлыгының халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге тарафыннан грамота белән бүләкләнә. Соңгы вакытта, “Татарстан яшьләре”, “Безнең гәҗит” газеталарында хәбәрче буларак, аз-маз язгалый...*